# Сәләткә нур булган йолдызлар



# «Сәләткә нур булган йолдызлар»

*Икенче китап*

---

Шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, пьеса һәм публицистик язмалар

Казан
imagestudio
2020

УДК 821.512.145–1/–2/–3/–4
ББК 84 (2Рос = Тат) –4/–5/–6
С94

Төзүчесе: Флүс Латыйфи исемендәнге «Сәләткә нур булган йолдызлар» конкурсының оештыру комитеты

«Сәләткә нур булган йолдызлар»
Икенче китап: шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, пьеса һәм публицистик язмалар / [төз. һәм кереш сүз авт. Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур блугна йолдызлар» конкурсының оештыру комитеты]. – Казан: imagestudio., 2020.– 158 стр.

Әдәбиятка яшьләр килә. Кечкенәдән җитди иҗатка омтылган яшь буын каләмен төрле жанрларда сыный. Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур блугна йолдызлар» конкурсы – яшьләрнең төп ярдәмчесе. Бу җыентыкта конкурста җиңү яулаучыларның һәм казыйлар тарафыннан аерым игътибарга лаек булучыларның эшләре – 100 иң яхшы эш туплап бирелде.

УДК 821.512.145–1/–2/–3/–4
ББК 84 (2Рос = Тат) –4/–5/–6

# Кереш сүз

«Сәләткә нур булган йолдызлар» конкурсы елдан-ел зуррак аудитория туплый: катнашучылар саны арта, география киңәя. Конкурска килгән эшләр дә елдан-ел күбрәк куандыра. Әлбәттә, конкурска килгән эшләр арасында җитлеккән әдипнеке дип карарга мөмкин булганнары да, күп тырышлык таләп иткәннәре дә бар.

Һәр авторның теле, язу алымы, дөньяга карашы аерылып тора. Тик ничек кенә булмасын, алар – татар әдәбияты, татар журналистикасының киләчәге булырдай кешеләр.

Вакыт узу белән, кечкенә генә чишмә дә танымаслык елгага әверелә ала. Моннан күп еллар элек без кечкенә чишмәне елга итү вазыйфасын үз өстебезгә алдык. Тәҗрибәле язучылар, шагыйрьләр, журналистлар һәм драматургларны, оештыру комитетын – барыбызны да бер максат берләштерә: яшь авторларга чын язучы булырга булышу.

Еллар узар. Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур булган йолдызлар» конкурсыннан чыккан авторлар зур язучылар булып танылырлар. Ләкин һәркайсы үзенең чишмә башының кайда булуын йөрәгендә саклар дип өметләнеп калабыз.


Шигърият

## ШИГЪРИЯТ
12-14 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Эльвина Гәрәева***

### Яңарыш

Кайчан гына урам тулып
Йөри идек, җил куып.
Көн үткәнен дә сизмичә
Кайта идек тау шуып.

Дус табуы авырлашты,
Юк урамда балалар.
Буш вакыт килеп чыгуга
Телефоннар алалар.

Таныш түгел кешегә дә
«Дус» куябыз күрмичә.
Урамнан эзләмәсәм дә,
Дусларым әллә ничә.

Дусларым артып торса да,
Нигә күңелсез икән?
Болыннарда качыш уйнап
Йөрүләр җитмимикән?

Фәндә, көндә яңалыклар
Басты бөтен дөньясын.
Бер урында тик тормыйча
Замана алга барсын!

### Кышны көтү

Көз китәргә ашыкмады,
Кышы да соңга калды.
Кар яуганын көтә–көтә,
Күзләрем инде талды.

Алган яңа чаңгылар да
Тик ята тузан җыеп.
Җыештыручы апалар
Йөриләр яфрак өеп.

Мин ышанам, килер ул кыш,
Күмәр дөньяны акка.
Без кар бабайлар ясарбыз,
Куярбыз кышка сакка.

### Ашкыну

Исәнләшәм кояш белән,
Чәчәкләргә кул изим.
Агачлар белән серләшеп,
Яңгыр яуганын сизмим.

Әй, гүзәл соң бүген дөнья.
Йөгереп йөрисе килә.
Яңгыр тамчылары кебек
Сикереп уйныйсы килә.

Җырлыйм, биим, канатланам,
Хисләр ташый йөрәктә.
Өйдә мине туган көнгә
Маэмай көтә бүләккә.

## Истәлек

Бик кадерле бер әйбер
Безнең өйдә саклана.
Әнием гел сөртеп тора,
Күрәмсең, ул таплана.
Миңа аңа тияргә
Әле рөхсәт итмиләр.
«Әниеңнең бабасының
Соңгы ядкаре», – диләр.
Әниемнең бабасы
Сугышта ятып калган.
Буыннан күчеп буынга
Истәлек–рәсем калган.
Җиңү көнен һәр гаилә
Түземсез көтеп алган,
Күпме әни – тол һәм
Балалар ятим калган.
Телимен тыныч тормыш,
Бу заманда бигрәк.
Бабайлар батырлыгын
Онытмаска кирәк.

*2-нче урын*
***Диләрә Зәкиева***

## Кышкы дәрт

Килеп җитте
Салкын кыш.
Көтә безне
Сагынып тыш.
Чана шусаң,
Тау яса.
Чаңгы таксаң,
Эз яса.
Кар бабай да
Ясап куй!
Йөгерсәң дә,
яхшы уй!
Тимераягыңны
Ки!
Чамалап син…
Ай..! Юк!.. Иии…
Саф һавада
Саф уйлар.
Артта калсын
Борчулар!

## Кайтам әле авылыма!

Сагындым туган авылны!
Кайтам әле, ялларда.
Авылымның табигате
Китми һич күз алдан да.
Искә төшә кузгалаклар,
Бакчадагы җиләкләр.
Алмагачтагы алмадан
Тулып тора чиләкләр.
Койма буенда кычыткан.
Ул да мине сагынган.
Сыерчыклар миңа карап
Сызгыралар кыектан.
Өйнең ачык тәрзәсеннән
Әнием карап тора.
Бар да әзер: коймак, бәлеш…
Парлары чыгып тора.
Авылыма кайттым тагын.
Бар да якын. Сагынылган.
Бармы икән җирдә тагын
Туган өйдән якынрак?

## Бәйрәм көн

Бүген иртәрәк тордым
Битне, кулларны юдым.
Чәйнеккә су тутырдым,
Өстәлгә куеп тордым.
Көләч, матур йөз белән
Әни миңа карады.
Бүген бәйрәм көн икәнен
Мин шунда ук аңладым.

Бүлмәмә йөгереп кереп
Бүләк эзли башладым.
Әзрәк кенә эзләгәчтен,
Аллага шөкер, таптым!
Әни янына чыктым,
Кысып кочаклап алдым
«Сигезенче март белән!» – дип
Чын күңелдән котладым.

*3-нче урын*
***Искәндәр Зиннуров***

## Телевизор карыйбыз

Телевизор карыйбыз без,
Әти белән кич җитсә.
Хоккей бара.., уйнар идем
Ак барста, көч җитсә…
Шайба китсә, сикеренәм,
Гол кертсәләр, кычкырам,
Гимн уйналса, шулвакыт
Мин дә басам, төз торам.
Хоккей шәп… футболны да
Яратабыз карарга.
«Хисне бәйдә тот», – ди, әти
Белмим. Ничек ярарга…

## Укытучыма

Ашкынып барам, мәктәбем,
Сөенеп сиңа барам.
Әйтерсең, җәйге кояш син,
Минем укытучы апам.
Елмаюы белән шулай
Гел үзенә тартып тора.

Иртән йокыдан тормыйча
Иренеп ятып кара.
Белем иленнән бергәләп
Икәү атлыйбыз.
Икебезгә бер сөенеч,
Бер үк кайгыбыз.
Укытучым! Син искиткеч…
Йөрәгеңдә урын чиксез.
Без дә сыйдык
Аяз күкне иңләр өчен,
Иңнәремә бергә–бергә
Канат куйдык.

## Дуслык

Тал белән каен янәшә,
Әйтерсең, якын дуслар.
Дуслык җылытыр аларны
Килсә дә салкын кышлар.

## Бәхетле мин

Әбием бар, бабам бар,
Әнием дә, әтием дә.
Бик бәхетле, матур пар.
Якты йөзле, шат күңелле
Якын туган – апам бар.
Бәхетле ич, зур бәхетле
Күңелемдә юк бер зар.
Белем алам мәктәбемдә,
Бәхетлемен – бәхет бар.

## Безнең мәктәп

Безнең мәктәп
Бик хозур.
Чиста, төзек
Һәм бик зур.
Укый анда балалар,
Тырышып белем алалар.
Укытучылар гыйлемле
Безгә бирә белемне

## Яз

Кышның күзенә карап яз
– Мин киләм, – дип тартыша,
Әллә кыш картайган инде,
Бик кыюсыз карыша.
Февральнең уртасына
Яз өермәдәй керә,
Өй кыекларыннан тамчы
Тып–тып килә – сикерә.
Булмас, димә, килмәс, димә
Кыш көне дә яз җитә.
Ә яз көне йөрәкләрне
Әче буран, җил өтә.

15-18 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Диләрә Кашапова***

## Төн

Төн. Офыкта кояшның соңгы нуры сүнде,
Бакчаларда гөлләр йомган күзен.
Бары йодызлар һәм ак ай гына бизи
Караңгы күк йөзен.

Төн. Бар җиһанда тынлык хөкем итә,
Шау–шу тавышлардан тынып калган дөнья.
Искән җилдә агач яфраклары гына,
Күңелгә шом салып, кыштырдашып куя.

Төн. Күк гөмбәзендә яңа йолдыз кабынды,
Берсе сүнде шул ук мизгелдә.
Белдем: йолдыз булып яңа язмыш кабынгандыр,
Яшь күңелем шундый сизгер лә.

Төн. Җил дә тынды, әмма яфраклар
Үз телендә һаман серләштеләр.
Күңелемдәге уйлар һәм хыяллар
Бер табышмак булып берләштеләр.

Төн. Таңга әле ерак, табигать ял итсен,
Сихри төнгә кабат сокланыйм.
Җир тынычлыгын саклаган йолдызлар һәм
Мин генә йокламыйм.
Төн...

***

Табигатьнең ачы күз яшьләре
Булып ява көзге яңгырлар.

Бу яңгырда тәнне генә түгел,
Җанны өшетерлек сагыш бар.

Кулчатыр астына ышыкланып,
Ашыгабыз җылы өйләргә.
Көн буена баштан кичкәннәрне
Якыннарыбызга сөйләргә.

Булган кулчатырын да ачмый,
Кайберәүләр бара чыланып.
Чөнки өйдә тик ялгызлык көтә
Бушатырга күңел чоланын.

## Яз шәүләсе

Көн бүген шундый матур,
Күк аяз, кояш көлә.
Саран гына булса да,
Бераз җылысы килә.
Зур боз сөңгеләренә
Вак тамчылар җыела.
Агач ботакларыннан
Тәңкә карлар коела.
Кыш әле бар көченә
«Мин хуҗа», – дип лаф ора.
Тик кояш нурларында
Яз чыңы эленеп тора.

## Тукайга

Тукай рухы белән килә
Табигатьнең һәр язы.
Җанны телгәли шагыйрьнең
Мөкатдәс моңлы сазы.

Нәни Апуш, Тукай, Бөек Тукай…
Үзе таныш, үзе бик серле.
Әле шаян кебек, әле җитдиләнә,

Һәр әсәре үзенә бер төрле.

Шигырь юлы саен тирән мәгънә,
Гыйбрәт, киңәш, үгет–нәсыйхәт.
Пәйгамбәрчә әйтелгән ул сүзләрне
Һәр буынга белү мәслихәт.

Шагыйрь дә син, Тукай, философ та,
Тарихчы да, көрәшче дә.
Ничек өлгердең син барысына да,
Шундый кыска гомер эчендә?

Еллар саны гына исәпләми
Даһиларның гомер юлларын.
Еллар түгел, хәтта чорлар аша
Горур яңгырый Тукай җырлары.

Ул җырларда – милләт язмышы,
Халкын сөйгән шагыйрь өзелеп.
Халкың барда, син яшәрең, Тукай,
Халкың гомере – синең гомерең.
Мөмкинме соң Тукаеннан башка
Күзалларга татар милләтен?
Татар дигәч, Тукай искә төшә,
Тукай дигәч, татар милләте.

## Салкын җәй

Җәйне кемдер урлаганмы,
Әллә качканмы үзе?
Җәй җәеләсе аланда
Сагышлы көзләр эзе.

Җаннар җәйгә сусаганны
Ул әллә белмәгәнме?
Үпкәләгәнме, югыйсә,
Үртәргә теләгәнме?

Тәүлекләр буе түгелә

Күкнең тишек комганы.
Күңелгә үк үтеп керә
Салкын яңгыр томаны.

Җил дә хәтта ачы исә,
Яфрак-–таҗларны коя.
Игенчеләр басу-кырдан
Юеш уңышны җыя.

Август – инде җәйнең төне…
Мәрхәмәтле бул безгә!
Кояш назын бүләк ит бераз,
Кергәнче елак көзгә.

*2-нче урын*
***Алинә Хәбибуллина***

***

Салкын карашыңнан тәрәзәләр
Ап-ак бәскә күмеләләр.
Үреләләр.
Куллар һаман бозга үреләләр.

Бер тамчы нур тәтемәсен белеп,
Керфекләр дә талпыналар.
Тартыналар.
Күзләр генә никтер тартыналар.

Серләреңне синең тойган кебек
Чәч очларым дулкынлана.
Ялкынлана.
Эзләреңнән күңел ялкынлана.

Көчсезлегем түгел. Дәшмәвеңнән
Мин чыныга гына барам.
Янам.
Бозлы тәрәзәгә кулым терәп,

Суыгыңнан жылы табам.
Янам.
Утта дөрләп, чыныгадыр ярам…

***

Дәшмисең.
Яратам дәшмәвең,
Бернигә карамый
Һәрвакыт үзеңчә эшләвең.
Яратам күзләргә
Чүп-тузан булып кермәвең,
Очрашу эзләп беркайчан
Артымнан ияреп йөрмәвең.
Дәшмисең.
Әйдә соң, дәшмә син.
Мин түгел, сиңа тик гөлләр тиң.
Яратам
Атлавың, йөрешең,
Битараф карашың,
Күзләрең көлешен,
Югары баскычтан төшмәвең.
Дәшмисең.
Яратам дәшмәвең.

***

Чылатканда яңгыр табан астын
Каян жылы учак табасы?
Сөртәсеме кайнар күз яшьләрен?
Әллә тыштан салкын каласы?

Адым саен очрый тукталышлар –
Калын түбә, бәлки, ышыклар.
Тик иреннәр һаман дерелдиләр,
Үтеп китсә яннан гашыйклар.

Үткен жилләр йөзне яраласын,
Кулны киссен көзнең суыгы.
Талпындырмас мине янәшәдә
Тукталышлар бик күп булуы.

Тайгак юллар, борылышлар аша
Сулышыңны тоеп йөгерәм.
Миңа дигән тукталышым мине
Сабыр гына көтә – мин беләм…

***

Бармак очларымда – кышкы суык,
Бер селтәнсәң, кисәр һаваны.
Көт син, көтмә… Бары табасы юк
Тегеп куяр кешең яраны.

Күңелемдә – гөлчәчәкләр шиңә,
Кыш билгесе түгел кар гына.
Дөнья кадәр иркен булган хыял
Энә кадар жирдәй тар гына.

Батыр булсаң, жилне куып кара,
Жылы өреп кара дөньяма…
Чү, хәзер үк инде сискәндереп,
Төнне ярып кызыл ут яна.

Бармак очларымда – кышкы ялкын,
Бер селтәнсәң, кисәр һаваны.
Әллә синме, һәрчак хыялланган
Бәйләп куяр кешем яраны?

***

Мин үтәсе бозлы юлларга
Йолдызлар сибелеп калганнар.
Алар да, канга ук сеңгән
Хисләрнең утында янганнар.

Адашкан күңелем бик мохтаж
Шәм уты кадәрле яктыга.
Тапмадым ни бер уч жылылык –
Төн үтеп, инде таң яктыра.
Карашың суыгы һаман да
Боз булып йөрәкне газаплый.
Кышкы жил түгел, дәшмәвең
Йөземне аяусыз яңаклый.
Күзләрем – йолдызлы юлларда,
Кайнармы яктырак янганнар?
Барыбер бик салкын күңелгә:
Йолдызлар керфегең очыннан
Юлларга сибелеп калганнар.

***

Казан урамнары бәхетле:
Юлларында – синең эзләрең.
Кабан күле дулкыннарын назлап,
Йөгергәндер синең күзләрең.

Бауман диварлары хәтерли
Үтеп киткән серле сыныңны.
Сөю тулы кайнар сулышым да
Казан һавасына сыенды.

Казаныма барам дигәндә,
Уйларымны эчкә качырып.
Ашкынуга һич тә түзә алмый,
Синең янга кайтам ашыгып.

Барам түгел, кайтам ашыгып…

***

Төннең төпсез
Йөзендә
Йолдызлар ясаган

Рәсемең.
Сәгать пояслары
Һаман да
Язалар кадерле
Исемең.

Һәрвакыт кабатлыйм,
Телемдә
Яндырам
Кояшлы исемең.
Онытыйк
Бик авыр булуын
Караңгы кышкы көн
Хисенең.

Мин язган барлык
Шигырьдә:
Син генә.
Син генә.
Син генә.
Карга манылган
Учымда
Җавапсыз мәхәббәт
Сизелә.

***

Күкрәк тутырып исним январьне –
Һәр күзәнәк кардан киенә.
Ераклардан урап узсам да мин,
Бар юллардан сиңа киленә.
Сиңа түгел, синле иртәмә –
Минем иртәм сине ярата.
Хисләремнең һәр бөртеген җилләр
Карлар белән сибеп тарата.
Синең язың – шунда, дисәләр,
Төшәр идем җир асларына,
Ни кызганыч, әмма без яшибез
Төрле сәгать поясларында.

Мин беләмен: синнән бураннар
Бер адымга артта калмыйлар.
Тик маршрутлы автобуслар гына
Синең якка алып бармыйлар.
Таң кызарган мәлдә кушыла
Плей-листта – Сплинның соңгы жыры.
Колакчыннар дәлилли аладыр:
Ут-ялкыннан тавышың жылы.
Ул жылыга түзми, йөгереп,
Атылырмын кебек урамга.
Ялгыш кына утырып поездга,
Кузгалырмын кебек юлларга.
Карлар эреп, бураннар тынгач,
Гашыйк булсам язга бермәлне,
Сагынырмын кебек барыбер дә
Синле кышны, синле январьне.

***

Очраклы карашлар төзидер язмышны,
Кайвакыт – очраклы очрашу.
Вагонда/метрода очрцаклы танышу…
Нәтижә – очраклы кавышу.

Кисешә лифтларда бормалы сукмаклар,
Хатларда фикерләр кисешә.
Борылышта кинәт кисешә маңгайлар –
Очраклылык безгә килешә.

Ялгыш кына ки дә иң матур күлмәгең,
Ялгыш кына яңгырда чылан.
Бар да очраклы, дип үжәт ышанырга
Без, кешеләр, һәрвакыт чыдам.

Чиксез интернетта очраклы танышу,
Кем беләндер ялгыш табышу.
Барысы да гади очраклылык, диеп
Күңел белән генә карышу.

Очраклы очраклар комбинациясе
Тудырадыр бөтен язмышың.
Үз тормышым – үз кулымда, дисәләр дә,
Үзгәртелмәс язган ялгышың.

Безнең белән булган һәрбер очраклы хәл
Күптән инде язып куелган.
Бик күптәннән күкләрдә үк хәл ителгән,
Китабыңа, бәлки, уелган.

Планнар корам, диеп уйласаң да, безне
Үзе урнаштыра башкала.
Сиңа язган бары бермәл сиңа була,
Башканыкы – була башкага.

***

Ыгы-зыгы. Дөнья кайный. Уйлар чаба.
Хәл алырга житми бер сәгать.
Хисләр ташый. Каннар кайный. Бу давылда
Яратуым сине – бер сәнгать.

Коры жилләр сукмагыма кар тутырган.
Юаш кына сиңа юл ярам.
Сөю – сәнгать. Түзү – сәнгать. Үзең – сәнгать.
Жилгә каршы чыгып, мин барам.

Моң тәменә сусап кипкән иреннәрем
Сөйләр сиңа шигырьләр яттан.
Ул сәнгатьне бирәү миннән яхшы белсә,
Мәхәббәттән шундук баш тартам.

19-25 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Энҗе Хөсәенова***

***

Шигырем укырсың,
укыйсыңны беләм.
Гади сүзләр арасына
ихлас яратуым әләм.
Йөрәгемнең иң түренә
(кагылмаслык итеп!)
яш(е)ренгән синең исем.
Бүләк иткән чәчәгеңнең
Һәр таҗында – сөю исе.
Меңнәр арасыннан
сине күрәм.
Һәр очрашу саен
(хәтерләсәң!)
толымнарым үрәм.
Шигырем укырсың,
укыйсыңны беләм.
Мин җанымны
(бүгенгедән)
мәңгелеккә
урталайга бүләм.

***

Ә аралар өзелмәгән әле,
ябылмаган әле юллар да.
Хәтерлимсең, каен сыендырды
коеп–коеп яңгыр яуганда.

Соңгы очрашулар күпме булды,
өзгәләде һәрчак бәгырьне.
Яшьнәтә дә, яшәтә дә алган
беркем дә юк синнән кадерле.

Бу юлларны укыганда, бәлки,
танымассың да син үзеңне.
Миндә инде соңгы тамчы калды,
бүлеп бирче бераз түземне.

Төшләнәмме, әллә инде өнем?..
Сине күрүләрем чынмы соң?!.
Бу буранлы көндә уртак газап –
Соңгы очрашуның соңгысы…

***

Бу җиһанның
кайсыдыр бер
почмагында
беләм
синең
барлыгыңны.
Миннән искән
җылы җилләр
чәчләреңә килеп
кагылдымы?
Син —
йөрәгемә
уелган
шатлыгыммы,
сагышыммы?
Сандугачлар аша
юлладым мин
тавышымны.
Таныдыңмы?..
Кояш

нурларыннан
тоярсың син
җылылыгын
күңелемнең.
Мин
һәрдаим
юлларыңда
бер яктылык
булып
күренермен.

***

Мин көчсезмен, әнкәй.
Бу тормышның
мине кабат
үтереп
сынавы.
Әйтче, зинһар,
гомер, яшәү
берәр кайчан
җиңел буламы?
Мин ялгызым,
әнкәй.
Син дә ерак.
Мендәр кочып
елыйм төннәрен.
Түзалмыйча
бу газапка,
бу әрнүгә
сулый алмас
булдым
бер мәлне.

Кул сузучы
кешем юк та, әнкәй.
Уйлар килә кайчак
ярдәмгә.
Йокы керсә,
тынычланып торам,
онытылып торам –
тик әзгә.

Ә уянгач,
шул ук газап, әнкәй.
Бимазалый
җанның сызлавы.
Кочак–кочак бәхетләрнең,
никтер,
тамчысы да
насыйп булмады.
Син дә ерак, әнкәй.
Мин ялгызым.
Көннәр кыска,
Төннәр бик озын.
Йокы керми
интеккәндә,
менә кабат
күз яшьләрен
сөртә кызың…

*2-нче урын*
***Адилә Әхмәтҗанова***

***

Әле дәме хисләреңне көзен
урап йөрисең син муеныңа?
кулың әгәр туңып китсә кинәт,
уйлыйсыңмы аның хакында?

Әле дәме, аны килер диеп,
Төзисеңме буп–буш хыялларны?
Чигәләргә язылган диярсең,
Аның исем буамы тыныңны?

хәтта аның өчен югалырга,
үзгәрергә әзер, күзләреңнән
аңлыйм җаның сызлануын
һәм файдасыз киңәш бирәм:
Оныт!

Йөткергәндә аның исем яулыгыңда
Калса да, син хәтереңнән
югалуын көт тә, алга атла,
азапланма ялгыз сөюеңнән.

Эх, белсәңче, никадәрле салкын
йөгерүен синең сүзләреңнән.
«Әле дәме… яратасың?»
диюеңнән. Әле дәме?

***

Интернет челтәре тотмавын
Сәбәпкә алыпмы,
Бер кәгазь хат килә язасым.
Мин озын хатларны үз итәм.

Эзләнү түгелме
Билгесез сырхауның дәвасын?
Бармаклар калтырап туктата,
(Үҗәт кыз туктыймы?)
Ул яза! Канатып ярасын.
Язылгач, уйланыр «Кемгә»се
(Саташу түгелме!?)
Я, ярый, котылыйм, язылсын.
Шушы хат төгәллек кертер дә,
(Яңартып яраны)
Һәр кеше аңлар күк хатасын.
Сүзләр күп, хисләрне әйтмим дә
Бик килә (чынлапмы?!)
Хатымның азагын табасым…
Язылды аталып һәр сәбәп,
Белмим, аңларсыңмы,
Мин яздым, табарсың чарасын.
Ниһаять, тәмамлыйм сүземне
(Күңелдә бушлыкмы?..)
каләмнең бетереп карасын.
Бу хатны тапшыру бик мөһим
Тоела…ертыйммы?!
Тапшырам! тик яңгыр туктасын…

***

Чик куймый читлеккә эләгү –
Шулкадәр гадәти вә еш хәл.
Чыгарга юл эзләү нияте
«Тап, – ди, – зур хатаны иң әүвәл».

Дүрт яклап дивар да очрамас,
Ә атлар юлында зур киртә.
Хатаны табарга соң түгел,
Тик ярты гасырга бик иртә.

Нигәме? Аңлатам: бу хата
Хәзерге тормышка артык зур.

Ясалган адымны акларга
Җитмәстер үтүе бер гасыр.

Хатаның нилектән гыйбәрәт
Икәнен мин сезгә сөйләмәм.
Мин генә интекмим чыга(а)лмый,
Чыга(а)лмый замана читлектән.

## Иреккә

Зәңгәр белән яшел төсне кушып,
Хасил булган дөнья кисәге,
таңны төнгә ялгап үзенеке итә,
искә төшереп,кемнәр икәнне.

Галәм кочагыннан йолып алып,
җирле кеше итү теләге,
хыялыйның канатларын тыеп,
гади кеше итә түгелме?

Яшел–зәңгәр дөнья киңлегеннән
Башым тартмыйм, әмма галәмгә
туры юлдан аермагыз, чөнки
мин иреккә сусыйм, иреккә!..

## Бүләк

Ярты гасыр соңга калып, гафу,
Мин бүгенгә үткәннәрдән «бүләк».
Заманадан артта калуыма
Таптым бугай акланырлык сәбәп.

Акланыйммы? Гаеп тагарсыңмы?
Әллә мине кабул итүеңме?
Каһвә ясап эчкән бер мәлендә
Уйла әле ялгыш кына мине.

Нигә, димә, гасыр чиген даулап,
Мин кап–кайнар каһвә булып, бары
Ургылам күк синең йөрәгеңә,
Ялгар өчен, чиктәш гасырларны.

Син күзләрдән укып аңлар кеше:
Чит күрүем бу «яңа» заманны!
Бер гаебем бар тик, мин (аңла син!)
Ярты гасыр соңга калган бары…

Кулың белән миңа кагылудан
Илле елга кире чигенгән күк.
Мин үткәннән киләм,ә син мине
Кичә белән бүген чатында көт…

***

Чиксез галәм гизеп, ай эзләдем
Таба алмый шактый интектем.
(Ә башкалар кояш эзли иде…)
«Ай яктысы җитмәсме?!', – дидем.

Алар бар(ы)сы кояшка йөгерде,
Ә мин качтым кайнар нурлардан.
Көл калдырып яндырган кояшка
Юллар ачык, айга – ябылган.

Кояш балкый, аны табып була
Озак вакыт сарыф итмичә.
Ай яктысы тонык, төссез шул ул
Мөмкин үтү хәтта күрмичә.

Кояшҗылы, кояш артык якты,
Якынкилсәң, мөмкин пешәргә.
Айны эзлим, ай яктысы якын
Кояш юлын хәтта белсәм дә…

*3-нче урын*
***Илназ Закиров***

## Әфганстан

1989 ел, апрель, Әфганстан.
Атым Алмаз. Туган ягым Татарстан.
Монда дошман, монда яман, көчле сугыш,
Көндә үлем, тынычсызлык, кеше суеш.
Бу җирдә көн ничек үтә? Котың оча!
Мыштырдасаң шундук үлем килеп коча.
Һәр яңа көн кызыл канлы елга ага,
Дусларымны үтергәнче пуля чага.
Бинокльдан күзәткәндә тау башларын,
Канга баткан, кызыл, салкын, зур ташларын
Булсаң да син җитез, юләр яки батыр
Күргән галәмәттән җылы каның катыр:
Яшь гәүдәләр тау башында ятар аунап,
Мыскыл итәр дошман җансыз тәнне кыйнап.
Утырырлар хәшәрәтләр муен кисеп.
Әллә каян канның исен була сизеп…
Кеше белән дуслашырга бик тә кыен,
Дуслашасың – тиздән аның кис[е]лә муен.
Егетләрнең гомерләре яшьләй бетә…
Аларны бит өметләнеп Ана көтә!
Таныштым бер егет белән – Илдус атлы,
Әйбәт малай, акылы да җиде катлы.
Разведкага кичә китте тау ягына
Бүген исә һәркем аны нык сагына.
Йоклаганда үлгән дуслар керә төшкә
Күз яшьләрен чыгармаска түзәм көчкә.
Туган якка кайтырмынмы исән–имин?
Кызганычка бу сорауга җавап белмим!
Әфганстан! Күпме кеше гом[е]рен өздең!
Гәүдәләрдән җансыз таулар син төзедең!
Әфганстан! Кайчан бетәр синдә сугыш?
Әфганстан! Кайчан бетәр кеше суеш?!

## Соңгы сулыш

Кояшлы көн... бик караңгы...
Сулышым, күрәсең, булыр соңгы!
Көн дә эссе... тән суына...
Сизә җаным – Әҗәл куана.
Күреп калдым – мылтык, ялкын...
Бик авырта... бигрәк салкын.
Каты ташлар мамык сыман,
Уйлар исә – куе томан...
Көч калмады, хәлем бетте.
Әллә гомерем юкка үтте?!
Йомып булмый – күзләр ачык...
Карап тора «кара карчык»...
Урап алды кара ятьмә...
Әткәй... Әнкәй, мине көтмә!
Шушы булыр соңгы сулыш...
Каһәр суккан юньсез сугыш...

...
Эчке уйлар саташтыра.
Куе томан сыман
Адаштыра яман.
Булышмый вино,
Шәраб, кызык кино.
Боздай көч эри.
Эчтә нидер чери,
Таркала кебек сөяк
Үзем мин куптән өрәк –
Типми бит инде йөрәк.
Эчке уйлар саташтыра.
Уйлана торгач, салгач
Акылдан шаштыра, калгач
Үзең генә бүлмәдә.
(Терелмә син, үлмә дә!)
Барлык җир кипкән – коры,
Дөньяның төсе соры.
Тынычсызлык бербөтен
Эчкә алына төтен.
Мәхәббәттән бик читен...

## Тик бер сүздән

Тик бер сүздән
Гөрләвектәй акты яшьләр күздән
Өметләрне ватып.
Йөрәк туктап, боздай катып
Өзде җанны...
Йөрешеннән туктатып сыек канны.

Тик бер сүздән,
Моңсулыкка кертеп тездән,
Бетте агып
Бәхет төсе йөздән... бушлык тагып,
Сагыш кагып...
Яңа туган гыйшык хисен кара ягып.

Тик бер сүздән
Агып төште ачы яшьләр күздән –
Мәхәббәтне аңлатканда
«Юк», – диюдән... «юк», – диюдән яратканда.
Язгы җылы таң атканда...
Сине генә яратканда!

## Бабай белән малай

Бер бабайга сорау бирә сабый:
Бабай, нәрсә ул картлык?
Аптырамыйча әйтә өлкән абый:
Улым, ул бик зур шатлык!
Аптырый бала – кем булсын шат?
Катып беткәч күптән муеннар,
Кем шатлансын булмагачтын 10 кат
Сикереп, йөгереп уйнап уеннар?
Ничек инде, бабай, сөенергә?
Томанлана торгач уйларың,
Сөенергә түгел, кирәк көенергә
Сызлаганда йомшак кулларың!
Әйтә бабай: Улым, миңа 80 күптән –
Йөрим шома басып аякка!

Мәгънәсе юк көенергә «чүптән»
Таянсам да кайчак таякка.
Мин картаеп белдем тормыш ямен,
Оныкларның күрдем йөзләрен,
Тоя алдым озын гомер тәмен,
Үткән юлда калды эзләрем!
Зарланырга миңа булыр гөнаһ –
Яшәп җиттем тирән картлыкка.
Рәхмәт яусын сиңа бөек Аллаһ!
Ирештергән өчен безне шатлыкка.

# Чәчмә әсәр



ЧӘЧМӘ ӘСӘР
12-14 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Айлия Хаҗиева***

## Тылсымлы умырзая

Айсылуны йокысыннан кояшның җылы нурлары уятты. Ул теләмичә генә күзләрен ачты да, як–ягына карады. Бүлмәне кояш яктырта, әйтерсең лә, Айсылу алтын төсләр иленә килеп эләккән. Аның тәрәзә янына йөгереп килеп, урамдагы матурлыкны күрәсе килде. Әмма тәрәзә янына бара алмады Айсылу, кышкы гүзәллекне күрмәде…Чөнки 6 яшьлек Айсылуның аяклары авырта, шуңа кечкенәдән инвалид арбасында йөри. Кыз язмышына һич үпкәләми, һәр туган көнгә шатлана, тормышның матур ягын күрә белә.

Менә бүген дә инвалид арбасына утырырга тырышты. Килеп чыкмагач, моңаймады, яраткан әнисен ярдәмгә чакырды.

– Әнием!

Бүлмәгә Айсылуның әнисе керде. Кызын күргәч, аның йөзендә борчулы елмаю барлыкка килде. Мәликә апа берсүзсез генә Айсылуның инвалид арбасын этеп алып барды.

– Әнием, минем өчен борчылма! Менә берәр кышкы аяз көндә син шушы тәрәзә аша урамга карарсың. Анда бәсле миләш агачлары янында, зур–зур кар өемнәре арасында бер кызны күрерсең. Ә ул кыз мин булырмын! Мин тәрәзә каршына йөгереп килермен дә, сиңа сәлам бирермен. Менә шул вакытта без икебез дә бик бәхетле булырбыз. Шулай бит, әнием?

Әни кеше кызына карап:

– Әйе, кызым, нәкъ шулай булыр.

Кышкы көннәр ничек кенә аяз, матур булмасын да, кояш нурлары астында кар ничек кенә ялтырамасын, Айсылу күңеле белән гел язны көтте. Чөнки язгы табигать, сафлык, җылылык аңа өмет бирә иде. Беренче язгы чәчәкләрне күрүгә, аның торып йөреп китәсе килә, әмма булмый шул. Нәрсәне дә булса зарыгып көткәндә, вакыт бигрәк әкрен үткән сыман тоела икән ул. Айсылу да көн саен әнисенә бер үк сорауны бирә: «Әни, яз җиттеме инде?» Ниһаять, бүген ул һәркөн биргән соравына «әйе» җавабын

алды. Белсәгез сез аның ничек шатланганын! Бәхетеннән башы күккә тия язды! Айсылу әнисен урамга чыгарга чакыра башлады. Әмма әнисенең эше бик күп иде, барын да эшләп бетерергә тырышса да – өлгермәде, караңгы төште.

Кичен Мәликә апа Айсылуга умырзаялар турында китап укыды. Рус телендә «подснежник» дип аталган бу чәчәкнең дөньяда бик аз калганын белде Айсылу. Явыз кешеләр бу чәчәкне өзеп бетергәннәр. Әнисе бик арыган иде, шуңа китаптагы рәсемгә дә, аянычлы һәм кызыклы мәгълүматка да игътибар бирмәде, укыды да укыды. Ә Айсылу әнисен кызыксынып тыңлады, умырзая турында бик күпне белде. Рәсемнәр буенча бу чәчәкнең нинди икәнен исендә калдырды. Умырзаяның кар сыман ап-ак таҗларына соклана–соклана, кызчык йокыга китте.

Икенче көнне алар урамга чыктылар. Кояш кар өемнәрен ялтырата. Әмма алар эрергә җыенмыйлар әле. Күк йөзендә бер болыт әсәре дә юк, зәп–зәңгәр аяз һава. Яз килүнең билгеләре булмаса да, Айсылу күңеле белән нидер сизә иде. Йомшак җил исә, җепшек кар кояшның якты нурлары астында алмаз ташлар сыман ялтырый. Бу бит инде язның беренче билгеләре! Ә тиздән яз Айсылуның хыялындагыча булыр. Ямьле, җылы, матур, чәчәкле, кояшлы, гүзәл яз... Ә иң мөһиме – өметле. Ә бәлки, Айсылу нәкъ менә бу язда йөреп китәр, бәлки берәр тылсымлы хәл булыр... Бары ышанырга, өметләнергә кирәк. Айсылуның башына төрле матур уйлар килде.

– Кызым, Айсылу, кара тегендә нинди матур чәчәк! – дип, Мәликә апа таҗлары тамчыга охшаган якындагы чәчәккә төртеп күрсәткәч, Айсылу уянып киткәндәй булды. Анда, карлар арасында, кара җир чыккан иде. Ул җирдә, кара рәсемдәге ак тап шикелле, бер гүзәл чәчәк үсә. Ул кар кебек ап–ак чәчәк Айсылуга таныш булып күренде, шуңадырмы, ул елмайды. Әнисе, кызының елмаюын күреп, шатланды. «Хәзер мин сиңа аны өзеп алып киләм», – дип чәчәк янына йөгерде. Мәликә апа чәчәк янына килеп җиткәндә, Айсылу бу чәчәкнең исемен искә төшерде. Умырзая! Дөньяда бик әз калган бит бу чәчәк! Әнисе, кулын умырзая янына сузганда, Айсылу: «Әнием, өзмә умырзаяны!» – дип кычкырып торып басты. Мәликә апа чәчәктән кулларын алды да, кызына карады. Айсылу әнисенә таба килә иде. Атлыймы, әллә очамы? Әни кеше үз күзләренә ышанмады. Айсылу дөньясын онытып әнисе янына йөгерә иде... Кызчыкның көчсез үсемлекне бик тә саклап каласы килде.

– Әнием, умырзаяны өзмә, ярамый, – диде Айсылу.

– Кызым, син йөреп киттең бит! – дип әйтергә чак көч тапты бәхетеннән елый башлаган ана.

– Әни, тот мине, егылам бит, –диде Айсылу.

Әмма ул егылмады. Айсылу әнисенең җылы кочагына сарылды да, үзен шатлыгыннан күкнең җиденче катында хис итте. Таҗларын аска төшереп торган умырзая өскә күтәрелде һәм кояшның җылы нурлары аңа таба йөгерде. Ә бәлки бу Айсылуның уйларындагы тылсымлы чәчәк булгандыр? Хыялый кызга өмет биреп торган яз тылсымлы чәчәк алып килгәндер.

Айсылу белән Мәликә апа өйгә кереп киттеләр. Капка төбендә инвалид арбасы утырып калды. Ул бу гаиләгә кирәк түгел иде инде. Айсылуның хыял–өметләре бүген чынга ашты. Ә өметләнсәң, бөтен теләкләрең чынга аша! Киләчәгеңнең яхшы булачагына ышанып яшәргә кирәк.

## Үпкәләдем галимнәргә!

Дөресен генә әйткәндә, мәктәп укучылары – бик сабыр һәм тырыш халык ул. Караңгы кышкы иртәләрдә, хәтта уңган кояш та йокысыннан торырга иренеп ятканда, балалар, букчаларын тотып, белем алырга ашыгалар. Юлда, шук салкын һава битләрне чеметеп, йокыны куып җибәрмәкче була. Башка кереп, кисәк–кисәк искән суык җил уйларны чуалта, бүген булачак контроль эшләрне искә төшерә, каникулларны сагындыра.

Мәктәпкә берәм–берәм, борыннарын мышнатып, балалар агыла. Гардеробка керер алдыннан, алар Яңа ел хөрмәтенә бизәлгән чыршыга сокланып карыйлар. Тик сыйныфларына керүгә, чибәр чыршы онытыла. Сигезенчедәге Галиевнең дә шул хәл. Геометриядән булачак контроль эш аны күбрәк борчый. Галиев һәм аның кебекләр – үтә кызык халык. Үткән параграфларны кабатлап утырыр урынга, алар үзләренчә грандиоз план коралар: кем кемгә булышасын бүлешәләр, шпаргалкалар ясап маташалар, үзләре һаман нидер сөйләшәләр. Иң мөһиме: укытучы күрмәсен.

Кыңгырау тавышы укучыларны сыйныфларга кертеп утыртты һәм мәктәптә тынлык урнаштырды.

– Укучылар, датаны язабыз, контроль эшнең темасын язарга онытмагыз, – дигән сүзләр геометрия дәресен башлап җибәрде.

Иң арткы партада дәфтәр актарып утырган Галиевнең күзләре укытучының карашы белән очрашты.

– Җаваплар дәфтәргә язылып куелганмы әллә, Галиев? – дип сорады укытучы апа.

– Бәлки язылгандыр, апа, – дип, Галиев дәфтәрен япты, тик кирәкле битенә карандаш кыстырды.

Галиев беренче эшне игьтибар белән укып чыкты. Фалес теоремасын дәлилләргә кушкан. Кем икән инде ул, Фалес дигәннәре? Таныш фамилия кебек. Галиев башын эшләтте, бөтен булган һәм булмаган белемнәрен искә төшерергә тырышты. Башындагы шул белемнәре аны китапны ачырга өнди иде. Галиев укытучыга күтәрелеп карады: нидер яза. Шыпырт кына китаптан Фалесны тапты. «Ә–ә, хәтерлим. Менә гел шулай: китапны ачып карагач кына, укытучы апа сөйләгәннәр искә төшә!» – дип уйлады Галиев. Фалес Борынгы Грециядә яшәгән икән. Өчпочмаклар охшашлыгы турындагы теореманы барлыкка китергән.

«Фалес, Фалес, – дип кабатлады Галиев, галимнең китаптагы портретына күз салып, – борынгы заманнарда яшәгәндә, теоремалар сиңа нәрсәгә кирәк булды икән? Ул вакытта башыңны катырып утырмасаң, син бүген, кимендә, шушы класстагы ундүрт баланы бәхетле итәр идең. Бәлки, син теоремаңны уйлап тапмасаң, бүген контроль эш булмас иде,» – дип уйлады малай.

Галиев, Фалестан җавап көткәндәй, галимнең сурәтенә җитди караш ташлады.

«Нәрсә, әйтергә сүзең юкмы? – малайның һәм галимнең «әңгәмәсе» һаман куерды, һәм Галиев, ирен чите белән елмаеп: – «Фалес, әгәр син чыннан да акыл иясе булсаң, өчпочмаклар охшашлыгын бик җайлы һәм дөрес юл белән билгеләр идең. Гап–гади линейка булышыр иде сиңа! Һәр фигураның өчешәр ягын үлчәп, тигезлеген исбатласаң, сиңа да, миңа да рәхәт булыр иде: сиңа, башыңны авырттырып, теорема уйлап чыгарырга туры килмәгән булыр иде, ә мин контроль эштә җәфаланып утырмас идем,» – диде.

Фалес белән тарткалашып туйгач, Галиев, укытучы күрмәгәндә, китапны шыпыртын гына япты. Геометрия дәресендә ул үзенең яраткан гадәтенә тугры калды: уйларына, хыялларына бирелеп утырды да, дәрес бетәргә ун минут калганда, мәсьәләләрне килделе–киттеле эшләп куйды. Шулай узды бу чирекнең соңгы геометрия дәресе. Контроль эшне начар эшләгәненә Галиев борчыл-

мады. «Икеле алсам да, чиреккә барыбер өчле чыгачак,» – дип уйлады ул.

Геометрияне җене сөймәсә дә, бу елны Галиев биология дәресләрен ярата башлады. Сигезенче сыйныфта анатомия бүлеге өйрәнелә икән. Җидедә булганда хайваннар дөньясын үзләштерү теңкәсенә тисә дә, кешенең, ягъни үз-үзеңнең, организмны өйрәнү бигрәк кызыклы икән! Ләкин бу фәнне яратса да, аны ятлап утыруны Галиев кирәксенмәде.

– Узган дәрестә без кеше иммунитетын үттек, укучылар. Эчтәлекне безгә Галиев сөйләячәк!

Эх, менә нәкъ шушы сүзләрдән соң балалар дәресләрне, мәктәпне яратмаска мәҗбүр булалар! Бер караганда, узган дәрестә шундый кирәкле тема үтелгән, укытучы сөйләгән мәгълүматны Галиев кызыксынып тыңлап утырган, ләкин бүген ул онытылган бит инде, иммунитет дигәннәре хәтердән чыгып очкан. Нигә укытучылар дәрес башлануга шул рәвешле сорау алалар икән? Белмәгәнне, өйрәнмәгәнне сизмиләр микән?

– Галиев, без сине тыңлыйбыз.

– Узган дәрестә без иммунитет темасын өйрәндек, – дип башлады сүзен Галиев һәм туктап калды.

Уку – энә белән кое казу, диләр. Галиев өчен шушы минутларда белмәгән, өйрәнмәгән нәрсәне башкаларга сөйләү – нәкъ энә белән кое казу иде.

– Ярар, Галиев. Безгә иммунитетны өйрәнә башлаган ике шәхесне ата.

Класстагы «отличник»лар кулларын өскә күтәреп:

– Апа, апа, мин, – диештеләр. Аларны Галиев килеп терәлгән хәл борчымады, чөнки аның кебекләрнең теманы белмәве – яңалык түгел.

Шулай да берсе, мескен Галиевне кызганып:

– Йөз егерме бер, – дип пышылдады.

– Галиевнең икелесен бүлешәсегез киләме? – дип кисәтте укытучы.

Галиев тиз генә китапның шул битен ачты һәм ике фамилияне күрде. Үзенең ораторлык талантларын кулланып сөйләргә тотынды:

– Теге дәрестә без ике атказанган шәхес белән таныштык. Алар борынгы вакытларда, корольләр заманында яшәгәннәр. Бе-

ренчесе – Эдуард Дженнер – бик акыллы һәм тырыш кеше булган. Ул иммунитетны иң беренчеләрдән өйрәнә башлаган. Икенче галим – Луи Пастер. Ул шулай ук бик белемле булган. Пастер Э. Дженнерның эшен дәвам итеп, иммунитетны өйрәнгән. Әлеге галимнәр җәмгыятькә зур файда китергәннәр. Бу эшләре өчен аларны кешеләр яратканнар һәм рәхмәтле булганнар.

– Конректрак, Галиев, конкретрак. Пастер белән Дженнер нәрсә уйлап тапканнар?

– Э–э, иммунитеттыр инде…

– Галиев, син нәрсә? Синең әйтүеңчә, Дженнер белән Пастерга кадәр кеше организмында иммунитет булмаганмы?

– Вәт, башны катыра, – дип эчтән мыгырданды Галиев һәм кинәт башкалардан «вакцина» сүзен ишетте. – Вакцина! Апа, алар беренче вакцина уйлап тапканнар.

– Укымыйча йөрсәң дә, колагың яхшы ишетә, Галиев, – дип көлемсерәде укытучы. – Ләкин исеңнән чыгарма: имтиханда сиңа беркем дә җавап пышылдап утырмас! Йә, вакцина нәрсә ул? Аны нәрсә белән ашыйлар?

Биология укытучысы балаларны кайчакта шулай котыртып куйгалый иде.

– Вакцина – бик кирәкле әйбер. Ул иммунитетка булыша. – Малай берни белмәсә дә, югалып калмады. – Аны Дженнер белән Пастер уйлап тапкан. Вакцина – ул шундый дару.

– Тукта әле, вакцина нәрсәләрдән тора?

– Апа, аны кем белгән инде! Ниндидер дару шунда.

– Галиев, дәфтәреңдә билгеләмә язылган: «вакцина – препарат из ослабленных микробов».

– Нәрсә?! – Галиев гаҗәпләнде, хәтта аның ачуы чыкты. – Ужас! Мин вакцинаны салкын тиюдән саклаучы дару дип торам. Ә аның эчендә микроб, вирус икән. Менә сиңа мә! Белә торып агу кадыйлар! Мин уколлардан бик куркам, фельдшер кабинетына кергәндә котым оча. Әни ясатырга кушкач, авыртулардан саклый дип үгетләгәч кенә ясатам прививканы. Ел саен ясатам һәм ел да икенче көнгә үк температура күтәрелә.

– Галиев, нишләвең бу? Тынычлан, зинһар. Син ялгышасың.

– Юк, апа, Дженнер белән Пастер ялгышканнар. Вакцина уйлап табып, кешеләрне микроблар ярдәмендә дәваламакчы булганнармы?

– Галиев, утыр. Миннән яхшы билге көтмә. Параграфны укымагач, берни аңлый алмагансың. Вакцина эчендәге начар йогын-

тысы әз булган микроблар белән көрәшеп, организм көч туплый һәм авыруларга каршы торырга әзер була.

Укытучының сүзләре Галиевнең бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыкты, чөнки малайның акылы, гомумән, фәнни сөйләмне озак эшкәртә иде.

Алда – Яңа ел каникуллары, бүген укуның соңгы көне, шуңа ул бик тиз үтеп китәргә тиеш дип уйлады Галиев иртән. Ләкин геометриядән контроль эш һәм вакциналар аның күңелен төшерде. Җиденче дәрес сыйныф сәгатенә туры килде. Фалес, Дженнер, Пастер белән тарткалашып, Галиев арган иде. Сыйныф сәгатендә төрле һөнәрләр турында сөйләштеләр, Галиевтан булачак профессиясен сорадылар.

– Белмим әлегә, – дип җавап кайтарды ул, – ләкин мин, тәгаен, галим булырга җыенмыйм. Теоремалар, вакциналар уйлап чыгарырга кирәкми, мәктәптәге балалар башларын катырып утырмасыннар, үпкәләдем әле галимнәргә! Алар акыллы булып йөргәнгә, без газап чигәбез, – диде Галиев.

Мондый җавап укытучыны да, укучыларны да гаҗәпләндерде.

Тәрәзәләр аша мәктәп эченә керергә атлыгып торган суык кына бу җөмләләргә һич сәерсенмәде, чөнки ул, Галиев белән беррәттән, Фалес, Дженнер һәм Пастер белән танышты. Кешеләр пыяла тәрәзәләрне пластикка алыштыргач, хәзер кышкы суыкның бер эше юк. Элегрәк ул кыш көннәрендә пыяланы

Чибәрләндереп, төрле бозлы бизәкләр ясый иде. Ә пластмасс тәрәзәләрдә бизәкләр килеп чыкмый, шуңа ул кеше тормышын күзәтә. Менә бүген суык Галиевне күзәтте, ә тиздән малай кайтыр юлга чыгар, шул вакытта суык аның бияләйләренә кереп бармак очларын чеметер, башлыгын салдырып, Галиевнең уйларын чуалтыр, һәм борынгы заманнарда яшәгән галимнәрне суык җил малайның хәтереннән үзе белән бергә алып чыгып китәр.

*2-нче урын*
***Азалия Мирхәйдәрова***

## Яшәү өчен көрәш

Көзнең соңгы көннәре якышлашты. Табигатьтә үзенә күрә бертөрле көрәш бара. Нәрсәдә чагыла дисезме көрәшне? Ә-ә-әнә, соңгы яфраклар яшәү өчен көрәш алып бара. Кышның беренче билгеләре күренә башлады: ачы Җил чыкты. Ул яфракларга каршы сугыш ачты. Җил бик көчле, ә яфраклар мескен, көчсез. Алар тырыша-тырмаша, бар көчләрен җыеп, Җилгә каршы көрәшкә омтылалар. Үләселәре килми аларның; яшисе, тормыш тәме, җәйге Җилнең иркәләве астында ләззәтләнәселәре килә. Алар аптырыйлар: әле генә җәй иде бит, ник шулай кыска булды соң әле бу? Яфраклар ярдәм көтә. Ә ул юк... Димәк, бары үзеңә генә ышанырга кала.

Ә явыз Җил аларны һаман кыерсыта, кыйный, рәнҗетә. Ул аларны һич кенә дә кызганмый: өзеп ала да һава буйлап куып йөри. Хәлләре беткәч, җиргә ата. Яфраклар шулай берәмтекләп һәлак була.

## Каргыш

Элек, бер хан күккә менгән, ди. Ул ханның исеме булган, ди, Айхан. Аның булган, ди, санап бетергесез кызлары. Кызлары да күккә менеп йөри торган булганнар. Күк патшасы – Кояш күрмәгәндә генә, әлбәттә. Бу вакытта төн була. Кояш йоклый. Айның кызлары, күккә менгәндә, йөзләрен яулык белән каплый торган булганнар. Ни өчен дисезме? Чөнки айның кызлары шулкадәр матур булганнар: йөзләре алтын кебек җемелдәгән, ди. Кояш тау башында йоклаган. Ул черки кадәр якты булса да уянган, сикереп торган, бар нәрсәдән дә көнләшкән. Ай, аның уенча, аңарга буйсынырга тиеш булган.

Менә беркөнне Ай һәм аның кызлары күккә менгәннәр. Кызлар Җил–батыр белән уйный башлаганнар. Аларның матур йөзләрен күрер өчен, яулыкларын ачканнар. Бу чибәркәйләрнең йөз яктысына Кояш уянып китә һәм ул Айны:

– Гомерең буе күктә калсаң иде, – дип каргый.

Ай аптырап тормаган, аңарга җавап кайтарган.

– Ярар, мин килешәм, ләкин син дә, көнче, үзеңә җәза ал: гомерең буе ян! – дигән, имеш.

Каргышлар чынга ашкан: Ай күктә калган, ә Кояш гомере буе күктә яна икән. Ә Айның кызлары җиргә төшкәннәр. Ләкин Ай аларны җирдә, кешеләр арасында, калдырырга теләмәгән. Андагы вәхшилек, сансызлык аның күңелен кайтарган. Ул аларны берәмләп, чәчләреннән тартып, күккә алып менгән. Ә Ай кызларының чәч эзеннән Киек каз юлы барлыкка килгән, ди. Бу кызлар тора–бара йолдызларга әйләнгәннәр. Җил–батырлар әле һаман да Йолдызлар белән уйныйлар, ди.

## Чын дуслык

Бәрәңге дусты Чик белән уйнагач йокларга ятты. Ул, күзләрен ачкач, бик матур чәчәк күрде. Бу матур чәчәк Эт эчәгесе иде. Ул кояш нурларында ялтырый. Бәрәңге, күзе төшүгә, аңарга гашыйк булды. Ул Эт эчәгесенә эндәште:

– Әй, чибәркәй, исемең ничек? Әйтсәң, танышыр идек.

– Минем исемем – Асыл.

– Я, сөйлә инде, Асыл. Кайлардан килдең?

– Мин ерак Африкадан, колорадо коңгызының канатыны утырып килдем, – дип алдашты Эт эчәгесе.Ул бернинди Асыл түгел, чынлыкта исә Сатлык иде. Ә Бәрәңге аңа гашыйк булды. Ул болай уйлады: «Мин дөньяның иң матур кызына гашыйк булганмын.» Ә ялганчы Асыл һаман сөйләнде дә сөйләнде:

– Мин бик арыдым, зинһар өчен, яфрагыңа утырып, ял итәргә рөхсәт ит.

– Ярар, ярар, җаным, – диде Бәрәңге. Ул бүтәнчә булдыра алмады. Мәхәббәт утында яна иде.

Атна үтте. Эт эчәгесе әкренләп Бәрәңгене чолгап алды. Бәрәңге күпме генә яктылыкка омтылса да, булдыра алмады. Ул инде әкренләп үлә барды.

– Үләм, үләм, яшисем килә. Төш зинһар, тамырларымны корытма. Бер генә тамчы булса да су бир, яктылыкка чыгар.

Ләкин аны бер кеше дә ишетмәде. Бары нәни Чик кенә дустын коткарырга тырыша иде. Ул Эт эчәгесенең яфракларына урала, абына- сөртенә. Менә-менә барып җитте ул. Бик зур авырлыклар

белән генә Эт эчәгесенең тамырын өзеп атты да егылып та китте. Бәрәңге җиңел сулап куйды. Ул чиксез рәхмәтле иде нәни дустына.

*3-нче урын*
***Илназ Билалов***

## Күтелмәгән бүләк

Бәйрәмгә әни белән апага бүләк әзерләргә булдым. Әле ярый, әни ул көнне авылга киткән иде. Уйларга вакытым булды. Алданрак әзерләнергә кирәк булган да бит! Кибеттән икесенә дә тартмалы конфет алырга була да, тик акча юк. Нишләргә инде? Башта апа турында уйладым. Акча сорап булмый, бакчада чәчәк юк. Нәрсә бүләк итәргә? Һич уйлап табып булмый. Уйлый торгач, открытка ясарга булдым. Бик зур итеп матур открытка ясадым һәм, эченә чәчәк тә кыстырып, апага бүләк иттем. Аңа бик ошады. Ә менә әнигә нәрсә уйлап табарга? Апа кибеттән, әнигә бүләк итү өчен, конфет алып кайтты. Мин аңа: «Әйдә шул конфетны икебездән бүләк итик әле», – дидем. «Юк инде. Үзең әзерлә!» – диде апа. «Сатлыкҗан син!» – дигәнемне сизми дә калдым. Мин инде елап җибәрергә дә әзер идем. Еласам, апа көләчәк инде. Түздем. Әнигә открытка ясарга утырдым. Нишлим соң? Бүтән бернәрсә уйлап таба алмадым.

Менә әни кайтты. Апа конфетын күтәреп чыкты. Җитмәсә, бик матур чәчәк букеты да алган булган. Ачуым килә, көнләшәм. Эх сине… Ә минем открытка гына. Әле ярый анысын ясап өлгердем. Минем дә әнигә гадәти булмаган бүләк әзерлисем килгән иде бит. Ник алданрак әзерләнмәдем икән, ә? Апаны да әйтер идем. Тагын елыйсым килде. Кеше көлдереп торып булмый, тиз генә киемнәремне эләктердем дә тышка атылдым. «Әгәр авыр уйлар басса, кәефегез бик начар булса, үзегезгә берәр эш табыгыз», – дип әйтә безгә психолог. Эш эшләп кенә хәл үзгәрмидер инде ул. Карап карыйк. Мин капкага сөяп куелган көрәкне алдым да кар көри башладым. Башта сукмакларны киңәйттем. Болай гына булмый әле бу. Кәефем һаман шул килеш. Зур ләгәнне тартып китердем дә, карны шуна төяп, урамга ташый башладым. Үзем шулхәтле тиз эшлим. Тирләп–пештем. Инде елыйсы килми. Апага үпкәм генә калды. Бу эш миңа ошап китте. Карны ләгәнгә өеп тутырам да урамга алып чыгып бушатам. Ишегалды чистара тора, урамда менә дигән тау өелә тора! Чана шуарга бер дигән була бит бу! Минем авызым ерылганнан–ерыла бара. Әни белән апа мине

эзләп чыкканда, ишегалды ялт иткән иде инде. Иң мөһиме, мин үзем кояш кебек балкыйм.

– Улым, кая киттең соң син? Әйдә, чәй кайнады,–диде әни.

– Уууф, сусадым.– дидем мин. Әни ишегалдын күреп шаккатты:

– Менә улым миңа нинди бүләк ясаган! Рәхмәт, улым. Күптән чистартасы бар иде инде бу ишегалдын. Хәзер рәхәтләнеп бәйрәм итсәк тә була инде, – диде әни. Иии, нишләп үземнең башым җиитмәгән соң моңа? Чыннан да, бер дигән бүләк бит бу! Алданрак уйлаган булсам, тагын әллә нәрсәләр эшләп өлгерә идем бит. Ярый. Әле соң түгел. Моннан соң нәрсә бүләк итим, дип баш ватмам инде.

Ул арада әти дә кайтып җитте. Бергәләп чәй эчәргә утыргач, мин әнигә открыткамны бүләк иттем. Аңа бик ошады.

15-18 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Айзилә Абдрахманова***

## «Лайк» бәласе

Аһ, шушы Ислам Саматовичны! «Тарихны өйрәнергә кирәк, балалар! Ул – безнең үткәнебез дә, киләчәгебез дә», – дип тукылдый да тукылдый! Су буе бер кирәкмәгән әйбер яздыра. Һаман дата, термин, дата, термин... Әйтергә онытканмын: әле Николай I һәм II, Пётрлары бар, Явыз Иван, Әби патша... Патша да патша, сугыш та сугыш... Бер тыңларлык кызыклы вакыйгасы юк. Кем әйтмешли, ат хәтле буе белән заводка эшкә бару урынына, мәктәпкә укытырга килгән, бу гәүдәсе белән ишеккә дә сыймыйдыр инде. Күзлеге дә бигрәк килешсез, карт бабайларныкы төсле. Дәрес буе сөйли дә сөйли, сөйли дә сөйли... Утырам инде шунда, «хәзер төшеп китәм» дигән башымны кулым белән терәтеп, аның күзлегенә карап. Тыныч кына аңлатсын иде тарихын, юк бит. Миңа бәйләнгән була: «Тырышсаң, укый аласың инде син. Башың эшли, ятларга, укырга гына кирәк, Миләүшә! Телефоныңны бераз читкәрәк куеп торсаң...» Аннары китә инде берәр сәгатьлек нотыклары... Әллә миңа бәйләнүдән рәхәт табамы соң ул? Аның миндә ни эше бар? Ни телим, шуны эшлим! Әле бит шул «Күзлек» миңа «еллык»ка өчле чыгарам, ди. Бөтен фәннән «4»ле, «5»легә генә укып, көндәлегемне бер «3»ле «бизәп» торсынмы инде хәзер? Менә, ичмасам, Фәрит Сабитович яхшы иде: ник бер сүз әйтеп карасын, тыныч кына дәресен аңлата, берәүгә дә дә бәйләнми иде. Пенсиягә чыгып кына әрәм булды абыебыз.

Аһ, шушы Ислам Саматовичны! Ел буе укымаганны, иртәгә ничек сөйлим инде, йә?! Юк, аңламыйм мин тарихны, бөтен җаным–тәнем белән күралмыйм! Кырык биш минут буе сөйли шул Иваннарын, Романовларын, ничек теле армыйдыр. Язып утыруның ни кызыгы булсын, шунда берәр мисал яки мәсьәлә чишәргә дә бирми бит ул!

Э-эх... Элегрәк без тарих белән дус идек бит. Фәрит абый киткәч, берара тарих дәресләрен укымый тордык, аннары яңа укытучы килде. Дәрес керми торган арада өйрәнгәннәрем дә онытылган. «Күзлек» килгәч, аның укытуын ошатмадым һәм та-

рих фәненә булган мәхәббәтем бөтенләй сүрелде. Аннары мин бу фәнне кирәк түгел дип саный башладым, укымадым. Бер карасаң, Википедия булганда, тарихны өйрәнеп утыруның ник кирәге бар? Ачасың да карыйсың…

… Интернет дигәннән… Әллә телефонда утырып алырга инде? Соңгы фоторәсемем ничә «лайк» җыйды икән? Бая телефоным сүнгән иде. «Инде зарядкасы тулгандыр» дип, телефонга килеп тотынган гына идем – күз алдымда, әлҗе-мелҗе килеп, вак-вак зәңгәрсу шакмаклар пәйда булды…

***

– Балалар, барыгыз да дәресне өйрәнеп килгәндер дип ышанам. Бүген кайберләрегездән телдән имтихан алачакмын. Темабыз «2000-2020 елларда бабаларыбызның көнкүреше». Әзерләнә торыгыз.

… Туктагыз, нинди бабалар?? Нинди 2020 еллар тагын?! Әллә бераз ычкына башлаганмы бу Ислам Саматович?!.

Тиз генә янәшәдә утыручы Илназга төртәм:

– Абый ни сөйли ул?

…Тыңламаган булып кылана…

– Илназ дим!?

– Нәрсә инде?! Ишеткәнсеңдер бит, ә?! Бәйләнмә әле! – дип тагын нидер язарга тотына.

«XXI гасырда безнең бабаларыбыз акыл ягыннан бераз үсә, баш мие күләме шактый зур була. Шуның белән бәйле рәвештә, алар берникадәр ачышлар ясый, примитив наносмартлары, ягъни алар телендәгечә әйтсәк, төрле компьютерлары, телефоннары була. Самолет, метро кебек транспорт чаралары да уйлап табалар…» дигән юлларны тиз генә партадашымның планшетыннан укып алдым.

Шулчак каршыбызда бернинди китап–дәфтәрләрнең булмавына, ә зур гына планшет барлыгына игътибар иттем. Планшет дип, бармаклар экран буенча йөрми, ә һавада эленеп торган хәрефләргә баскалый, галограмма диимме соң шунда.

«Мәктәп каян шулхәтле акча алды икән?!» – дип, бер гаҗәпләнсәм, сыйныфташларымның хәзерге заман кешеләрен «бабай» дип сөйләве мине бөтенләй сүзсез калдырды.

Нишләгән соң болар бүген?? Әллә миннән көләләр инде?! Аңлыйм: миңа тарихны белмәү килешми, тик бу кадәр кыланмыйлар инде!

Шулчак гел «ике»легә генә укучы, дәресләрдә посып кына утыручы Илдар кул күтәрмәсенме!!! Күзләрем шар булды! Сөйләп китте бу:

– XXI гасырда яшәүчеләрне бик надан, башсыз булган дип әйтә алмыйбыз. Ләкин алар югары акыл белән дә әллә ни аерылып тормаганнар…

Укытучы абыйга күзем төште, бик канәгать йөз белән башын селкеп утыра. Чыннан да, бераз «китә» башлаган, ахрысы… Ә сыйныфташым һаман сөйли:

– Ерак бабаларыбыз күбрәк белем алу, баш миләрен 100%ка эшләтү урынына χάος γύρωны (хаос гиро), ягъни ялкауланып, эшсез ятуны өстенрәк күргәннәр. Алар шул замандагы Инстаграм, Вконтакте, Твиттер, WhatsApp дип аталган социаль челтәрләрдә утырганнар. Анда фотолар куеп, лайклар җыеп, язышып һәм башка әйберләр эшләп вакыт уздырганнар. Иң популяр шөгыльләрнең берсе ниндидер песиләр турындагы яки башка тематикадагы кызыклы видеолар карау булган. Боларның барысы белән бөтен дөньяга танылу мөмкинлегенә өметләнгәнннәр….

Илдар бик күп сөйләде, «Күзлек» аның сүзен куәтләп дәвам итте.

– Ләкин әле бу гына түгел. Бабаларыбыз заманында сугышлар чагыштырмача аз булган. Ни өчен?.. Дөрес, алар көчле атом бомбасы уйлап тапканнар. Бер караганда, бу – зур ачыш, ә икенче яктан – бәла. Нишләп бәла, әйдәле, Миләүшә, сөйләп җибәр, – диде тарих укытучыбыз.

– Абый, Википедия бар ич, ачыгыз да карагыз, – дигән шаяртуымны укытучы яратмады, күрәсең, кашларын җыерды.

Үзем белгәнне тыкылдарга туры килде инде.

– Атом бик әйбәт, чөнки ул әллә нинди зур сугышларны булдырмый тора.. Коралыбыз бик көчле, Америка бездән курка.. Ә начар ягы…начар ягы… атом сугышы була калса, барыбыз да үләчәкбез, – дип әйтеп кенә бетергән идем, бөтен сыйныф, шул исәптән Ислам Саматович та шаркылдап көләргә тотындылар.

– Тукта инде, Миләүшә, нинди сугыш, нинди Америка тагын?! Утыр, «икеле», – дип, көчкә әйтте абый, көлүеннән туктый алмыйча.

…Шаккаттым!.. Юк, билгегә түгел, ә сыйныфның көлүенә… Әллә бүген тагын да миңгерәдемме икән?!. Юк-юк… Дөрес сөйләдем бит инде?!..

Дәреснең калган өлешендә күктән төшкән кеше кебек утырып чыктым. (Дәрес тә артык озын иде бүген, әллә техничка апа тәнәфес бирергә онытып утырамы?) Күп сөйләделәр: кешеләр, «эшче һөнәрләр» дип юләрләнеп, фәнне үстерә алмаганнар, бик надан булганнар, имеш…

Ахыр чиктә түзә алмадым, торып бастым да:

– Ислам Саматович, җитте, бик «кызык» булды спектаклегез! 45 минут буе әкият тыңлыйм, тарих кайда соң монда?! Миннән көләсезме соң сез?! Урамда XXI гасыр, аңлыйм, ләкин бу маскарад өчен генә мәктәп шундый гаджетлар сатып алдымы? Туктатыгыз уеныгызны!» – дигән идем, бөтен класс тагын шаркылдап көләргә тотынды.

…Нәрсә соң бу??? Әллә кичә соң ятуым ярамады микән?! Әллә миннән кеше көлкесе ясарга тырышалармы?!

Шулчак дәрес буе бик канәгать утырган укытучының кашлары кинәт җыерылды:

– Миләүшә, белмисең икән, тыңлап кына утыр! Бая «Америка» дип кеше көлдердең, хәзер әллә кайчангы гасырны «бүген» дип сөйлисең. Алдагы дәресләрдә өйрәнгәнне тагын бер кат кабатлыйм. Без 4720 елда яшибез, моннан 1500–2000 еллар элек Җирдә зур катастрофа була: ялгышлык беләнме, әллә юкмы, ләкин син әйткән бомба шартлый һәм кешелек юкка чыга. Җир планетасы икенче Марска охшап кала, ләкин без аны кире үз хәленә кайтара алдык. Чөнки бомба шартлаганчы ук, кешеләр Айда яши башлаган була инде. Без, Айда яшәп исән калган бабаларыбызның оныклары, туган планетабызга кайттык. Яңа эра башланды… Боларны әллә кайчан өйрәндек бит инде, Миләүшә…

… Бомба, яңа эра, Айда тормыш… Ә Николай I, II, Пётр патша кайда? Явыз Иваннарны бүтән өйрәнмибезмени инде??? Ә Путин нишләде? Ул һаман президентмы соң әле?..

… Минем башым чатный, шул ук вакытта мең дә бер сорау тынгы бирми. Ә бөтен кеше шырык–шырык көлә… Янә башым әйләнергә тотынды, күз алдымда тагын теге зәңгәрсу шакмаклар бии башлады…

***

… Уянып киттем… Палата тулы врач, авыз–борынымда ниндидер көпшәләр, кулларыма тагын әллә ниләр тоташтырганнар… Ток бигрәк каты суккан икән!

… Эх, Сез, Ислам Саматович, «атом» дигән буласыз. Ә мин бит кичә Вконтактедагы фотосурәтемдә ничә «лайк» булганын гына

карамакчы идем... Мин исән, ә айфоным... айфоным үлгән... Димәк, Википедия дә минем өчен бүтән юк. Хәзер тарихны өйрәнергә дә вакытым күп була инде. Бәлки, бу – яхшыгадыр да: киләчәк буын безне надан булган, интернеттан башка берни дә белмәгән дип уйламасын әле.

... Ислам абый, киләчәк буын! Көтегез, күрсәтәм әле мин сезгә!

## Киелмичә калган туфлиләр

...Чулпан үзен зур кыз диеп саный инде. Тагын дүрт айдан аңа тугыз яшь тула. Ул кул астына бик иртә керде: әти–әнисе эштә булганда, ашарга да пешерде, кечкенә энесе белән сеңлесен карау да аның өстендә иде.

Бүген әти-әнисе Казанга китте, шуңа өйдәге бөтен эшләр Чулпанга калды. Әти-әнисе шулай берәр җиргә китсәләр, балаларга һәм өйгә күз-колак булырга дип, авылның икенче башында яшәүче үзләренә ботак очы туган тиешле Ерак әбине чакыралар иде. Бүген дә Ерак әби килде.

Кич җитте. Энесе белән сеңлесе йокларга ятты, ә Чулпан, йокламыйча, әти–әнисен көтте.

Алар бик соң гына кайтты, балаларына күп итеп күчтәнәчләр дә алганнар иде. Сеңлесе Айсылуга – зәп-зәңгәр күзле, алсу күлмәкле, зур матур курчак; энесе Камилгә – үзбушаткыч машина, ә Чулпанга – зәңгәрсу сандалилар һәм аксыл-көрән бизәкләр төшерелгән шоколад төсендәге туфлиләр. Кыз, сандалиләрен киеп, күбәләктәй очып-очып биеп тә күрсәтте, ә үзе, ялт-йолт килеп, бөтен бүлмәгә нурлар сирпеп торучы туфлиләрдән күзен алмады. Ниһаять, әнисе туфлиләрне сузды: «Ә хәзер боларын киеп кара инде, кызым. Кысан түгелләр микән?» Чулпан әнисе кулыннан туфлиләрне җәлт кенә тартып алды да киеп тә куйды. Алар шундый матур һәм килешле иделәр. Чулпан үзен тагын да үсеп киткән кебек тойды: башын горур тотып, шак–шык басып, бүлмә буйлап йөренде; тыпырдый–тыпырдый биеп тә алды. Аның моңарчы сандали кигәне бар, ә туфли киюе – беренче, шуңа күрә бу хис аның өчен аеруча тансык иде.

Әти-әниләре бик арып кайткан иде. Шуңа күрә, чәй эчеп алгач, әтисе йокларга кереп ятты, ә әнисе, күчтәнәчләр төяп, Ерак әбине өенә озатырга дип чыгып китте. Чулпан өстәлләрне җыештырды, савыт-сабаны чайкап куйды. Әни кайткач, тагын бер утырып

чәй эчәрбез диеп, газ плитәсенә чәйнекне куеп җибәрде. Үзе, туфлиләрен киеп, тагын берничә мәртәбә бүлмәләрне әйләнеп килде. Аннары моңа гына риза булмыйча, чоланга чыгып китте. Анда башкаларны уятам дип куркасы юк иде: рәхәтләнеп тыпырдап биеде; болдыр баскычлары буйлап, шак-шок басып, бер менде, бер төште... бер менде, бер төште... Чулпан үзенең иртәгә ничек мәктәп коридоры буйлап баруын, сыйныфташларының бу туфлиләргә карап соклануын күз алдына китерде. Туфлиләрен салгач та, аерыласы килмичә, аларга озак кына карап торды, һәрбер бизәген җентекләп тикшереп чыкты, яратып күкрәгенә кысты да зур саклык белән туфлиләрен идәнгә куйды. Зәңгәр сандалиләр дә туфли янәшәсенә урнаштырылды. Аннары Чулпан, аш бүлмәсендәге утны сүндерде дә йокларга кереп ятты. Бераздан әнисе дә кайтты. Өйдә утлар сүнгәч, барысы да йоклагандыр дип, ул да шыпырт кына йокы бүлмәсенә кереп китте. Ә газ плитәсе өстендәге чәйнек әкрен генә кайнап калды...

ДӘВАМЫ БАР

*2-нче урын*
***Алинә Хәбибуллина***

## Ак бәрән, кара бәрән

Һай кыздыра да соң бу кояш! Тәннәрне пешереп, керфек очларына кадәр үрмәли. Якты нурдан авырайган күз кабакларын һич күтәреп булмый. Апрельнең юеш көннәреннән соң мондый коры кызу көннәр тансык булса да, артык бәхет шатлык китермәгән кебек, бу эссе дә тәмам үзәккә үтә. Күләгәгә ышыкланыр урының булса – бер хәл, тәрәзә аша сыйныф эченә тулган нурлардан парта артына качып булмый шул. Бу кызуда аркадан тир тамчылары тәгәри. Егетләр, әнә, түзә алмый, кәчтүмнәрен урындык аркасына элеп куйганнар. Ап-ак күлмәктән калып, ромашка таҗлары шикелле төрле якка сибелгәннәр. Кулларда китап-дәфтәр: барысы да йөзләрен күләгәгә качырырга телиләр. Кайберәүләр, геометрия теоремалары, физика формулалары кагыйдәләре язылган дәфтәр битләрен бөкләп ясаган җилләткечне җилпеп, хәлләрен җиңеләйтергә тырышып утыралар. Ә укытучы әллә инде юри үрти, әллә чынлап йончыган укучыларның хәлен аңламый: «Бүген яңа тема үтәбез, дәфтәрләрне ачыйк»,– дип күңелгә ике потлы гер сала. Яз вакыты бит инде, кемнең мондый чакта укыйсы килсен! Биш көн рәттән сарык көтүендә йөргән Инзиләгә этисе: «Дәресләрең күп калды, яхшылап әзерләнеп бар»,– дип ныклап әйтеп җибәрде. Укыган кеше генә максатларына ирешә ала дигәнне еш ишетеп тора ул болай да. Дөресен генә әйткәндә, үскәч, көтү куып йөрисе килми аның бер дә. Биш көн буена кайнар кояш астында чәчләрне, йөзләрне пешереп йөрү бер дә рәхәт булмады, монда мәктәптә түбә астында утырасың ичмасам. Көтүлектә йөрүнең ни авырлыгы бар диючеләрнең үзләрен көне буена ачык һавада йөртәсе иде. Аркадагы авыр букчаны кечкенә иңнәреңдә кичкә кадәр күтәреп йөртүе шактый авыр булуын бик яхшы аңлады Инзилә. Каләмгә үрелгәндә дә кулларына килограммлы герләр эленеп куелган кебек хис итә ул. Болында борын төрткән яшь үлән–чәчәкләрне таптап, өенә таба качу ягын караган сарык–бәрәннәр артыннан сулыш кабып йөгерүе дә шактый хәлдән тайдыра. Ярый, болары көтү көне белән бергә үтеп тә китте ди. Соңыннан, җылы юрган астына чумып, авырайган

башны йомшак мендәргә терәгәч, күз алдыннан сарыклар үтә башлавыннан ничек котылырга? Берәү, икәү өчәү... Көне буе җиләктә йөреп, берьюлы ике чиләкне күзеннән чыкканчы тутырып кайтсаң, шулай була гадәттә. Бу юлы да, компьютер хәтерен зарарлаган вирус шикелле, көне буе күз алдында булган бәрәннәр бер дә югалырга уйламый. Инзилә дәрестә дә һаман, иягенә таянып, күзләрен йомган килеш уендагы көтүлектән бар көченә качарга тырыша. Ә укытучы апаның үз мәшәкатьләре: уку елы беткәнче, тиешле темаларны үтеп бетерәсе, контроль эшләр эшлисе бар.

– Христиан дине I гасыр уртасында барлыкка килә. Башта ул Урта диңгез регионында яшәүче яһүдләр арасында тарала...

Бу тарих фәне бигрәк кызык инде! Әллә кайчан булган хәлләрне өйрәнеп утыруның нинди кызыгы бар икән?

– ... Христин дине икенче дөнья барлыгы турында да сөйли. Бу тормышта яхшы гамәлләре күп булган кешеләр оҗмахка эләгә. Андагы яктылыктан күзләр чагыла, агачларда татлы җимешләр үсә...

Тынып калган сыйныфның бер почмагыннан кинәт кенә сорау ягырады:

– Апа, анда да сарыклар бар микән?

Аптырап калган укытучы, берникадәр дәшми торганнан соң, елмаеп, сүзен дәвам итте:

– Бардыр, Инзилә...

Бу җавап яңгыравыннан куркып утырган кыз, бар сыйныфны яңгыратып, уфтанып куйды:

– Иий, анда да көтү көтәсе була икән!

Үз уйларына батып, йоклап утырганнар да уянып китеп, барысы бергә дәррәү көлеп җибәрде. Бары тик тырышып укыганнарның, тырышып эшләгәннәрнең, максатына һәм хыялына тугры калганнарның гына үз урынын таба алуын Инзиләгә тормыш, бәлки, бераз соңрак өйрәтер. Ә әлегә ул, күз алдында йөгерешкән ак һәм кара бәрәннәрнең уртәвенә түзә алмый, алдында яткан китапларын читкә этеп, парта өстенә капланды...

*3-нче урын*
***Азалия Хәмәтшина***

## Бүләк

Гаиләдә бер генә бала булганга, Алия күбрәк әбисе янында булды, әбисе тәрбиясендә үсте. Әти–әнисе иртән эшкә чыгып китә, ә Алия тагын әбисе янында кала. Әбисенең әкиятләрен, яшь чакларында булган хәлләрен тыңлап үсеп җиткәне сизелми дә калды. Бик уңган шул аның әбисе, җитмәсә бик матур да. Тәмле итеп бәлешләр пешерә, матур итеп гөлләр үстерә. Ә иң мөһиме оста итеп бәйли ул. Бер көнгә бер пар оекны, я бияләйне бәйли дә куя. Нинди генә бизәкләр кулланмый ул аларны бәйләгәндә!

Әбисе Алияне гел нидер өйрәтеп, киңәшләрен биреп үстерә: «Кызым, эшеңне җиренә җиткереп эшлә! Шулай эшләсәң, сине хөрмәт итәрләр. Ә инде кем өйрәтте дисәләр – үзем беләм, диярсең». Нәрсәгә генә өйрәтсә дә, нәрсә генә эшләсәң дә «Кем өйрәтте дисәләр – үзем беләм, диярсең», – дип тукып тора. Алия өчен бу көлке генә булып тоелса да, бу җөмләне еш кулланырга туры килде аңа. Беркөнне кеше күрмәгәндә генә әбисенең бәйли торган оекларын алып, бәйләп карарга булды. Әбисе моны күреп, бик шатланды, аның бәйләгәнен әкрен генә күзәтеп торды.

– Я, кызым эшең барамы? – диде, әбисе елмаеп.

– Тырышам, әбием, синеке кебек бизәк ясарга телим.

Тырыша торгач, Алиянең бизәге нәкъ әбисенеке кебек килеп чыкты. Азатның шатлыгы эченә сыймыйча кычкырып җибәрде:

– Е-е-ес, – диде, ул. Килеп чыкты.

Шул вакытта күршедә яшәүче Наилә апа килеп керде. Алиянең бәйли торган оек тотып утырганын күргәч, шаккатып:

– Әллә, Алия оек бәйләргә өйрәнәсеңме? Әбиең өйрәтәдер инде. Молодец! – диде.

– Юк, Наилә апа, мин үзем беләм, дигәнен сизми дә калды. Әбисенә күз төшергән иде, әбисе аңа күзен кысарга теләгәндәй, икесен дә йомып алды. Менә шундый вакыйгалары күп булды аның…

– Әбием, мин сиңа кайчан булса да бик тә җылы оеклар бәйләп бирермен, яме! – диде.

– Рәхмәт, кызым, рәхмәт, – дип аркасыннан сөйде аны әбисе.

Әйбәт кенә мәктәпне тәмамлагач, институтка укырга керде Алия. Укытучы һөнәрен сайлады ул. Рәсем укытучысы.

Алия – җиткән кыз булып үсеп тә җитте, ә әбисе бик картайды шул аның. Институтта укыса да, еш кына әбисенең хәлен белергә кайта ул. Тәмле-тәмле чәйләр, кәнфитләр алып кайта аңа. Еллар үтә торды. Алия институтны уңышлы гыны тәмамлап, үз бистәсенә эшкә кайтты. Әйбәт кенә эшли дә башлады. Эшен бик яратып башкара ул. Ниләр генә ясамыйлар алар укучылар белән. Балаларга дәресләр бик ошый, хәтта укытучы апаларыннан өстәмә түгәрәк тә сорадылар. Алиянең куллары алтын, барлык эшкә дә бик оста.

Әбисе дә картайды шул аның, җылы оекларны да бәйли алмый башлады. Миңа да әбигә дигән оекларымны бәйләргә вакыт җитте ахры дип, Алия оекларны бәйли башлады. Ә беркөнне әбисе бөтенләй авырып китеп, урынга ятты. Алия ул-бу булмасын дип, оекларны тиз-тиз бәйләде. Өч көн дигәндә, оеклар бәйләнеп тә бетте.

– Әбием, синең аякларың өшидер, мин сиңа вәгъдә иткән оекларымны бәйләдем. Әйдә мин сиңа аларны кидерәм. Алия әкрен генә аларны кидерде, ләкин әбисе дәшмәде. Берничә көн шулай аңсыз ятты ул. Бүген әбисе төнне аеруча авыр чыкты. Ә иртә якта инде ул суламады.

Алиягә бик авыр булды. Аның күзләренә яшь килде. Ул әбисенә карады, аның күзләрендә канәгатьлек күрде ул. Димәк, әбисенең өйрәтүләре бушка китмәгән, әйтелгән эш эшләнелде. Бар да риза.

– Тыныч ят, әбием!

– Бәхетле бул, кызым!

19-25 яшьлекләр

*2-нче урын*
***Энҗе Халикова***

## Мәхәббәт ялкыны

«Мәхәббәт – иң бөек көч», – дигәннәрен ишеткәнем бар, ләкин бер дә ышанасым килми иде. Чөнки гашыйк булган кеше – ул юләр, акылын тәмам югалткан кеше дип саный идем. Тик кешенен язмыш дәфтәренә шулай язылгандыр күрәсен, һәм бөтенебезгә дә мәхәббәт хисенен нәрсә икәнлеген белергә насыйп булган.

Менә минем дә гашыйк булырга чиратым җиткән күрәсен...

Бер кеше миңа мәхәббәтнен нәрсә икәнен аңларга булышты,һәм ул хискә ышанырга өмет бүләк итте. Ләкин мин аңа ышанып дөрес эшлим микән? Бәлки ышанырга, өметләнергә ярамагындыр?

Беренче саф мәхәббәт онытылмый диләр, дөресе шулдыр күрәсен. Менә минем дә шул турыда синен белән сөләшәсем килә, кадерле укучым!

***Беренче очрашу***

Эссе җәй көне, мин практика үтәргә,эшкә урнашырга йөрим. Тик мин теләгән организацияда урын булмый һәм мине мәктәп китапханәсенә эшкә алалар.

Үзем турымда сөйләп китим. Танышырга, минем хис–кичерешләремне аңларга Синә җайлырак булыр. Минем исемем – Алия. Мина 16 яшь. Шомырттай кара күзле, озын кара чәчле, уртача буйлы кыз. Буш вакытымда шигырьләр, хикәяләр язарга яратам. Хисле кыз булуыма карамастан, мәхәббәт хисенә бик ышанмыйм.

Эх, Алия, Алия... Әлеге җәй синен тормышынны баштан аякка хәтле үзгәртәсен әле белмисен бит.

Җәйге практика утергә мине мәктәп китапханәсенә алдылар. Мин практикант кыз, Айсылу апага булышып йөрим, буш вакытымда имтиханнар бирергә әзерләнәм. Көннәрем берүк төрле үтә. Ләкин, бугенге көн калган 15 көннән аерылды.

Бүген китапханәгә бер егет китап алырга керде. Әкияттә ничек була икәнен беләсезме? Бер караштан гашыйк булалар. Менә безнен белән дә шулай булды. Мин бу егетне беренче тапкыр күрүем

иде. Ул китапханәгә кергәч без берберебезне күреп тәрәлеп каттык. Ул ни өчен кергәнен онытты, ә минем кулыманан китаплар төште дә китте. Бераз басып торгач, ул йокыдан айныган күк, миннән күзен алып, иптәш кызыма эндәште:

– Хәерле көн, Камилә! Миңа икенче уку елына китаплар җыеп куй әле. Мин соңыннан кереп алырмын,– диде дә, миңа елмаеп карап, чыгып китте.

Ул егетнен чыгып китүе булды, мин Камилә янына барып утырып, анын турында сорашмакчы булдым. Ләкин ул миңа анын кушаматыннан башка берни дә әйтә алмады…

Шул үк көнне мине иң якын дустым велосипедта йөрергә чакырды. Эх, кем уйлаган, шушы очрашунын да үзенен сере бар икәнлеген…

Мин Айрат белән кич чыгырга булдым, тик теге егет хаман башымнан чыкмый, анын күзләре, елмаюы, сөйләшүе күз алдымда.

– Айрат, ә син мәхәббәтнең барлыгына ышанасынмы? – дип сорарга уйладым дустымнан, тик сорамасам бәлки яхшырак буласы булгандыр.

– Әлбәттә, ышанам. Минем өчен мәхәббәт ул син! Тик син генә күрерге, сизергә теләмисен. Ә мин бит сине ничә ел инде ошатып йөрим, – дип, Айрат янымнан әкрен генә велосипедында узып китте, ә мин ишетмәбешкә сабышып:

– Ярар, Айрат, җавап бирәсең килмәсә, бирмә. Ә миңа кайтырга кирәк, әйдә өйгә таба борылыйк, – диеп, сүзне икенчегә борып, өйгә кайтырга җыенып борылсам, каршыма башымнан хаман чыкмый торган егет килә!!! «АБАУ!!! Нишлим?? Кая качыйм??» дигән уйлардан башка, мин берни дә уйлый алмый идем.

Серле егет безнен яннан узып китте, ә Айрат минем битем кызарып чыкканын күреп, усалланып , мине берүземне калдырып кайтып китте.

***Танышырга вакыт***

Мин өемә кайтуга ук, компьютерымны яндырып «ВКонтакте» интернет-чилтәрнә кереп, җырлар тыңлап, бүген булган хәлләрне онытырга җыендым. Әмма ләкин, бүгенге серле егет киресенчә уйлаган күрәсен. Күзләрем маңгаема менде, Илназ исемле егеттән хат:

– Сәләм,Алия! Син Айратны ошатасынмы? Бәлки берәрнинди Дамирнымы?

– Хәерле кич, Илназ! Минем уйлаумча, син андый сораулар бирергә хакың юк. Без бит синен белән таныш та тугел. Ләкин си-

нен күңелең тыныч булсынга, ярар җавап бирәм. Юк, миңа берсе дә ошамый. Мәхәббәтнең барлыгына ышанмый торган кеше, ничек кемнедер ошата ала?

– Мин бик шат! Чөнки барыбер син минем белән булачаксын. Мин дә синен күк мәхәббәт хисе китапларда гына бар дип уйлаган идем, тик бүген китапханәдә сина гашыйк булдым.

– Юләр! Бер караштан гашыйк булып булмый!!!

– Була! Син дә бит мине ошаттын. Кузләрен дөресен әйтә, сүзләреңә караганда.

– Юләр!

Әлеге язышудан сон без Илназ белән дусларча сөйләшеп йөри башлады, ул да мәктәптә эшләгәч безгә очрашырга җайлы иде. Айрат безне күргән саен читкә китә, ә Илназ аны күрүгә мине нык итеп кочаклый. Мин алар арасында буласым килми, Айрат бит минем дустым…

Практиканын соңгы көнендә, әни өйгә кайтып минем белән сөйләшә башлады:

– Кызым , ә нигә әле син миңа егетен бар икәнен әйтмәден?

– Әнием, егетем булса беренче итеп сиңа әйтер идем. Ләкин ул юк, минем дусларым гына бар.

– Ярар, ә Илназ алайса кем?

– Минем дустым, без аның белән мәктәптә таныштык.

– Ә менә миңа әйттеләр, сез бергә дип. Ул үзе шулай дип сөйләп йөри бит, кызым. Ә аның күрше авылда йөргән кызы бар. Ул хәзер елап, өеннән дә чыкмый.

Бу сүзләрне ишеткәч мин кызарып чыктым, һәм ачуымнан Илназга яздым

– Илназ, син ялганчы!!! Йөргән кызың була торып минем арттан йөрисен. Башкаларга мин синең йөргән кызың дип алдыйсын. Нигә син минем белән алай уйныйсын? Мин бит сиңа ышана идем!!!

Илназнын хатын көтмичә, мин аны «чёрный список»ка аттым. Ике көн өйдән чыкмыйча, аннан качып яттым, һәм бер атнадан Казанга апайлар янына кунакка китәргә булдым. Шулай итеп мин мәхәббәтнен ни икәнен барыбер аңлый алмыйча, үз хисләремнән качтым…

ДӘВАМЫ БАР

*2-нче урын*
***Гөлчәчәк Сабирова***

## Ялгыз имән
## (чынбарлыктан алынды)

Кече сыйныфлардан ук күрше авылга йөреп укырга туры килде. Ул елларда автобус йөрткәнен хәтерләмим. Ара әллә ни ерак түгел – ни бары өч чакрым, әмма сынау юлы иде ул…

Мәктәбебез тау битендә урнашкан. Тауны төшкәч тә сул якка борылып авылга таба атлыйсың. Синнән уң якта – биек тау, сул якта – куе әрәмәлек кала. Аннан нинди генә кыргый авазлар, нинди генә кыштырдаулар, нинди генә үлек исләре килми иде. Шул кот очкыч әрәмәлектән нидер, ә кайчак кемдер (качкыннар да юк түгел бит) килеп чыгар да әллә кая алып китәр яки бу якты дөнья белән хушлаштырыр сыман иде. Йөгерә-атлый, кайчак елый-елый әрәмәлекне үтәсең. Ярый әле әрәмәлек юл буе сузылмаган. Сигез йөз чакрым тирәсе атлагач әрәмәлек юл буеннан читләшә, юлны икегә бүлеп япа–ялгыз имән кала. Имән карт, инде күпне күргән. Аның хәтерендә төсләрен югалткан солдат кулъяулыклары да, ничәмә-ничә еллар йөгерә-атлый кайткан укучы күз яшьләре дә, аварияләр дә…

Ә иң кызыгы шунда – нәкъ имән төбендә сәер хәлләр була. Мине дә бу сәерлекләр урап узмады. Шулай бервакыт җәяү ялгызым кайтып барам, әрәмәлекне үтеп имән төбенә җиттем. Бик еш борылып үткән юлга карау гадәте бар иде. Беренчедән, шикләнеп булса, икенчедән, җаеп–таеп машиналы таныш-белеш килеп чыкмасмы. Шулай борылып карасам арттан бәләкәй генә карчык килә. Таныш түгел. Авылыбыз бәләкәй, мин ул карчыкны һичшиксез таныр идем. Гомумән, ул ничектер сәер булып тоелды миңа…Йөрәгемне шом басты. Адымны тизләйттем, янәсе куып тотмасын мине. Бераздан, гадәттәгечә, борылып карасам – әби юк, аннан җилләр искән. Бик озак эзләдем, тау битен күзем белән йөгереп чыктым, артка, аскы юлга карадым – юк, бер кайда да юк иде, вәлләһи җир йоткан диярсең. Аскы юл – такыр басу юлы. Уңда – тау. Кайдан гына кайтма – син уч төбендәге кебек ап-ачык күренәсең. Әмма сирәк кенә ялгыз агачлардан башка бер ни дә юк иде. Нәрсә соң бу?! Әллә инде саташаммы ?! Болай

да курку баскан йөрәккә шом өстәлде. Кайчан ничек өйгә кайтып кергәнемне хәтерләмим. Әти–әниемә бер ни дә сөйләмәдем. Бу вакыйгадан соң ялгыз имән минем өчен куркыныч вә серле булып калды. «Курыкканга куш күренә» диярсез. Әмма моның белән генә сәер хәлләр бетмәгән икән...

.... Инде күп еллар үтте. Мәктәпне тәмамлап, югары уку йортында укып йөргән чагым. Иң гүзәл, көч-куәт ташып торган чак. Беренче курсны тәмамлагач йөртү таныклыгын алырга булдым. Вакыт тиз үтә бит ул. Бер ничә айдан правалы да, машиналы да булдым. Әтием иске машинасын миңа яздырды. Гаиләбездә ир туган булмагач әниемне, туган-тумачаны кирәк җирләргә йөртү минем өстемә төште. Бу җаваплылыкны үземчә бәхет тә, горурлык та итеп кабул итем. Йөрдек, күп йөрдек. Таң ата – без юлда. «Выжлатып» әле моннан, әле тегеннән урап кайтабыз. «Выжлап» нәкъ әрәмә буеннан, мәктәпкә йөргән юлдан да үткәләдем. Әмма җәйнең матур бер көнендә бу «выжлап» үтү соңгысы булды. Авариягә тарыдык. Нәкъ менә юл кичешкән ялгыз имән буенда... Ялгышлык миндә иде. Ләкин үткәннәрне барлыйм да уйланам: ялгышлык чыннан да миндә микән? Әллә берәр көч башымны томаладымы? Әллә соң чыннан да бу җир дәһмәтлеме? Ә бәлки карт имән ялгызлыктан туйгандыр... Ә син ничек уйлыйсың, укучым?!

*3-нче урын*
***Айгизәр Ногъманов***

## Хат

Кайгы-хәсрәт, күз яшьләре. Тагын нәрсә була ала куркынычрак, күңелсезрәк бу яшьтән?

Мин тауда басып торам һәм әле генә чәчәк ата торган умырзаяларны күрәм. Биредә барысы да тынычлык белән тулы. Тик бу сүрәттә мине нәрсә дә булса борчый. Менә тора йорт, аны инде шайтан таягы һәм кычыткан басып беткән. Аның тәрәзәләре бар да ватылган.

Өйнең авыр чор кичерүе күренеп тора: җиңү бәхете, өйгә ашкыну һәм әни образы китергән вакыт ул. Мин кердем бу өйгә, анда бар нәрсәавыр һәм каты сугыш истәлекләре белән тулган. Өстәл өстендә берничә хат ята иде. Бу хатлар югалмаган, әмма онытылып, ташландык булып калганнар. Ә бит алар мәхәббәт, нәфрәт һәм шатлыкны күрсәтәләр. Мин бу хис–тойгыларны, дулкынлануларны тойдым һәм бүтән укый алмадым...

Әмма бер хат минем өчен гомер буена онытылмады. Бу хат шунда яшәгән хатын-кыз кулыннан язылган иде.

«Кадерле улым, менә өч ел инде син фронтта. Мин сине көтәм, син кайчан кайтасың? Сине исән-сау күрәсем килә. Барысын бирер идем сине күреп китер өчен. Кулларым яза алмый, кайгырам синең өчен. Инде ничә ел үтте, йөрәгем өзелә.

Синең көләч, ягымлы йөзең гел күз алдымда. Улым, кадерлем, тизрәк кайт. Тормышың ничек, авырмыйсыңмы? Бу хат сиңа барып җитсен һәм күңелеңә җылылык өстәсен. Бар кайгылар синнән китсен. Яралансаң да, бирешмә, көрәш һәм җиң...Яратам сине минем кояш, минем җилкен».

Хатны укып чыккач мин аңладым, ничек көчле булганын бу әнинең яратуы. Бу хатлар арасында тагын берәү бар иде...

«Исәнмесез, Асия апа. Мин Галинын дусты, Идрис булам. Ул бик тә әйбәт кеше һәм яхшы дус. Аның юлы авыр булса да, ул җиңелми иде. Ләкин, иртә белән, йоклаганда, безгә немец диверсантлары хоҗүм иттеләр. Без югалып калдык, әмма Гали безне канлы сугышка алып китте. Без җиңдек, ләкин Гали авыр яраланды. Тиздән ул вафат булды. Гали сезне бик нык ярата иде. Мин

хисләремне тыя алмыйм, миңа авыр. Бу ерткычлар бездән иң кадерле кешебезне тартып алдылар...»

Гали вафат булды. Бөтен өмет юкка чыкты. Асия апа үзендә көч югалтты.

Ул кыен хәлдә иде. Асия апаның кичергән хисләре бик фаҗигале, онытылмаслык.

Гомер – ул бирәү. Һәр кеше үзе генә белә ничек аңа яшәргә.

# Балалар әдәбияты



БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ
12-14 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Идел Ногъманов***

## Канатлы кешеләр

Борын-борын заманда олуг Җир шарында бер яхшы агач та, яшел үлән дә, ярдәмчел җәнлек-кошлар да булмаган. Җир өсте иге-чиге күренмәгән комлыктан гына торган. Комлыкның патшасы комсыз Кызылком бар дөньяны куркыткан. Кызылком үзенең ханлыгына берәр әйбер ялгыш кына төшсә дә, шунда ук үз комында югалта барган. Шуңа күрә, явыз Кызылкомнан качып, ул заманда, кешеләр чиста һавада яшәгән. Алар ак канатлы булган һәм һәрбер кеше ниндидер тылсым эшли белгән. Канатлы кешеләр зәңгәр болытлар белән тукланганнар, тыгыз болытлардан өйләр төзегәннәр. Тылсым ярдәмендә салават күпере салып төрле буяулар уйлап тапканнар. Ай, кояш нурларыннан ныклы җепләр ясап, матур, уңайлы киемнәр теккәннәр. Бик дус яшәгән канатлы кешеләр киң һавада.

Шулай бердәмлектә тормыш иткәндә, кешелек дөньясында куркыныч вакыйга була. Бер канатлы бәхетле гаиләнең, өч яраткан баласы болыттан болытка сикереп уйнаганда җиргә килеп төшә. Әле аларның канатлары ныгымаганлыктан, алар кире күккә очып менә алмыйлар. Ә эшчән әти-әниләре бу вакытта эштә була. Кайтуларына балаларын өйдә тапмагач, эзли башлыйлар…

Актан киенгән өч бала комлык уртасында кайда барырга белми. Тәннәрен комлы җил кисә, аяклары комга күмелә. Кызылком тиз арада сизенеп яннарына килеп җитә. Ул көчсез балаларның тылсымын, канатларын үзенә ала һәм тагында көчлерәккә әйләнә. Ашыйм дигәндә, ул нигәдер җәлли балаларны, шуңа күрә исән калдыра. «Ярарком, балаларком, минком эшлим сезгә өйком», – ди ул. Кызылком төзеп бирә кара комнан сарай һәм шунда ябып куя канатсыз балаларны. Сарайның ишек төбенә сакчы озын еланнарын яткыра. Балалар елый, аларның өйләренә кайтасы килә.

...Әти-әнисе бөтен кук йөзен карап чыккач, җиргә күз салырга уйлый. Һәм шунда елаган тавыш ишетәләр. Зур комлы сарайда канатсыз, хәлсез балаларын күреп ата-ана хушсыз кала. Алар кайгыдан куе болытка әйләнә, балаларына якынрак булыр өчен, тамчыга әверелеп яңгыр булып явалар. Сусаган балалар яңгыр суын җыеп эчеп кенә исән кала.

Кызылком урланган канатлар ярдәмендә һавага да очып менә башлый. Ул әти-әниләре өйдә булмаганда, бөтен бәләкәй баланы урлап, канатларын ала. Кызылком тагында көчлерәккә, явызракка әйләнә. Аны тылсым белән генә җиңеп булмый башлый. Олы канатлы кешеләр җыелышып канатлары усал Кызылкомга эләкмәсен өчен, канатларыннан кошлар ясыйлар. «Кошлар сабыйларыбызга безнең турында сайрарлар, авыр чакларда киңәш биреп, таяныч булырлар», – дип әйтәләр дә, юкка чыгалар. Алар югалган урында куе зәңгәр болытлар гына кала.

Шул болытлардан жиргә әллә ничә көн яңгыр ява. Кызылком судан бик курка, бөтен көчен җыеп давыллап та карый, ләкин яңгыр тагында ныграк ява. Һәм Кызылком Җир шарыннан хәлсезләнеп көчкә чыгып кача. Ул китү белән Җирдә елгалар, чишмәләр килеп чыга, табигать яшеллеккә күмелә.

Күктән төшкән бөтен бала исән-сау кала. Әти-әниләрен нигә югалганын алар аңлыйлар. Һәрчак яңгыр яуганда, җыелышып, кулга-кул тотынышып яңгыр астында бииләр. Аларның якты истәлеген, ышанычын аклар өчен балалар тырышып эшлиләр. Бер-берсенә ярдәм итеп, тату яшиләр. Ә канатлы кошлар һәр алсу таң саен сихри матур итеп сайрыйлар...

*2-нче урын*
***Нәзилә Гирфанова***

## Тылсымлы курай

Яшәгән, ди, булган, ди авыл читендә бер кечкенә өйдә ярлы хатын. Тора-бара ул хатынның Хәдичә исемле кызы туган. Ул көнләп түгел, ә сәгатьләп үскән. Хәдичә зирәк һәм тапкыр булган.

Менә бервакыт Хәдичәнең әнисе бик авырып киткән. Ул көннән–көн начарлана барган. Аның әнисенә бер табиб та булыша алмаган.

Бер көнне, әнисенең чәй эчәсе килгән, ә самовырда су беткән. Хәдичә чиләк-көянтәсен асып чишмәгә суга киткән. Ә чишмә аларның өйләреннән бик ерак булган. Хәдичә байтак юл үткәннән соң, ниһаять чишмәгә барып җиткән. Чиләкләренә көмеш су тутырып кайтырга чыккан. Азмы–күпме барганнан соң аның юлында бик сусаган, хәлсезләнгән куян очраган. Кызганып, Хәдичә куянга су эчерткән. Куян шул кадәрле сусаган булган, чиләкләрдәге барлык суны да эчеп бетерә язган. Хәдичәгә шунда гына әнисе искә төшкән. Ул бик борчылган. Инде әнигә ни эчертермен, чишмә бит инде еракта калды, дип кайгырган. Куян аның борчылуын күреп:

– Ник борчыласың? – дип сораган.

Хәдичә аңа барысын да аермачык сөйләп биргән.

– Кайгырма, – диде куян, – Менә сиңа тылсымлы курай. Ул курайда нинди дә булса көй уйнасаң, ул барлык кешене авыруыннан терелтә ала, – дигән дә, курайны Хәдичәгә биргән.

Кыз куянга күп рәхмәтләр әйтеп өенә таба киткән. Өйгә кайтып кергәндә әнисенең хәле тагын да начарланган. Шулвакыт ул куянның сүзләрен искә төшерде һәм кураен куеннан чыгарып уйнап җибәрде. Хәдичә нычырак уйнаган саен әнисенең хәле яхшыра барды. Көннән–көн ул үзен яхшырак хис иткән һәм тәмам терелеп җиткән.

Хәдичә белән әнисе әле хаман да матур тормыш белән яшиләр ди.

«Изгелек эшләсәң, яхшылык көт», – дигәннәр бит өлкәннәр!

## Актәпи

Авыл уртасындагы йорттан бер хатын чыкты да, авыл читендәге урманга таба юнәлде. Аның кулларында кечкенә генә кап-кара песи баласы иде. Ул бик куркып як-ягына карый. Урманга килеп җиткәч, хатын:

– Кит! Пресс! Син безгә кирәкмисең! Син кара төстә һәм бары тик уңышсызлык кына китерәсең! – дип песи баласын чирәмгә ташлады.

Кечкенә песинең исеме Актәпи иде. Актәпи нәрсә булганын аңламыйча күпмедер вакыт чирәмдә утырды. Шуннан соң авылга таба юнәлде, ишегалды себерә торган кешене күреп «Бәлки ул мине үзенә алыр..». дип уйлап, үзенә ышанмыйча берничә адым аның янына атлады. Себерүче исә кара мәчене күреп: «Пресс! Кит моннан!» – дип куалап җибәрде. Актәпи куркып эскәмия астына кереп качты.

Куркуыннан тынычлангач, эскәмия астыннан чыгып, гәҗит укып утырган бабайны күреп алды. Аның янына сикереп менеп мырылдый башлады. Бабай аны ишетеп эскәмиядән этеп үк төшерде. Актәпи эскәмиядән егылып төште. Аның тәпие бик нык авыртты. «Мин беркемгә дә кирәк түгел» дигән уй аның күңелен тагын да авырттырды.

Инде тәмам хәлдән таеп, менә шулай әле монда, әле тегендә йөри торгач, ул сөяк кимерә торган этне күреп алды. Янына килеп:

– Исәнмесез... Ә сез нәрсә эшлисез? – дип сорады.

– Ашыйм! Күрмисеңме әллә?! – дип әйтте.

– Минем дә бик ашыйсым килә. Күптән ашамаган инде...

Эт Актәпине җәлләп аңа да сөяк бирде.

– Рәхмәт сезгә, – дип әйтте Актәпи ашап бетереп, тәпиләрен ялый–ялый. Кинәт үзенә охшаган куе сары төстәге мәчене күреп алды. Актәпи аның янына чапты:

– Исәнмесез! Мине үзегез яныгызга алыгыз әле, без бит бик охшаш, төсләребез белән генә аерылабыз. Үтенеп сорыйм! – дип ялварды.

– Гафу ит. Мин сине бик алыр идем! Ләкин минем үземнең дә балаларым күп шул.

Инде кая барырга белмичә, Актәпи тагын ялгызы гына калды. Ул чишмә янына килеп судагы шәүләсенә карап:

– Мин бит кара төстә булганыма гаепле түгел! – дип елап җибәргәнен дә сизмәде. Ул туктый алмады, күз яшьләре аның күзеннән ага да ага.

Кинәт кенә кемдер арттан очлы тырнаклары белән Актәпине эләктереп алды. Шуннан ул нәрсә аны бик югарыга, һавага күтәрде. Тырнаклары баткан җирдән кан ага башлады. Актәпи башын күтәрсә, ул үзен бөркет тырнакларына эләккәнен аңлап алды. Авыртуына карамастан, Актәпи бөркетнең аягын көч–хәл белән тешләп алды. Көчле аяклар аны ычкындырды. Актәпи аска ыргылды. Чишмә суы аның егылуын йомшартты, ләкин су салкын иде. Үзенең авыр хәленә карамастан, Актәпи өметен югалтмады. Кинәт бер кыз–бала кечкенә куллары белән аны судан тартып чыгарды. Актәпи күп кан югалтканга һәм бик каты туңганга аңын җуйды. Кыз исә, Актәпине әнисе янына алып килде. Әнисе Актәпине хайваннар табибына алып барды. Табиб Актәпине караганнан соң:

– Яра тирән түгел, бәхеткә каршы. Зур зыян юк, – дип әйтте. – Тиздән йөреп тә китәр.

– Әни-и-и…

– Юк кызым! Без аны үзебезгә ала алмыйбыз. Болай да өебезгә биш мәчене сыендырдык бит инде, – дип бүлдерде кечкенә кызын әнисе.

– Димәк, аның хуҗасы юк…– диде, аларны тыңлап торган табиб. – Ярар, алайса аны үземә алып кайтам. Күптән песи турында хыяллана идем, – дип шатланып елмаеп куйды.

Актәпи терелеп, табиб абыйсы янында яшәп калды. Хәзер инде ул иң бәхетле песиләрнең берсенә әверелде.

*3-нче урын*
***Нәзилә Закирова***

## Җиңү көне

Күңелем тулы бәйрәм хисе белән кайтып барам. Бер сәгать элек кенә явып киткән җиңел яңгыр урамнарның тузанын баскан. Кышкы авыр йокыдан уянып, инде яшел шәлгә төренергә өлгергән яшь каен агачлары да йомшак яңгыр тамчыларында сафланып, барлык узып китүчеләрне сәламлиләр кебек. Кояш батышы ягыннан искән йомшак яз җиле дөньяга яңару һәм яшәрү исләре чәчә. Бар җиһанның матурлыгын өстән сүзсез генә күзәтеп торучы кояш, нурлары белән, барлык тереклекне коендыра кебек. Әйтерсең барлык табигать, барлык җан иясе бүген бәйрәм итә. Бөтен җирдә бәйрәм тантанасы: шарлар, чәчәкләр, котлаулар.

Җиңү көне... Туган җиремә инде ничәмә ничә еллар буе килеп, алдагы елларда да барлык җанлы һәм җансыз нәрсәләрне үзенең шатлык нурлары белән күмәргә вәгъдә иткән Җиңү бәйрәме. Бар халык – әле сугышның һәм җиңүнең нәрсә икәнен дә аңламаган бала–чагадан башлап, чәчләренә күптән ак бәс сарган, инде гомер кышына кергән өлкәннәр дә – бәйрәм итә бүген.

Безнең буын сугышның коточкыч вәхшилекләр, рәхимсезлекләр алып килгәнен китаплардан укып, кинолардан карап белә. Бөек Җиңү безгә бик күп корбаннар аша бирелгән. Бүгенге матур, тыныч, бәхетле тормышта яшәвебез белән без каһарманнарыбызга гомеребез буе бурычлы. Әмма аларга тиешле бәяне биреп, вакытында ярдәм итеп җиткерә алабыз микән? Сугыш һәм тыл каһарманнарыбызның сафлары сирәгәйгәннән сирәгәя бара. Безне тарихыбыз белән бәйләүче җеп тә нечкәрә бара кебек.

Шуларны уйлый-уйлый, урамнан атлыйм. Кинәт күкрәге орден-медальләр белән тулы бабайга күзем төште. Аның адымында, хәрәкәтендә җир анага хөрмәте сизелеп тора. Һәр адымын ул, йомшак итеп, әмма ныклы ышаныч белән атлый иде... Соклануымнан күңелем горурлык хисләре белән тулды. Минем язгы табигатьнең хозурлыгын, матурлыгын, кодрәтемнән килгән хәтле, шушы бабайга бүләк итәсем килде. Һәм акрын гына аны күзәтә башладым. Минем кебек аңа карап сокланучылар байтак

булып чыкты. Аларның да кызыксынулы һәм соклanулы күзләре бабайда иде.

Менә ул, салмак кына атлап, икенче якка чыгар өчен, юл кырына килеп басты һәм сабыр гына көтә башлады. Тирә-юньдә бер кеше юк. Әз генә читтәрәк кечкенә баласын җитәкләгән ана басып тора. Кинәт 4-5 яшьлек чамасындагы малай ананың кулыннан ычкынып, юлга таба йөгереп китте. Юлдан, зур тизлек белән чыжылдап, бер–бер артлы машиналар чаба. Бер мизгел... Бу очракта бары тик бер мизгел генә барысын да хәл итәргә сәләтле иде. Кинәт бабай балага таба талпынды. Яшьләргә хас җитезлек белән малайны кулыннан эләктереп алды. Тик, тигезлек саклый алмыйча, бала белән икәүләп, юл кырына аудылар. Куркудан агарынган, көзге яфрак кебек калтыраучы ана алар янына ташланды. Шашынган күзләре белән башта баласын капшады, аннан бабайга үрелде. Ул арада без, якындагыраклар, ярдәмгә ашыктык...

Мин, шушы вакыйгадан соң, бабай белән элемтәне югалтмаска булдым. Аның янына хастаханәгә киттем. Ул мине елмаеп каршы алды.

– Кызым, зыян юк. Әз генә «ремонт» ясадылар, – диде ул, бәйләнгән кулын сыпырып.

– Кем атлы буласыз соң? Бабай дип йөртү килешеп бетмәс, – дидем мин дә, аның кебек шаяртып.

– Рәхмәт, кызым. «Бабай» сүзе – минем өчен «иң югары титул».

– Бабай, бигрәк шаян булып чыктыгыз әле.

– Дөнья шулай өйрәтте, кызым. Гомер кыска, матур итеп яшәп калырга кирәк. Минем сугышта һәлак булган иптәшләремә дә лаеклы булып яшисем килде һәм килә дә.

– Сез моңа мең тапкыр лаек бит. Әнә бит тагын үзегезнең гомерегезне куркыныч астына куеп, нинди зур батырлык эшләдегез.

Бабайның йөзендә сәер елмаю барлыкка килде:

–Кызым, арттырырга ярамый. Минем урында теләсә кем эшләр иде аны, – дип, урындык башына эленгән, орден–медальләр тагылган киеменә күз төшерде. Мөгаен, сугыш, сугышта һәлак булган иптәшләре күз алдына килгәндер. Мин ул турыда сүз катарга җөрьәт итмәдем. Анын кәефен күтәрергә тырышып:

– Бабай, әйдә үз тормышыгыз турында сөйләгез әле. Берәр нәрсә турында, – дидем.

Ул уфтанып куйды. Мин ялгыш сорау биргәнемне аңладым. Тик әйткән сүз – аткан ук шул, кире кайтарып алып булмый.

Бабай ашыкмый гына хәтер йомгагын сүтәргә тотынды:

–1943 елның язында сугышка киттем. Сугыш, сугыш инде ул. Сез инде аны укыганнардан да, кинолардан да яхшы беләсез. Һәр совет солдаты кебек үк мин дә сугышчан бурычымны үтәдем. Бу орден–медальләрнең һәрберсендә сугыш фаҗигасе чагыла...

Мин тагын аны авыр уйлардан коткарырга теләп:

– Бабай, бабакай, әйдәгез, авыр теманы читкә куеп торыйк, – дидем тиз генә. – Мөгаен, сезнең дә мәхәббәтегез булгандыр. Әйдәгез, шул хакта сөйләшик.

ДӘВАМЫ БАР

15–18 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Ләйсән Абдрахманова***

## Бүләк

«Укучылар, Балалар йортына бүләкләр алып килергә онытмагыз! Бу мөһим!» дигән СМС килеп төште телефоныма... Уф, тагынмы?! Күпме була инде, ә?! Кыш җиттеме, башлана инде... Акция. «Ятимнәр өчен Яңа ел», имеш. «Сезнең ярдәм безнең өчен мөһим! Булышыгыз! Читтә калмагыз!» имеш...

... Уфф... Буш сүзләр бит болар! Көләсе килә... Әле тагын: «Булышсагыз иде!» – дип үтенгән булалар. Ә укытучылар алай әдәп саклап тормыйлар, «Алып киләсез! Бетте! Бу мәсьәлә чишелде!» – дияләр дә теманы ябалар. Аннары, өйнең астын өскә китереп, бүләк эзләргә туры килә. Бүләк дигәнем... үземә кирәкмәгән әйбер инде. Ярамаган тагын аларга. Туган көнемә бүләк ителгән, үземә ошамый торган киемнәр, китаплар, блокнотлар... Эзли торгач табыла инде...

Кем соң син, дисезме?

Таныш булыйк соң: мин – Алсу. Гап–гади, нормаль, типик кыз мин. Башкалардан берни белән дә аерылмыйм төсле. Шундый ук ике күзле, ике колаклы, бер борынлы, әмма авыр характерлы. Авыр да түгел инде. Шулай дигән генә булалар. Әйтсеннәр, миңа барыбер. Алар просто миннән көнләшәләр, чөнки мин һәрвакыт үз дигәнемә ирешәм. Ультиматум беләнме, янау беләнме – мөһим түгел. И вот они завидуют...

«Кемгә охшап шундый син? Алай вөҗдансыз булмыйлар инде! Алсу, азрак кылан», – дигән булалар. Һе, шулай дигән генә булалар, ә үзләре миннән дә хуже.

Бәләкәй чагымда да: «Өйнең астын өскә китерәсең. Мультиктагы Маша кебек син. Бөтен кешене куркытып, контрольләп торасың. Алай ярамый бит. Син кечкенә, әлегә сине җитди кабул итмиләр, әмма үсә төшкәч, үзеңә авыр булыр», – дияләр иде.

Үстем, инде унөч яшем тулды менә. Әмма үзгәрмәдем. Шундый ук булып калдым, чөнки миңа болай да рәхәт. Артыгын сорамыйлар, миннән куркып торалар... Дусларым да җитәрлек...

Әйе, әти–әни белән генә кайчак ачуланышабыз. Тик алай гына булгалый инде...

Менә шундый инде мин, дуслар әйтмешли, «вредный». Әмма кайчан да булса үзгәрермен, «проблемный» булудан туктармын дип, һич тә уйламаган идем...

...Уноче. Дүшәмбе. Яратмыйм бу көнне! Авыр, йокы килә. «Понедельник – день тяжелый» дип, юкка гына әйтмиләрдер, мөгаен. Дәресләрен дә әйтер идем...иң авыр фәннәрне әллә юри шул көнгә куйганнар инде?!. Шулай да үземне кулга алдым. Ничек кенә барасым килмәсә дә, мәктәпкә барырга туры килде.

...Уф! Көн ярыйсы гына үтте кебек шикеллле...сыман...тоела... Эх, тоелган гына икән шул!!..

Моңа кадәр, дусларым белән мәктәптән кайтканда, бик күңелле була торган иде, чөнки алар һәрчак минем кәефне күтәрергә әзер. Сөйләшер темалар да күп: фильм дисеңме, башкасымы – уртак тема һәрчак табыла. Ләкин бүген Алинә (ул мине яратып бетерми): «Беләсезме, ә Алсу – асрамага алынган ятимә кыз. Миңа әни әйтте», – дип куймасынмы! Чәчләрем үрә торды! «Аны кыерсытмагыз, үзен уңайсыз хис итмәсен, булышыгыз, дип әйтте әни», – дигән була бит әле тагын, миңа күз кырые белән генә карап.

Барысы да сүзсез калды. Айдар гына: «Аңлашылды», – дип әйтеп куйды. Мин исә бер туңдым, бер пештем. «Ни сөйлисең син?? Ялган!!» – дип кычкырасым килде – авызымнан сүзем чыкмады. Тик күз яшьләремне тыеп тора алмадым: урам уртасында баскан килеш, кычкырып–кычкырып еладым.

Ул көнне мин гомеремдә беренче тапкыр кунарга өйгә кайтмадым...

Иртән генә әниемнән – 31, әтиемнән 28 «пропущенный звонок» килгәненә игътибар иттем. Әмма шалтыратырга шүрләдем, «Мин – дусларымда», – дип СМС кына җибәрдем дә мәктәпкә киттем.

Ә мәктәптә бөтен кеше мине сөйли. Элекке вакытым булса, әйткән булыр идем мин аларга бер–ике сүз – ник туганнарына үкенерләр иде... Хәзер бер сүз дә дәшә алмадым. Дәресләрдә дә күктә очып йөргән төсле утырып чыктым.

Дәресләр бетте. Өйгә кайтасы килми. Шулай да кичке алтыда, шәһәр карап туйгач, акчам беткәч кайтырга туры килде. Әмма, гадәттәгечә: «Мин кайттым», – дип түгел, ә «Ничек сез мине ал-

дый алдыгыз??? Ничә ел!!!» дип кычкырдым да бүлмәмә кереп бикләндем.

ДӘВАМЫ БАР

## Балалык шуклыгы

Илнур – бик шук бала. Аңа нибары алты яшь кенә. Аягы җиргә тисә тия, тимәсә юк – баскан җиреннән ут чыгара.

Әмма бүген Илнур бөтенләй бүтән төрле. Ниндидер җитди һәм серле ул бүген. Ник дип гаҗәпләнәсезме? Эш шунда ки, аларның чуар тавыгы ун йомырка салган иде һәм шуның бишесе бүген йомырка эченнән чыккан. Бу хәбәр турында Илнурга аның дәү әнисе – Фәүзия апа әйтте. Шул мизгелдә аныңниләр кичергәнен белсәгез иде сез! Илнур шундук ишек алдына йөгерде. Йөгерде дисәң дә дөрес булмас, ул алар янына очып кына барды. Илнур бик тә бәхетле иде.

Ул дәү әнисе белән бергә бу нәни чебиләрне өйгә алып керде. Илнур аларны бер күрүдә яратты. Яратмыйча соң! Ул бит аларны күпме көтте, чуар тавыгына йомыркаларны да үзе салган иде.

Илнур шактый вакыт сары йомгаклардан күзләрен дә алмыйча карап торды. Алар бит шундый матур һәм төрле иде. «Берсе йөнтәс, берсе йон тәпиле, берсе чуар, берсе кара күзле, берсе сары төсле», – дип бәя биреп чыкты ул. Һәм шул сыйфатларына карап, берсеннән–берсе матур исемнәр кушты Илнур: Йомшаккай, Йонтәпи, Чуаркай, Каракүз һәм Сарыкай. Бу вакытта Фәүзия апа чебиләрне йомшак һәм җылы бүрек эченә урнаштырды. Чебиләр Илнур кебек шукланып чыгып качмасыннар өчен, ул бүрекне катыргы тартмага салды. Шул көннән башлап Илнур күп вакытын чебиләр янында үткәрде. Алар берни аңламасалар да, барын да сөйләде, чебиләрнең хәлләре турында кызыксынды.

Бер көнне Илнурны йокысыннан ниндидер чит тавыш уятты. Торасы килмәсә дә торды. Өйдә беркем дә юк иде. Шундук Илнур чебиләре турында искә төшерде, тизрәк алар янына йөгерде. Илнурны уяткан тавыш чебиләр пипелдәве булып чыкты. Ул аларны аңлаган сыман: «Туңасызмы әллә, нәниләрем? Хәзер мин сезне җылытам», – диде. Илнур, ашыга–ашыга, кулына шырпы алды. Дәү әнисе Илнурга шырпыга тияргә рөхсәт итми иде. «Син кечкенә әле, аны дөрес кулланмасаң, ни генә булмас», – дия иде. Ләкин Илнур аны–моны уйлап тормады, тизрәк газны кабызды. Аннары чебиләр яши торган кәгазь тартманы газ плитәсе өстенә

куйды. Илнур: «Менә хәзер сезгә җылы булачак, нәниләрем минем», – дип әйтергә дә өлгермәде, катыргы тартмага ут капты. Илнур нишләргә белмичә югалып калды һәм акырып еларга тотынды. Әле ярый өйгә дәү әнисе килеп керде һәм ярдәмгә ташланды. Ялкынны сүндерүгә, малай чебиләре янына ашыкты, ләкин Йомшаккай да, Йонтәпи дә, Чуаркай да, Каракүз дә, Сарыкай да – барысы да үлгәннәр иде. Илнур бу эше өчен бик үкенде, көннәр буе елады, барысын да кире кайтарырга теләде. Әмма соң иде инде…

… Бик күп еллар үтте. Илнур абый зур егет инде. Ул газчы булып эшли. Һәрбер өйгә кереп мичләрне, газ плитәләрен тикшерә. Урам башында Илнур абый күренүгә, аны малайлар уратып ала, чөнки газчы абый чебиләрне генә түгел, ә балаларны да бик ярата. Балалар да аның өчен «үлеп китә», чөнки кайчагында, аңа ияреп, газ карарга да йөрештергәлиләр алар. Илнур абыйлары төрле–төрле гыйбрәтле вакыйгалар турында сөйли, акыллы киңәшләр бирә, ә бу балаларга бик ошый. Мондый вакыйгалар турында сөйләп, ул киләчәк буынның үзеннән гыйбрәт алуларын һәм, шукланып, юләр эшләр башкармавын тели. «Газ бик файдалы, ләкин куллана белмәсәң, зыян да китерергә мөмкин. Шуңа күрә, балалар, уттан һәм газдан дөрес файдаланыйк, үзебезгә һәм тирә–юньгә бәла китермик!» – ди газчы Илнур абый.

*2-нче урын*
***Гөлия Яруллина***

## Ялгышуның хакы кыйбат

Көттереп кенә килде быел кыш. Ак чикмәнен җәяргә, елгаларны көмеш бозга төрергә бер дә ашыкмады. Бар тереклекнең сагынып көткәненә дә исе китмәде. Бер көн бар дөньяны йомшак ап-ак кар капласа, икенче көнгә эреп юкка чыга барды. Әйтерсен көз белән кыш көрәшкә чыкканнар да шулай бил алышалар. Ә көчләр тигез, берсенең дә җиңеләсе килми.

Кошларның кәефләрендә табигатьнең көйсезләнүе чагылыш тапмаса да, җәнлекләр аптырап калдылар. Куян тунын алыштырырга–алыштырмаска белмәде, аю йокы вакытын көтеп түземсезләнде.

Ә малайлар-кызлар өчен кышның тоткарлануы зур сынауга әйләнде. Кемдер зур түземсезлек белән шугалакның катуын көтте; кемдер чаңгы-чана шуарга, кемдер кар тәгәрәтергә, «окоп»лар ясарга хыялланды.

Кинәт көрәш мәйданына кыш–батыр килеп чыкты. Ашыгып, табигать хатасын төзәтергә теләгәндәй, зәмһәрир суыкларын ирекка чыгарып, бөтен җирне кар өемнәре белән каплап та куйды.

Ниһаять, бар тереклек кинәт тынычланып калды. Җитез куян йомшак ап-ак тунын киде, аю тынычлап йокыга талды.

Тик кыш көтеп зарыккан малай-кызларның гына бер дә тынычланасы килмәде. Җитмәгәненә, бүген ял көне, укырга да барасы юк. Һәркем үз дәртен басарга, канәгатьләндерергә ашыкты. Ислам белән Фәрит тә, мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырасылары килмичә, урамга чыгып чапты.

Менә кайда ул дөньяның рәхәте! Бер нәрсә уйлыйсы юк. Рәхәтләнеп уйна, күпме кирәк карда ауна, чап, егыл. Кием дә пычранмый, әни дә ачуланмый, кагып төшердең, бетте китте эше. Башта малайлар кар атышып уйнадылар. Аннан соң «Нығытма алу» уены, «Кем тизрәк» уеннары да уйналды. Дүрт аяклы дуслар да чаналарга җигелде. Вакытның үткәне сизелмәде дә.

– Аһ! Фәрит, вакыт бик соңарган икән бит. Кайтыйк. Дәресләрне дә карыйсы бар. Иртәгә математикадан контроль эш. Әзерләнергә кирәк, – диде Ислам.

Фәрит ачу белән:

– Синең шул булыр инде. Иң кызык вакытта бөтен уенны бозып ташлыйсың. Без аны кабатламыйча да эшли алабыз бит. Сайла: мин яки... – диде дә туктап калды һәм, кинәт бер фикергә килеп, – безнең дуслык шуның белән бетәчәк, – дип өстәп куйды.

Ислам беркавымга аптырап калды. 6 нчы сыйныфка хәтле бергә укып, кая гына барсалар да, гел бергә булган дустыннан ул бу сүзләрне көтмәгән иде. Аңа бу минутта авыр, бик авыр иде. Дустына булган үпкә аның томалагандай итте. Бер сүз әйтмичә, ул кайту ягына борылды.

Фәриткә дә бу мизгел бик авыр тәэсир итте.Таякны ныграк бөгеп ташлаганын аңлады ул, Исламның аны сайлавына чын күңеленнән ышанган иде. Аның кәефе кырылды. Шулай да Исламга үзенең кем икәнен, нинди яхшы дусны югалтуын дәлилләргә булды. «Менә хәзер авылда беркемдә дә булмаган окоп ясыйм да бар кешене шаккатырам, үкенерсең әле минем кебек дусны югалтканга», – дип уйлады ул.

Инде вакыт соң булуга да карамастан, дүрт аяклы дусты Актүшне ияртеп, бакча башына окоп ясарга китте. «Менә, ичмасам, чын дус. Нәрсә әйтсәң дә каршы килми»,–дип уйлады Актүш турында. Карны, ашыга–ашыга, өемнәргә өя башлады.Тик кар бик йомшак булганлыктан, кар өемнәре ишелә торды. Кәефе тагын да ныграк кырылды Фәритнең. Әмма уеннан кире кайтмады. «Бүген булмаса, иртәгә булыр. Нәрсә дә булса уйлап табармын»,– дип өенә юнәлде.

Юлда кайтканда, аның башын мең төрле уй борчыды. Иртәгә нишләргә? Ислам белән үзеңне ничек тотарга? Эндәшергәме аңа, юкмы?

Үз-үзе белән сөйләшә торгач, төпле бер фикергә килде ул: әлбәттә, сөйләшмәскә. Ислам яхшы дус, ләкин ул бит Фәритне сайламады. Безнең дуслык аңа бик мөһим түгел, күрәсең. Юк, аңа эндәшү – үзеңне түбән кую, горурлыкны җимерү булыр иде. Аның башын шундый уйлар бораулады. Кайтып дәресләренә утыргач кына, әзрәк тынычлангандай итте Фәрит.

Иртәгесен алар мәктәптә очраштылар. Икесе дә бер–берсен күрмәмешкә салышты. 6нчы сыйныфка кадәр бер табактан диярлек ашап, һәрвакыт аглый белән таглый булып йөргән ике дусның бер–берсен күрмәмешкә салышулары сыйныфташларга бик сәер тоелды. Бирелгән сорауларга бер дә җавап булмагач, сыйныф-

ташлар да кул селтәделәр. Теләсә нишләгез, янәсе. Ошый икән, йөри бирегез шулай.

Ә дусларның барысы да эчтә иде. Һәрберсе эчтән генә янды, көйде. Фәрит Исламны дуслыкны җимерүдә гаепләсә, Ислам Фәритне авыр сайлау алдына куюда гаепләде. Тик берсе дә баш бирергә җыенмады.

Көннәр үтә торды. Контроль эшләр дә, язма эшләр дә эшләнде. Бар да бер җайга салынып барды кебек. Тик дусларның гына хәлләре мөшкел иде. Күршеләр генә булсалар да, бер-берсен күрмәмешкә салыштылар. Таш бастырганнармыни: күңелләре дә авырайганнан авырая барды. Кайчандыр шундый зур куанычлар алып килгән кар өемнәре дә сөендермәде.

ДӘВАМЫ БАР

*3-нче урын*
***Диләрә Галимуллина***

# Җир-Ана авазы
# (әкият)

Борын-борын заманда яшәгән, ди, Былтыр атлы мәрхәмәтле бер егет. Ул табигать дусты икән. Көн дә урманга, сахраларга чыга икән, кош-кортларның, бөҗәкләрнең, хайваннарның, агач-үсемлекләрнең хәлләрен белешә икән, кирәк булганнарына ярдәм дә итә, ди. Ә урманда нинди генә агачлар үсми икән: меңьяшәр имәннәр, төз буйлы чыршы-наратлар, зифа ак каеннар... Ә алар төбендә нинди генә җиләкләр үсми дә, нинди генә гөмбәләр юк икән. Урманга килүчеләр табигать нигъмәтләрен җыеп кына түгел, ә җаннарына дәва, сихәт тә алып китәләр икән. Вак-вак бөҗәк-кортларыннан алып, төрле төсле күбәләкләре күзләрне иркәләсә, сайрар кошлары күңелләрне хушландыра, ди. Сахраларында да шундый ук гүзәллек. Былтыр урман–сахралар белән шулкадәр дуслашып беткән ди, берәр авырлык яки куркыныч янаса, ул күңеле белән тоярга да өйрәнгән. Шулай итеп, урман-сахралар, Былтыр белән бербөтен булып, бик матур гына яшиләр, ди.

Менә шулай, һәрвакыттагыча, Былтыр урманга китә. Урман үзенең саф һавасы, хуш исле чәчкәләре, рәт-рәт тезелгән агачлары, сайрар кошлары белән каршы ала. Былтыр үзенең яраткан аланына таба атлый. Шулвакыт ул: «Тукта! Сак бул! Безне таптый күрмә!» – дигән тавышлар ишетә. Тирә-якка күз сала, тик якында беркем дә күренми. Шулвакыт янә: «Аяк астыңа кара, без монда», – дигән тавыш кабатлана. Былтыр, иелеп җиргә караса, анда җир җиләге яфрагының сизелер-сизелмәс кенә селкенгәнен күреп ала. Яфракны күтәреп караса, бер төркем кырмыскалар җыелышып, кып-кызыл җир җиләген өстерәп кайталар икән. Былтыр бу юлы да үзенең кечкенә дусларына ярдәмгә ашыга. Тырысына берсеннән-берсе сусыл, җитешкән җир җиләкләрен тутыра да кырмыскаларга бүләк итә.

Кырмыскалар, урман дуслары, Былтырга хөрмәт йөзеннән тылсымлы салам таягы бүләк итәләр. «Сиңа ярдәм кирәк булганда, менә шушы тылсымлы сүзләрне кабатла: «Салам тая-

гы, салам таягы, тылсым көченә ия таяк, үзеңнең тылсымыңны күрсәт, миңа ярдәм ит!» һәм шуңа өч тапкыр өр, – дигән өлкән кырмыска. – Тик шуны онытма, Изге җан иясе, бу таяк синең ике теләгеңне генә үтәячәк». Былтыр сөенә-сөенә өенә кайтып китә. Юлда кайтканда: «Тылсымлы таяктан нәрсә генә сорарга икән? Планшетмы, компьютермы, әллә ipadмы? Ярар, бераз торсын әле, аннары күз күрер», – дигән.

Тик көннәрдән бер көнне урманга бик зур куркыныч янаган, ди. Ниндидер кешеләр зур–зур тракторлар белән килеп, урмандагы төз буйлы агачларны кисә башлаганнар. Урман, авыртуга түзә алмыйча, бик каты ыңгырашкан. Кешеләр моны ишетмәгәннәр дә, үз эшләрен дәвам иткәннәр. Мең еллар буена хайваннарның, кош-кортларның тору урыны булган җәннәт почмагын бик тиз арада кисеп тә бетерәләр. Урманда моңсулык һәм бушлык хөкем сөргән. Монда сугыш булып үткән шикелле: җирләр актарылган, үсентеләр трактор тәгәрмәчләре астында калып өзгәләнгән, кош-кортлар, хайваннар кайсылары машина астында калганнар, кайсылары куркуларыннан урманнан чыгып та качканнар. Күп тә үтми, калын урман урынында агач төпләре, сынган агач кисәкләре, авыртуларына түзә алмыйча ыңгырашкан агач ботаклары, үлгән җәнлекләр, җансыз кош–кортлар гына калган. Җиләкләр дә, гөмбә–чикләвекләр дә юкка чыккан. Табигать үзенең җан өзгеч тавышы белән мәрхәмәтле кешеләрне ярдәмгә чакыра: «Ярдәм итегез! Коткарыгыз мине!»

Күпмедер вакыттан Былтыр да килеп җитә. Мондагы хәлләрне күреп, бермәлгә телсез кала. Аңына килгәч, Җир-Ананы кочаклап, үксеп елап та җибәрә. Вакытында ярдәм кулы суза алмаганына, урманга зыян салган кешеләрне рәхимсез эшләреннән туктата алмаганына, бик озак әрнеп елый. Урманның да хәле бик авырдан. Инде хәзер нишләргә? Урман бит ул – планетабызның үпкәсе, планетабызга болай да куркыныч яный. Хәзер кешеләр, җәнлекләр, бөҗәкләр нинди һава суларлар? Агачлар бит углекислый газны йотып, безгә кислород бүлеп чыгара. Тереклек бик зур куркыныч алдында бит. Эх, кешеләр, нишләдегез сез, ник урманнарны кисеп бетердегез?..

Шулай бик озак хәсрәткә бирелеп утырган Былтыр. Көн кичкә авышкач, кайтыр юлга кузгалган. Шулвакыт акыллы кырмысканың сүзләре исенә төшә, һәм, сөенеп, салам таягын һавада болгап җибәрә дә тылсымлы сүзләрне пышылдый: «Салам

таягы, салам таягы, тылсым көченә ия таяк, үзеңнең тылсымыңны күрсәт, урманга ярдәм ит!» һәм аңа өч тапкыр өрә.

Менә тылсым кайда ул! Күз ачып йомганчы, үлгән урман терелә башлый, тирә-якка үләннәрдән, агачлардан хуш ис тарала, кош-кортлар сөенечләреннән сайрап җибәрәләр. Агачлардагы яшел яфраклар кояш нурларына коена, Былтырга иелеп елмаялар, ә агач ботаклары башларын ияләр. Җир-Анабыз сөенеченнән җиңел сулап куя. Былтырга рәхмәт йөзеннән менә нәрсә ди: «Мәрхәмәтле җан иясе! Табигатьне саклап калу өчен, никадәр зур эшләр эшләдең. Инде кешеләр агачларны башка кисмәсеннәр, табигатькә зыян салмасыннар. Мин кешелек дөньясына зәңгәр ягулык бүләк итәм. Аның исеме газ булыр».

ДӘВАМЫ БАР

## Шаян турында әкият

Шәһәрдә җәйге иртә. Кешеләр эшкә ашыга. Мәктәпләр буш, балалар каникулда. Безнең Зилә дә, уңышлы гына 3нче сыйныфны тәмамлап, җәйге ялга чыкты. Аның Акйомгак исемле бик матур песие бар. Быел Акйомгакның өч баласы туды. Зилә аларга Шаян, Йомшаккай, Чәчәк исемнәре кушты. Песи балалары бер дә тик торуны белмиләр, гел шаяралар, мәш киләләр. Акйомгак көне буе нәниләренә азык табу белән мәшгуль.

Беркөнне, иртәнге аштан соң, Акйомгак, гадәтенчә, тычкан тотарга китте, ә балаларына өйдән чыкмаска кушты. Зилә дә бүген өйдә юк. Ул, иптәш кызлары белән, паркка ял итәргә китте. Шулай итеп песи балалары өйдә үзләре генә калды. Әй, рәхәтләнеп уйнадылар да соң! Төш вакыты җитте. Песи балаларының тамаклары ачыкты. Ә әниләре нигәдер күренмәде. Шулвакыт Чәчәк:

– Абыйларым, әйдәгез кибеткә барабыз, – диде. Шаян белән Йомшаккай шуны гына көткәндәй, бик теләп риза булдылар.

Менә алар урамга чыктылар. Урамда исең–акылың китәрлек икән бит… Юл кырыйларына зур-зур агачлар, матур-матур чәчәкләр утыртканнар. Ә чәчәкләр янында төрле төстәге күбәләкләр уйнаклап оча. Песи балалары шушы матурлыкны күреп, дөньяларын оныттылар. Әле бер күбәләк артыннан, әле икенчесенең артыннан куа башладылар. Тик араларыннан уртанчысы Йомшаккай гына урамдагы машиналарның күплегенә игъ-

тибар итте, юлны болай гына чыгып булмаслыгын аңлады. Шулвакыт аның күзе светофорга төште. Кайда күргәне бар иде соң мондый өч күзле багананы? Әәә, исенә төште, Зиләнең китабында күргән иде бит әле. Әле ул вакытта Зилә аларга бу багананың светофор икәнен, аның ни өчен кулланылганын сөйләгән иде. Менә хәзер Зиләнең сөйләгәнен искә төшерергә кирәк инде. Ул вакытта Зиләне тыңлыйсы калган да бит… Йомшаккай үзе артыннан Шаянны, Чәчәкне ияртеп, светофор янына килде. Озак көтәргә туры килмәде, светофорда яшел ут янды. Песи балалары юлларын дәвам иттеләр. Юл аркылы чыккач, Йомшаккай:

– Чәчәк, безнең Шаян күренми ич! – диде, як–ягына карап.

Шулвакыт машиналар кычкырта башлады. Чәчәк белән Йомшаккай шул якка юнәлде. Ни күрсеннәр, юл уртасында Шаян ята. Бер аягы өзелгән, юлга кан чәчрәгән. Ашыгыч ярдәм машинасы Шаянны шифаханәгә алып китте.


Эшнең нидә икәнен соң гына белделәр песи балалары. Юлны аркылы чыкканда, Шаян күбәләк күреп, кая барганын да онытып, аны куып китә. Тик… күбәләк тоттырмый, ә Шаянны машина тапты.

Чәчәк белән Йомшаккай куркып кына өйләренә кайталар. Әниләре күптән кайткан. Балаларын эзли-эзли йөдәп беткән, җитмәсә, Шаянның юклыгын күреп, тагы да каты борчыла башлады. Балалары ни булганын сөйләп бирделәр.

Берничә көннән Шаян савыгып өенә кайтты. Шул көннән әниләре юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтә башлады. Песи балалары да, әниләре өйрәткәннәрне, кызыксынып тыңладылар. Тиз арада бу кагыйдәләрне үзләштерделәр. Хәзер инде урамда курыкмыйча хәрәкәт итәләр икән.

Ә сез, дусларым, юл йөрү кагыйдәләрен беләсезме?

# Публицистика



ПУБЛИЦИСТИКА
12-14 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Зилә Габдрахманова***

## Тракторчы апаем

*Бөек Җиңүнең 75 еллыгы якынлаша. Мәктәбебездә төрле кичәләр үткәрелә, рәсемнәр, иншалар бәйгесе оештырыла. Һәрберсендә батырларыбыз искә алына, аларга дан җырлана, хәтирәләр барлана. Мин уйга калам... Сугыш җиле бит бер гаиләне дә уратып узмаган!*

Минем әбиемнең апасы Гыйләҗиева Фәрзәнә Гыйләҗетдин кызының да бу еллар бөтен уй-хыялларын, яшьлегенең иң гүзәл елларын чәлпәрәмә китерә. Ул 1922 елның 15нче апрелендә Наласа авылында дөньяга килә. 1941 елда Бөек Ватан сугышы башланганда Фәрзәнә апага 19 яшь була. Бөтен ир-егетләр сугышка китеп бетәләр. Авылдагы барлык эш карт-корылар, хатын- кызлар җилкәсенә төшә. Фәрзәнә апаны һәм башкаларны еракка, окоп казырга җибәрәләр. Шул вакытлар турында Фәрзәнә апа: «Бик салкын, ачлыктан, хәлсезлектән авыр ломнарны тотып торып булмый иде. Ләкин җиңү өчен түзәргә тырыштык», – дип сөйләгән. Читен булса да бирешмәгәннәр,түзгәннәр. Авылда колхозда эшли алырлык ир-атлар калмаганлыктан, трактор штурвалы артына утыру да хатын-кызларга туры килә. Шуңа күрә Фәрзәнә апа һәм берничә хатын-кыз тракторга укыйлар һәм эшли дә башлыйлар.

Үзем шушы юлларны язам, ә үзем эчтән генә горурлану хисләре кичерәм. Апаем турында тагын да күбрәк беләсем, аның бу батыр хезмәте турында башкаларга да җиткерәсем килә. Илебез өчен мәңге онытылмаслык шушы дәһшәтле елларда Фәрзәнә апаның күрсәткән фидакарь хезмәте, батырлыгы турында үзе дә сугыш чоры авырлыкларын күргән Зәйтүнә әбием гел искә ала һәм горурлану хисләре белән сөйләргә ярата. Шуңа да әбиемнән кабат сорашырга булдым әле.

– Яшь вакытта ниндиерәк иде ул Фәрзәнә апа?

– Апай бик чибәр иде, гади генә киемне дә бик матур итеп кия белә, чәчләрен гел матур итеп үреп йөри иде. Эшкә дә бик ба-

тыр булды. Бернәрсәдән дә куркып тормады. Усал Фәрзәнә диеп тә әйтәләр иде аны. Бик шәфкатьле, туры сүзле, гадел усал иде ул.

– Сугыш елларында ул нинди эшләр башкарды?

– Ул елларда бар кешегә дә кыен булды. Ирләр сугышка китеп бетте, эшләргә кеше калмады диярлек. Кем аякта йөри ала, бөтенесе эшләде: балалар да, картлар да, хатын-кызларны әйтәсе дә юк. Гаиләдә апайга барыбызга караганда да авыррак булгандыр. Чөнки ул җиткән кыз иде. Гаиләсе , баласы булмагангадырмы аның кебекләр авыр эшләрдән кайтып кермәделәр. Урман кисәргә дә, окоп казырга да, станциягә барып вагоннар бушатырга да – әйтеп бетергесез авыр барлык хезмәттә йөрде ул. Кышкы салкыннарда кияргә киеме дә , ашарга ризыгы да юк иде бит.

– Тракторда эшләргә ничек курыкмады икән?

– Куркуын курыкмавын хәтерләмим инде. Үзе генә белгәндер, ирләргә дә йөгәнләргә кыен булган бит ул вакыттагы тракторларны. Бәлки бераз ашарга булыр диеп тә уйлагандыр. Тракторда эшләгәннәргә икмәк бирелә иде. Апай аркасында без ул авыр елларда ачлык күрмәдек.

– Сугыш беткәч тә тракторда эшләвен дәвам иттеме?

– Бик озак эшләде ул анда. Сугыш беткәч тә, авылга ир–егетләр кайткач та аерылмады «тимер атыннан». Эшен намус белән башкара иде. Көнне төнгә ялгап эшләде дә эшләде.

– Әби, туганнарың арасыннан иң яратканы Фәрзәнә апа дип әйтә идең, ни өчен?

– Апай безнең барыбызны да ачлыктан коткарды, ул булганга мин авырлык күрмәдем. Сугыш кырында сөйгәнен югалткан Фәрзәнә апаем, гомере буе ялгыз яшәсә дә, тормышның авырлыкларына бирешмәде, гомеренең соңгы көннәренә кадәр безгә зур терәк булды.

ДӘВАМЫ БАР

*2-нче урын*
***Ильвина Шәйхуллова***

## Телефон наркотикмы, әллә замана чиреме?!

*Мөгаен, һәрберебезнең бу сорау алдында уйланганы бардыр: «Без нәрсәдән башка үзебезнең тормышны күз алдына китерә алмыйбыз соң?» Әлбәттә инде, кешелеккә һәрдаим кирәк әйберләр рәтенә– су, һава, ризык… Һәм дә инде телефон керә.*

Телефон һәрдаим безнең белән: телефон белән уянабыз– телефон белән йоклап китәбез. Ашаганда да, урамнан атлаганда да ул безнең белән.

Күбебез тере аралашуга караганда, гаджетлар аша аралашуны хуплый. Әйе, бәлкем алай кулайрыктыр да. Машинада, автобуста барганда да сөйләшеп була бит. Тик, кара каршы утырып сөйләшүгә җитми инде.

Менә шул телефонны һәрдаим куллану, аннан бәйле булу, телефонны югалтудан курку– номофобия (инглизчәдән – «no mobile phone» – телефон юк) дип атала. Бу фобия хәзерге яшьләр арасында гына түгел, өлкән буында да бик популяр.

Тик телефоннан бәйле булу бик тә зыянлы. Мәсәлән: өй эше эшләргә утырдың ди һәм телефоныңа хәбәр килде. Шуны гына укырга кердең, ә актыкта инде ничә сәгать утыргансың. Бу сиңа мөгаен таныштыр. Ә зыяны– дәресеңне хәзерли алмадың,һәм дә инде күз күремең начарланды.

Әмма бу проблемадан да чыгу юлы бар:

- Телефоныңа урнаштырылган кушымталарны барлап чык. Һәм уйла: кайсы сиңа хәрдаим кирәк, аларын калдыра аласың. Ә менә зур әзәмияткә ия булмаганнарын бетереп ташла.
- Вакытны иң күп ала торганы социаль челтәрләрде фотосүрәтләр карап, лайклар куеп утырудыр инде. Ә синең уйланганың бармы: «нигә инде бу миңа?» – дип? Шуның өчен үзеңа таймер куй. Һәм сүзеңдә тора бел. Куелган вакытың бетү белән кушымтаны башка кулланма.
- Өйдә вакытта телефоныңны кесәдә йөртмә. Читкәрәк алып куйсаң– тагы да яхшырак.

- Йокы вакыты җиткәч телефоныңны мендәр астына тыкма. Анда аңа урын түгел. Сүндереп, еракkарак алып куй. Чөнки, йокыга китә алмыйча ятсаң, кабат телефонны кулыңа алачаксың.
- Китапларны телефоннан укымаска тырыш. Күз күремең начарланачак. Фильмнар белән дә шул ук хәл. Карыйсың килсә, зуррак экраннан, мәсәлән: телевизордан карый аласың.
- Сәгатьне карарга дип кенә алып та, озак вакыт утырган чаклар була. Шуның өчен, кул сәгате ал. Шул вакытта сәгатьне телефонсыз да белә алачаксың.
- Ял вакытында, саф һава суларга чыкканда телефоныңны кулыңа алмаска тырыш, ә инде өйдә калдырсаң тагын да яхшырак.
- Һәм иң соңгысы – телефоныңа озын пароль сайла. Бу сиңа телефонны кирәкмәгәндә дә алырга юл куймыячак.

Тик шунсын да аңларга кирәк: бу лайфхаклар сиңа телефонсыз тормыш башларга түгел, ә телефонга азрак вакыт сарыф итәргә булышачак. Чөнки, без егерме беренче гасыр кешеләре һәм безнең тормышны телефонсыз күз алдына да китереп булмый. Ул безгә мәгълүмат чыганагы да, аралашу чыганагы да булып тора.

Әгәр син шушы кагыйдәләрне үтисен икән, синең өчен «яңа» – телефонсыз тормыш башланачак. Тырышып кара. Барсы да синең кулда!

*3-нче урын*

***Нарим Сәлмәнов***

## Уен да, эш тә, киләчәкне кайгырту да

*Минем бик тә машина йөртәсем килә. Ләкин әле иртәрәк шул. Миңа 12 генә яшь. Моның өчен машина йөртә белү генә җитми, юл кагыйдәләрен яхшы белергә кирәк. Минем кебек кечкенәләр өчен юл куркынычсызлыгы яшь инспекторлары отряды бар икән. Мин шунда йөри башладым. Юл йөрү кагыйдәләрен белү машина йөртүчегә генә түгел, җәяүлегә дә, велосипедчыга да – бөтен кешегә дә кирәк бит. Монда без күп нәрсәләргә өйрәнәбез. Юл билгеләре куелган махсус урында җәяү һәм велосипедта дөрес йөрергә дә, беренче ярдәм күрсәтергә дә безне җитәкчебез Рәсип Рәшит улы Гатиятов өйрәтә.*

Безнең отряд Яр Чаллы шәһәрендә үткән «Хәвефсез тәгәрмәч» бәйгесендә катнашты. Ярышырга республиканың барлык районнарыннан бик күп укучылар җыелган иде. Монда үткәргән дүрт көн миңа бик ошады. Шул турыда сезгә дә сөйлисем килә.

Иртәгә ярышка китәсе көнне мин бөтен кирәк әйберләремне әзерләдем. Бик иртә китәргә кирәк булганга, соңга калмыйча йокларга яттым.

1нче көн: 24нче апрель, сишәмбе. Сәгать алтыда юлга кузгалдык. Безнең командада дүрт кеше: ике кыз, ике малай. Юл бик озын , дүрт сәгать бардык. Сөйләшеп, көлешеп бару бик күңелле булды.

Барып җиткәч, регистрация үттек тә бүлмәләребезгә кердек. Төшке ашны ашагач, велосипедта фигуралы йөрү буенча беренче ярышны үттек. Кич белән дискотека булды. Рәхәтләнеп биедек, шаярдык.

2нче көн:25нче апрель, чәршәмбе. Бүген йокыдан тору 7нче яртыда булды. Бик тәмләп, иртәнге ашны ашадык. Аннары жюри безнең иҗади чыгышларны бәяләде. Бик тырышып, җырлар, шигырьләр өйрәнеп килгән идек. Яшь инспекторлар формасын да киеп куйгач, чыгышыбыз бик матур булды. Күңелләребез күтәрелеп китте. Төшке аштан сон, тормыш иминлеге нигезләре буенча сынау үттек. Барысын да әйбәт кенә башкардык. Беренче ярдәм күрсәтү, төрле хәлләрдә үзеңне ничек тоту турындагы со-

рауларга җаваплар бирдек, биремнәрне эшләп тә күрсәттек. Көн бик матур үтте. Йокларга яткач та, бик озак сөйләшеп, кызык хәлләрне искә төшереп көлешеп яттык.

3нче көн, 26нчы апрель, пәнҗешәмбе. Бүген соңгы бәйге. «Ул автошәһәрчек» дип атала. Шәһәрчек итеп эшләнгән урында, бөтен юл кагыйдәләрен үтәп, маршрутны узарга кирәк. Монысы да булды! Төштән соң барлык катнашучыларны балалар өчен күңел ачу үзәгенә алып бардылар. Рәхәтләнеп уйнадык. Бик күңелле булды. Шунысы кызык: без барыбыз да бертөсле, чөнки килгән көнне үк һәрберебезгә ЮИД дип язылган футболка һәм баш киемнәре биргәннәр иде.

4нче көн: 27нче февраль, җомга. Бүген соңгы көн. Иртәнге ашны ашауга, бүләкләү тантанасына киттек. Ул бик матур җирдә – Яр Чаллы шәһәренең балалар иҗат сараенда үтте. Мин һәм дустым «Автошәһәрчек» бәйгесендә призлы урын яулаганбыз. Безгә диплом һәм бүләк алу өчен сертификат бирделәр. Үзем һәм дустым өчен мин бик шатландым. Бүләкләүдән соң, төшке ашны ашагач, юлга җыендык. Ура! Өйгә кайтабыз! Сагындырган. Эш күп булганга гына сизмәгәнмен.

Яшь инспекторлар отрядына йөри башлагач һәм «Хәвефсез тәгәрмәч»кә әзерләнгәндә, мин күп нәрсәләргә өйрәндем. Үзем белгәнне иптәшләрем белән дә бүлешәм. Боларны белү гомерләрне саклап калырга мөмкин бит. Яшь инспектор исемен йөртү миңа бик ошый. Ә бәйгедә, тагын да яхшырак әзерләнеп, киләсе елга да катнашасым килә. Барлык кешеләргә хәвефсез юллар телим! Юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәгез!

15-18 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Ләйсән Абдрахманова***

## «Илһам» канатлар куя

*Кем син? Иҗатка гашыйк кешеме? Прозаикмы, әллә шагыйрьме? Һаман да үз сәләтеңне таба алмыйча интегәсеңме? Яки таптың, әмма куркасың. Ялгышудан. Адашудан. Барыннан...*

*Әйе, сәләтеңне табу кыен, аны үстерү тагын да кыенрак. Гәрчә моның өчен мөмкинлекләр бик күп булса да. Авыр. Бик авыр. Шулай да үзендә ихтыяр көче тапканнар гына алга бара, тырышлар гына уңышка ирешә.*

Әйткәнемчә, сәләтеңне үстерү, үз көчеңне сынап карау өчен, конкурслар хәзер бик күп. «Сәләт»кә нур булган йолдызлар», «Газпром», «Иделем акчарлагы», «Үз юлым»... Ләкин мин бу юлы әлеге бәйгеләр турында түгел, ә «Илһам» турында язарга телим. Юк, дөрес аңлагыз: «вдохновение» түгел, нәкъ менә «Илһам» Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесе.

«Илһам» Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесе ТР Язучылар берлеге, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан Федераль университеты белән берлектә 2014 елдан бирле үткәрелә. Ул ел саен, татар теле һәм әдәбиятын үстерү максатында, сәнгать белән кызыксынган һәм иҗатка гашыйк балаларны җыя. Әлеге бәйгедә укучылар дүрт номинациядә (проза, шигърият, драма, публицистика) һәм өч яшь категориясендә (5-7 сыйныфлар, 8-9 сыйныфлар, 10-11 сыйныфлар) көч сынаша.

Быел «Илһам» бәйгесенә Татарстаннан һәм Россия төбәкләреннән 1624 эш килә. Шуларның иң яхшы дип табылган 600е икенче турга чакырыла.

Икенче тур берничә зонада үтте. Нәкъ менә шул турда , балаларның әсәрләрне үзләре язганмы-юкмы икәнлекләрен тикшергәннән соң гына, җиңүчеләр ачыкланды.

25 апрель көнне Казанның Идел буе спорт һәм туризм академиясендә «Илһам» Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесенең бүләкләү тантанасы булды. 34 җиңүче алтын хәрефләр белән

йөгертелгән диплом, «Эльдорадо» кибетенә сертификат һәм үз әсәрләре тупланган «Илһам» альманах–китабы белән бүләкләнде.

Шушы җиңүчеләр арасында үзебезнең исемнәрне күрү чын бәхет иде. Апам Айзилә белән икебез дә «Проза» номинациясендә беренче урын яуладык: ул – 8-9 сыйныфлар арасында, мин – 5-7 сыйныфлар арасында.

Әйдәгез, хәзер җиңүчеләрнең үзләре белән танышып китик. Бүләкләү тантанасында алар ниләр кичерде икән?

«Проза»да Гран–при алган кыз Хәбибулина Алинә (Азнакай районындагы сәләтле балалар интернатының 11 нче сыйныф укучысы):

«Мин «Илһам» бәйгесендә беренче мәртәбә сигезенче сыйныфта укыганда катнашкан идем. «Илһам»лы юлым дүрт ел дәвам итте, һәм аның азагында шундый зур бәяләнүгә лаек булу, әлбәттә, минем өчен искиткеч зур сөенеч булды. Үземнең уңышым турында ишеткәч, бераз куркып куйдым: мин андый югары бәяләнүгә лаекмы соң? Башкаларның өметләрен аклармын дип ышанып калам».

«Проза»да 1 урынга лаек булган Абдрахманова Айзилә (Кайбыч районы Борындык төп мәктәбенең 9нчы сыйныф укучысы):

«Мин «Илһам» бәйгесендә беренче тапкыр катнаштым. Берәр нинди призлы урын булыр диеп, һич тә уйламаган идем. Регистрация үткәрүче апаның «Синең беренче урын» диюеннән соң чак кына егылып китмәдем, шатлыгымнан күз яшьләрем атылып чыкты. Әлеге бәйге миндә бары тик уңай яктан гына һәм иң бәхетле, иң күңелле вакыйга булып истә калды».

ДӘВАМЫ БАР

## Мәгариф министры белән очрашу, яки Канатлар киселгән көн

*Сез кечкенә чакта кем булырга хыяллана идегез? Кибетче, пешекче, бәлки, укытучы… Бу исемлекне туктаусыз дәвам итәргә була. Я инде, әйтегез. Оялмагыз. Хм, белмисезме? Әллә инде төгәл сайлаган профессиягез юкмы? Яки җавабыгыз мең төрлегә үзгәрәме?*

Ә мин андый түгел! Мин кем булачагымны төгәл беләм!.. беләидем…бүгенгә кадәр…

Министр булырга хыяллана идем мин. Ничә яшь булгандыр, белмим, әмма әти-әнием сүзләре буенча, бу сүзне әйтә белмәсәм дә, «Кызым, үскәч кем буласың?» дигән сорауга җавабым бер булган: «Мимистр!». Үсә төшкәч, бу хыял тагын да ныгыды. Әмма спорт министры да, урман яки авыл хуҗалыгы министры да түгел, нәкъ менә Мәгариф министры. Күрәсең, укытучы булып эшләүче әниемне көнозын, хәтта кичләрен дә күрмәү, аның назын туймыйча йоклап китүләр һәм шуңа күрә мәктәпне үзгәртергә теләү сәбәпче булгандыр моңа. Ләкин бүген бу хыялым чәлпәрәмә килде…

21нче март. Яз. Әкренләп кояш чыккандай була. Җылыта инде. Күңелемдә дә ниндидер җылы сөенеч бар, чөнки мине бүген зур очрашу көтә. Мәгариф министры Рафис Тимерхан улы Борһанов белән!!! Хыялга бер адым…

Ниһаять, мин – очрашуда. Якты зал. П хәрефе формасындагы өстәл. Өстәл артында минем кебек балалар. Тынлык хөкем сөрә. Бөтенесе ниндидер могҗиза көтә. Менә, горур гына атлап, Рафис Тимерхан улы Борһанов килеп керде. Әңгәмә башланып китүгә, без аны сорауларга күмдек. Тик, ни кызганыч, бөтен сорауларыбызга да җавап ишетү насыйп булмады. Ишеткән кадәр җаваплар да күңелгә җиңеллек китермәде. Хәзер шуларны сезгә дә тәкъдим итәм. Киттекме?

ФГОС. Барыбызга да таныш сүз, дөресме? Сез аны кирәк дип уйлыйсызмы? Әллә, кайбер танышларым кебек , «кирәкмәгәнгә балаларны тилмертү» дип исәплисезме? Ә менә Р.Т.Борһанов ФГОСны кире какмады. Ул аны кирәк дип саный. Балалар «башлы» булып үсә, имеш. Елга ике тапкыр имтихан бирү дә – аның өчен гадәти хәл. Димәк, берни дә үзгәрмәде. Канатлар гына киселде…

Бердәм дәүләт имтиханнары. Күбегезне борчыйдыр ул. Мин дә, 7нчедә генә укысам да, бу хакта сорамыйча кала алмадым. «Хәзер Казандагы югары уку йортларында бюджет урыннары бик аз. Аларга укырга керү өчен, БДИда бик югары баллар җыярга кирәк. Казанда укырга керү мөмкинлеге булмагач, мәктәп тәмамлаучы күп кенә егет–кызлар башка шәһәрләргә китәләр». Бу мәсьәләне күтәргәч, министр каушап киткән кебек булды. Шулай да үз фикерен үзгәртмәде, читләтеп кенә болай диде: «Бу сорауга мин түгел, ә Рособрнадзор җавап бирергә тиеш». Аннары: «Тырышып укыгыз. Барысы да үзегездән тора», – дип өстәп куйды… Монысы да булмады. Ярар. Алга киттек.

ДӘВАМЫ БАР

## «Лампочкага сикерәсем килгән иде», яки Укытучылык – озын гомер сере

*Мәктәбебез зур түгел: балалар да, укытучылар саны да аз. Тик аның мактанырлык тарихы, горурланырлык шәхесләре күп. Шундый остазларның берсе – гомере буе татар теле һәм әдәбияты укытучысы һәм укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшләгән, 9нчы июньдә 93 яшен тутыручы Фәйрүзә Гәрәй кызы Фатыйхова.*

Апас районы Болын–Балыкчы авылында туган Фәйрүзә апаның яшүсмерлек чорына Бөек Ватан сугышы туры килгән. «1942 елның кышы бик салкын булды. Безнең хуҗалыктан окоп казырга кеше юк. Әнкәйгә окоп казырга дигәч, аның өчен үзем киттем. Ләкин анда миңа кәйлә–көрәк тоттырмадылар, җир казытмадылар. Мин учак ягучы һәм кирәк–ярак ташучы булып кына йөрдем», – дип искә ала ветеран.

Унынчы сыйныфны тәмамлагач, өлкән абыйсының киңәше белән, Фәйрүзә апа Казан Дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. «Абый үзе дә армиягә кадәр үк укытучы булып эшләде. Аннан соң да гомере буе рус теле укытты. Кыз балага укыту, музыка һәм сәнгать өлкәсендә эшләсә, яшәү җиңелрәк була, диде абыем. Абыйның бу сүзләре миңа нык тәэсир итте, ахрысы», – ди ул.

Авырлыклар аша килә уңыш

«1945 елның сентябрендә мәктәп бусагасын укытучы булып атлап кердем. 1969 елга кадәр, 24 ел буе Болын–Балыкчы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыттым. Тормыш иптәшем Борындыкка колхоз рәисе итеп билгеләнгәч, туган авылымны ташлап, монда күченергә туры килде. Шул көннән башлап 1982 елга кадәр, Борындык урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыттым. Эшләү дәверендә авырлыклар күп булды, ләкин авырлыктан курыкмадым. Коллективта дуслык урнаштырырга тырышып, кайсын ишетмәгәнгә–күрмәгәнгә салышып, шушында укыту эшләре буенча директор урынбасары булып 14 ел эшләдем. Борындык мәктәбенең балаларын да, коллективны да, авыл халкын да бик яраттым».

«Әни, минем дә бит лампочкага сикерәсем килгән иде!»

«Бәхетле бала әнисе эшләгән мәктәптә укымый ул! Кече улым Айратны татар теле һәм әдәбияты дәресләреннән үземә укытырга туры килде. Үзем шунда завуч булгач, улымнан да тәртипле булуны таләп иткәнмендер инде. Ә бала бала бит инде ул. Тамагы тук булса, сикерә, чаба, дөньяны пыран–заран китерә. Чыгарылыш кичәсендә:

– Әни, минем дә башка малайлар кебек, кабинет ишегеннән чыккач, коридордагы лампочкага сикерәсем, шукланасым килә иде. Синең йөзеңә кызыллык китермим диеп, күп нәрсәдән тыелырга туры килде, – диде».

ДӘВАМЫ БАР

## Мин – мәгариф министры, имеш…<br>(Министрга хат)

Төш күрдем әле бүген. Бөтен нәрсә дә шундый сәер. Минем яныма бик күп балалар җыелган. Кайберләрен беләм дә бугай, йөзләре таныш. Кайберләре белән олимпиадаларда, төрле ярышларда, конкурсларда очрашканым бар кебек, араларында сыйныфташларым да күренгәли. Кем соң мин шуның хәтле? Нигә алар нәкъ минем янга җыелганнар? Кызык. Әйтерсең мин – патшабикә. Шәп!

Хискә бирелеп, озак ләззәтләнеп тора алмадым – уйларымны бүлдереп, миңа бер–бер атлы сораулар ява башлады:

– Ләйсән Айратовна, Сез – мәгариф министры, – дип дәште арадан бер укучы.

Мин аптырап калдым. Бу минем өчен көтелмәгән яңалык иде, ләкин берни дә булмагандай елмаерга туры килде. Ул сүзен болай дип дәвам итте:

– Укытучыларның кәгазь журналлары инде күптән юк. Ә бездән кәгазь көндәлекләргә язуны таләп итәләр. Бу өстәмә эш нигә кирәк соң?! Бөтен өй эшләре, билгеләр электрон журналга язып барыла бит.

Әйе шул. Бер кирәкмәгән әйбер ул – кәгазь көндәлек. Мин түзмәдем:

– Мин нишләтә алам соң? Барысы да миннән генә торган булса, күптән бетергән булыр идем инде мин аны, – дидем.

Ә балалар бар тавышка, ачуланып: «Сез бит министр!» –дип, кычкырдылар.

Аннары араларыннан әле берсе, әле икенчесе икенчесе сикереп торып, зарларын сөйли башладылар:

– Бездән укытучылар, хәтта кайбер әти–әниләр дә бик күпне таләп итәләр. Нәрсәдер эшли алмасаң яки ярдәм сорасаң: «Сез – ФГОС балалары. Шуңа күрә теманы без – сезгә түгел, ә сез безгә аңлатырга тиеш», – дип җавап кайтаралар. «Сез алдагы теманы үзегез кызыксынып өйрәнергә тиешсез», – дип, үтмәгән темалар буенча тикшерү эшләре бирәләр. Эшли алмасак, ачуланалар. Без гаеплемени алар аңлатмаганга? Темаларны үзлектән генә өйрәнерлек булгач, мәктәпкә дә йөреп тормыйк инде алайса?!

– ФГОС безне надан калдыра! Сез шуны аңлыйсызмы? Апа–абыйларыбыз сигезенче–тугызынчы сыйныфларда үткән темаларны без хәзер җиденче сыйныфта үтәбез. Без әллә алардан акыллыракмы? Имештер, 2003–2004 елда туган балалар – гений! Адәм көлкесе!

... Миңа таныш һәм таныш булмаган балалар ачуланып, берсен берсе уздырып, кычкырырга тотындылар:

–Безгә өй эшләрен бик күп бирәләр. Рефератлар, проектлар... Санап чыгарсаң, бер фәннән 10–15 бардыр.

–Безгә ял кирәк!

– Без көннәр буе бинада ябылып ятабыз: көне буе – мәктәптә, аннары – өйдә. Урамга чыгып һава суларга түгел, әти–әнигә булышырга да вакыт юк. Уйлап карасаң, барысына да сез гаепле. Әрлән кебек, читлеккә генә ябып куясыгыз калды бит!

– Сез – безнең вакытыбызны, энергиябезне урлаучылар!

Бу сүзләрдән соң калтыранырга тотындым, шабыр тиргә баттым: миңа бик авыр иде... Әле ярый...Әле ярый уянып киттем һәм озак кына тынычлана алмыйча яттым. «Әле ярый мин министр түгел!» – дип куандым мин ахырдан.

Рафис абый Борһанов, Сез дә уйланыгыз әле: бу сүзләрдә хаклык бар бит! Әйе, без – XXI гасыр балалары. Ләкин нинди генә гасыр булуга карамастан, бала бала инде ул! Үзегезнең мәктәп елларын, бала чагыгызны исегезгә төшерегез. Без дә бит сезнең кебек гап-гади балалар!

*1-нче урын*
***Талия Төхфәтуллина***

# Җылы сүз җан эретә

«Афәрин!», «Булдырасың!», «Син шундый акыллы!» Бу сүзләрне кем генә ишетергә теләми икән. Якын кешеләр тарафыннан әйтелсә, син үзеңне бер башка югары тоя башлыйсың. Әмма, ни кызганыч, соңгы вакытта безнең сөйләмебездә мондый мактау сүзләренең саны кими бара. Моның шулай икәнлегенә мин яшьтәшләремнең инстаграм–аккаунтларын карап чыкканнан соң төшендем.

Безнең сөйләм телебез дә, андагы мактау сүзләре дә бик аз һәм бик ярлы! Көндәлек тормышта кулланыла торган матур сүзләр «шәп», «афәрин», «бик матур», «матур», «гүзәл», «шәпский», «сез шундый чибәр», «матурка», «син шундый матур», «күз тимәсен», «тьфу–тьфу» һәм күп санлы «смайллар»лар белән чикләнә. Соңгылар хәтта мактау гыйбарәләренә карганда күбрәк тә. Димәк, без хәзер сүзләргә караганда күбрәк сурәтләргә игътибар итәбез, әйтәсе фикерләребезне ниндидер җансыз «смайл»лар аша җиткерергә тырышабыз икән.

Үземне борчыган сорауларга тагын да нигезлерәк җавап табу өчен, яшьләр арасында сораштыру үткәрдем. Тикшерү шуны күрсәтә: катнашучыларның барысы да мактау сүзләрен кулланалар. 23 кеше (77%) – мактау сүзен чын күңелдән, 7се (23%) – әдәп саклау йөзеннән генә әйтә. Күңелне борчыганы шул: 30 кешенең 8е (13%) генә «мин мактау сүзләрен еш ишетәм» ди, 27 % катнашучыга мактау сүзләре бик сирәк юллана, ә 13 % кешегә бөтенләй дә мактау сүзләре әйтмиләр икән.

«Мактау сүзләрен күбрәк кемнән ишетер идең?» дигән сорауга 67 % катнашучы – әти–әнидән, 17%ы – дусларыннан, 13 %ы – укытучылардан, 3%ы – сөйгән кешемнән, дип яза.

Нәтиҗәләр куанырлык түгел. Мактау сүзләренә булган дефицит гаиләгә барып тоташа түгелме соң? Димәк, бүгенге яшь буынга әти–әни тарафыннан игътибар гына түгел, җылы караш, ягымлы сүз җитми. Шул ук хәл мәктәптә дә дәвам итә. Күпчелек укытучылар тарафыннан бары тик коры «Молодец!» сүзе генә әйтелә. Үзе мактау сүзе ишетеп тәрбияләнмәгән бала кемгәдер

мактау әйтү турында уйлап тормас, яки «Молодец!» сүзеннән ары китмәс, билгеле.

Икенче сәбәп, мөгаен, татарның менталитеты белән бәйледер. Әби–бабаларыбыз мактауны чама белән генә кулланырга кушканнар, шулай ук кешегә матурлыгы яки башка сыйфаты турында «өстенә әйтмә, күз тияр», дип тә куркытканнар. Яисә мактаганда «Сөбханалла», яки «Күз тимәсен» дигән гыйбарәләрне кулланганнар.

Өченче сәбәп – без, яшьләр иң күп куллана торган интернетта татарча мактау гыйбарәләре, яки татарча сүзле смайллар юк. Ә мин аны эшләргә тәкъдим итәр идем. Нишләп әле безгә аларның татарча вариантларын ясамаска. Уңайлы да, заманча да.

Дүртенче сәбәп – яшь буынның китаптан шактый ерак булуы. Моның өчен нәрсә эшләргә соң? Әлбәттә укырга, классик әсәрләр – безнең телебезне, уй–фикерләребезне баетуның иң күп чарасы.

Шулай ук әлеге проблемадан чыгу өчен, мин мактау сүзләре язылган гыйбарәләрне халык еш була торган урыннарга, тагын әле шоколод, конфет кәгазьләренә урнаштырыр идем. Әйтик мәсәлән, чәчтарашханәләргә Г.Тукайның «Матурларның матурыннан матурсың!» дигән шигырь юлларын урнаштырырга мөмкин. Теш табибы бүлмәсенә – «Сезгә елмаю килешә», китапханәләргә – «Сез иң акыллы, яки тәрбияле»; җәмәгать транспортына – «Сез бик ихтирамлы» һ.б.; конфет кәгазьләренә – «Мин сезгә сокланам!», «Сез гаҗәеп!» һ.б. Минемчә, мондый язуларны уку күпләрнең кәефен яхшыртыр иде.

ДӘВАМЫ БАР

## Бет базары нинди серләр саклый?

*Менә инде дистә еллардан бирле атнаның һәр якшәмбесендә, һава торышына, юллардагы вәзгыятькә һәм дөньякүләм проблемаларга карамастан, Тинчурин исемендәге скверда Бет базары (Блошиный рынок) гөрли.*

*Ниләр генә юк монда: антиквариаттан алып, кирәкмәгән вак–төяккә кадәр. Сатучылар, нигездә, урта яшьтән өлкәнрәк кешеләр, алары да ике төркемгә бүленә: профессиональ коллекционерлар һәм пенсиясен җиткерә алмаудан, өйдәге артык әйберләрен сатучылар.*

Башта беренчеләренә тукталыйк…

Бет базары дигәч, күз алдыгызга нәрсә килә? Әлбәттә, «искелек» исе кергән, һич кемгә кирәкмәгән киемнәр; саран, тупас сатучылар һәм һәр тиене өчен калтырап торган сатып алучылар. Ышандырып әйтә алам, сез беренче тапкыр Тинчурин скверына килсәгез, үзегезне хәерче базарында түгел, ә нәкъ музейда кебек хис итәчәксез.

Төрледән-төрле статуэткалар, ике гасыр буе сакланган тәңкәләр, зәвыклы алка-йөзекләр, патефон, винил пластинка, хәтта сугыш чорыннан калган каскалар... Сөйләшә торгач, шул аңлашылды: бирегә антиквариат кибетләре яратып йөри икән. Алар кайвакыт хәтта атна буе бармаган сатуларын бередә тутырып, атналык табыш ясап китәләр. Бу урыннардагы сатучылар да, алучы да – белгеч. Андагы сәүдә барышын күзәтеп тору үзе бер тамаша. Куллардагы лупа белән «товар» тәфсилләп карала, аннан сүз «экспонатның» тарихына күчә (тыңлап торсаң, үзеңне аукционда күк хис итәсең). Бу урынны һич хәерче базары димәссең))) Бәяләре хәтта 50 000 гә җитә!!!

Антиквариат сатучылар, әлбәттә, минем кебек дилетантларны яратмый, арада хәтта: «Сез миннән допрос аласыз мәллә», – дип сукыранучылар да табылды. Мондыйларның күзләре үткен, синең бу өлкәдә «чәйнек» булуыңны әллә кайдан танып алалар. «Бу әйбергә 60 ел, аңа тиергә ярамый», «алырга җыенмасагыз, кирәкмәгәнгә вакытымны әрәм итмәгез», «карамагыз!»– дип, ачулана башлыйлар, ә кайбер урыннардан бөтенләй үк куып җибәрделәр. Юк–юк бөтенесе дә усал түгел!) Мәсьәлән, бер абзый бик ачык кеше булып чыкты. Кечкенә чагыннан ук тәңкәләр җыя икән, вафат булыр алдыннан бабасы аңа үз коллекциясен калдырган. «Үткән атнада бер бик сирәк тәңкә сатып алдым, 25 000 гә төште. Кот Матроскин әйтмешли: «кирәкле берәр нәрсә алганчы, кирәкмәгән берәр әйберне сатарга кирәк». Әнә шулай тәңкәләр җыям, үземә кызык булганнарын коллекциямдә калдырам, ә калганнарын бүтәннәргә сатам». Ул Казанны гына түгел, хәтта Европа базарларын да аркылыга буйга йөреп чыккан кеше (Гамбург, Берлин, Хелсинки һ.б.)! Аның фикеренчә, Бет базары – һәр шәһәрнең истәлекле урыны саналырга хаклы! Үз гомеремдә бу базарга беренче мәртәбә генә килүем булса да килешәм!!!

Танышымның коллекциясе генә түгел, тормышы да кызыклы булып чыкты! 1990 елларда чит илдә «агент» булып эшләгән. «Иртүк торып, ларёкларны йөреп чыгып, бөтен булган гәҗитне җыя идем. Эшем –безнекеләргә кирәк мәгълүматны җыеп җибү.

Әмма берникадәр вакыттан, сизеп алып, мине кире Россиягә кайтардылар. Аннары Россиийдән, паспорттагы исемемне үзгәртеп, яңадан Европага җибәрделәр..» – дип сөйләде ул.

*Икенче төркем сатучыларны*

Аларны беренче килүдә генә күрмәскә, аларга игътибар итмәскә дә мөмкин, чөнки базар галәмәт зур, ә «товарлары» исәпсез күп һәм гаҗәеп кызыклы. Скверның үзәгендә урнашкан антиквариантлар рәтен үткәч, бераз читтәрәк гап–гади полиэтиленга тезелгән «чүп–чарлар» рәте башлана: кием, сумка, уенчыклар, кул эшләнмәләре, савыт–саба, кесә телефоннары өчен зарядкалар һәм совет чорының пластмас курчаклары. Кыскасы, монда хуҗаларына бүтән кирәк булмаган әйберләр үзләренә яңа яшәү урыны «эзли». Сатучылары да, алучылары да гап–гади пенсионерлар. Бәяләр дә көлке: 10–50 сум, бер сатучы апа әйтмешли «саткан табышы җимеш алып ашарлык булса бик әйбәт инде». Сөйләшә торгач, шул аңлашыла: монда аларны чарасызлык йөртә. «Мин гомерем буе укытучы булып эшләдем. Түләүләрдән соң, акча яшәргә дә калмый. 14 мең пенсия нәрсәгә җитсен? Акча җитсә, мин монда чыгар идемме, гомеремдә чыкмас идем!»

ДӘВАМЫ БАР

## Интернет–этикет: тавышлы язмалар (аудиосообщенияләр) – моветон әллә прогресс таләбеме?

*Без һәр көн, һәр сәгать, хәтта минут саен диярлек төрле мессенджерлар белән кулланабыз. Telegram, Instagram, WhatsApp, Вконтакте... Тормышыбызны социаль челтәрләрсез күз алдына китереп тә булмый инде. Күбесенчә, без әлеге платформаларны аралашу максатында кулланабыз. Кулланучыга тагын да уңайлы булсын өчен бу җайланмалар һәрдаим яңарып тора, шуңа күрә безнең арсеналда яңадан-яңа функцияләр барлыкка килә. Хәзерге вакытта иң популяр булганы – тавышлы язмалар, ягъни аудиосообщенияләр. Бу функция барлыкка килгәч, кешеләр ике лагерьга бүленде: аудисообщенияләрне бик уңайлы дип фикерләүчеләр һәм тавышлы язмаларны тәрбиясезлек күрсәткече дип санаучылар.*

Бүген тавышлы язмаларны җибәрү мөмкинлеге бөтен социаль челтәрләрдә дә бар диярлек. Facebook һәм WhatsApp мессендже-

рында ул 2013 елдан бирле эшли. 2014 елда — Telegramда (ә дүрт елдан соң тизләтелгән тыңлау өстәлә), 2016 елда — VK, ә үткән ел хәтта Instagramда да тавыш яздыру мөмкинлеге булдырылды. Әлеге функция бер мессенджердан икенчесенә күчеп йөри икән, димәк, ул күпләр өчен уңайлы һәм кирәк. Уйлап табучылар да аны отышлы дип саный: Facebook мәгълүмәтләре буенча, тавышлы язмалар популярлык дәрәҗәсе буенча икенче урында тора. Шуңа карамастан, аудиохәбәрләргә каршы килүчеләр дә бик күп: алар тавышлы язмаларны җибәрүчеләрне тәрбиясезлектә гаеплиләр, алардан көләләр һәм шул рәвешле күптөрле мемлар тудыралар.

Күптән түгел төрле яшьтә, социаль хәле һәм һөнәрләре төрле булган 150 кеше арасында сораштыру үткәрдек. «Сез аудиосообщенияләр еш җибәрәсезме?» дигән сорауга – 63% кеше «әйе» дип, 37% катнашучы «юк» дип җавап бирде. «Хәреф белән язып утырганчы, аудиосообщение җибәрү уңайлыракмы?» дигән сорауга – 16 % «юк» дип, 84 % – «әйе» дип җавап кайтарды. «Тавышлы язмалар алганда, сездә уңайсызлану хисе барлыкка киләме?» дигән соруга 33 % «әйе» дип җавап бирсә, ә 67% се «юк» ди. Нәтижә ясасак, кешеләр аудисообщениләрне еш файдалана һәм аларны традицион сообщениягә караганда уңайлырак дип саный, ләкин тавышлы язмаларны алганда уңайсызлык һәм дискомфорт хисе кичерүчеләр саны да шактый... Хәтта кайберүләр аудиохәбәрләр җибәрү шәхси чикләрне бозу дип саный.

«Текстлы хәбәрләр, гадәттәгечә, безнең платформа аша җибәрелгән сообщениләрнең төп өлешен тәшкил итә. Әмма тавышлы хәбәрләрнең саны да арта бара, бигрәк тә, соңгы ике елда, – ди, 2018 елда Viber мессенджерының генераль директоры Джамель Агауа. Дөрес, аудиоязма җибәрүчеләрне дә аңлап була. Тавышлы хәбәрләрне язу уңайлы һәм тиз: күпләр клавиатурада хәреф җыюга караганда тизрәк сөйли (кышкы салкында перчаткаларны бөтенләй кулдан саласы килми, бу очракта да аудиосообщенияләр ярдәмгә килә). Тавыш яздыру өчен, хәтта төп шөгыльдән дә аерылырга кирәкми, аны теләсә кайда, теләсә нинди эш белән параллель җибәреп була.

ДӘВАМЫ БАР

## Баш мие Тик-тогы

*Интернетта Tik Tok мобиль кушымтасы көннән–көн популярлаша бара. Берәүләр аңа инде күптән гашыйк булса, икенчеләрнең, киресенчә, бу социаль челтәр ачуларын кабарта, ә өченчеләр исә аны бөтенләй дә белми. Димәк, бүген без нәкъ менә шул турыда сөйләшербез.*

*Нәрсә соң ул Tik Tok?*

Тик–ток дип аталучы бу Кытай кушымтасы иң элек кыска видеоларны редакторлау өчен генә кулланылучы сервис булган. Дөньяга ул үзенә охшаш функцияле тагын бер кушымта – musical.ly белән берләштергәч «таныла». Хәзерге вакытта Tik Tok иң популяр сервисларның берсе, уйлап табучылар анда караоке һәм видеороликларны берләштергән. Бу кушымтадан бөтен дөнья буенча 500 миллионнан артык кеше файдалана. Төп аудиториясе – 19 яшькә кадәрге яшүсмерләр һәм яшьләр. Йөкләнешләр (загрузка) саны буенча бу социаль челтәр 2018 елда хәтта Facebook, Instagram кебек гигантларны да узып киткән.

*Ни өчен TikTok сервисы мондый популярлык казанды?*

Тик–Ток нәрсә икәнен аңладык, әмма ул ничек итеп яшьләр арасында популярлыкка иреште соң?

- Актив һәм хәтта агрессив реклама

Әлеге кушымтаның популярлыгы, беренче чиратта, реклама компаниясе белән бәйле. Актив реклама YouTube һәм Google Adwords кушымталарында барды (экранда, кино карар алдыннан кайсыгызның ачуын чыгарып, TikTok ролигы чыкканы бар?), шулай ук блогерлар аша да төрле киңәшләр бирелде (әлбәттә болары да, нигездә, чын киңәш түгел, ә түләнгән реклама).

- Үсмерләрнең тренд үзәгендә булырга омтылышы

Моннан тыш, ул тиз арада үзенә киң аудитория — тинейджерларны яулый алды. Яшьләр, әлбәттә, трендлардан калышырга теләми һәм перспективалы сервиста популярлык казанырга омтыла. Шулай ук TikTok яшьләргә үз аудиторияңне тиз табырга булыша, чөнки сервис яңа һәм аның колачы гаҗәеп киң. Әйтик, инстаграмда безнең сторисларыбызны 300 кеше караса, монда «караулар» һәм подписчиклар берничә меңгә җитә.

- «Сарафан» радиосы

Бу эштә сарафан радиосы тәэсире дә мөһим роль уйный. Күп кенә кулланучылар Тик–токта булдырган видеоязмаларын Instagramга кертә башладылар. Һәм, әлбәттә, бу эффектлы видеолар күпләрне җәлеп итеп, аларны да үзенә тартты.

Популярлыгына карамастан, ни өчен Тик ток бик күпләрнең ачуын чыгара?

Популяр булса да, бу социаль челтәр күп кешенең ачуын чыгара һәм алар «тик–токерларга» карата тискәре фикер йөртә. Кушымтага мондый тискәре мөнәсәбәт булуның сәбәбе аның популярлыгы белән бәйле, ягъни агрессив реклама. Әйе, программа турында рекламалар бик күп. Ул бөтен «тәрәзәдән» диярлек ишетелеп һәм күренеп тора. Аның интернеттан шулкадәр еш кабатлануы хәтта туйдыра башлады. Бу социаль челтәрне, нигездә, яшүсмерләр куллана дидек, ә өлкәнрәк буын бу шөгыльне камера алдында кылану дип кенә саный.

Яшьтәшләрем арасында үткәргән сораштыруда «Ни өчен сез TikTok ны кулланмыйсыз?» дигән сорауга 14 % : «Мин, TikTok ны кулланыр идем дә, ләкин бу «шөгыль» матур түгел, артык кылану кебек кабул ителергә мөмкин».

Әлеге социаль челтәрнең уңай һәм тискәри яклары:

+ (плюслар)

- үз креативлыгыңны күрсәтү өчен шәп платформа;
- төрледән–төрле музыка сайлау мөмкинлеге бар;
- Төрле эффектлар һәм фильтрлар куллану мөмкинлеге зур;
- Видеоны тизләтү һәм акрынайту мөмкинлеге;
- видео–социаль челтәрләргә, мәсьәлән, Instagramга урнаштыру мөмкинлеге;
- Яңа дуслар табу мөмкинлеге.

– (минуслар)

Күп вакытны «ашый»: кеше бу социаль челтәрдә берничә сәгать рәттән утырса, ул акырынлап гадәткә, хәтта «чир» гә әйләнергә мөмкин.

ДӘВАМЫ БАР

*2-нче урын*
***Айзилә Абдрахманова***

## БДИдән ничек «качарга»?

*БДИ... Бары өч хәреф, өч сүз инде. Ә үзе шундый куркыныч! Унбер ел буе алган белеме җитмәс дип, кайдан ничек күчерергә, ни рәвешле шпаргалкалар кулланырга белмичә интегә кайбер укучылар. Ә икенче берәүләр тагын да «яхшырак» юлларын таба... Ниндинеме? Хәзер сөйлим.*

Күптән түгел колагыма шундый сүз керде әле: имеш, шәһәрдә яшәүче 8-11нче сыйныф укучылары, БДИне яки ТДИне югары балларга бирер өчен, авылга кайта икән. Юк, сез дөрес аңлагыз, авылда яхшы укытканга түгел, ә булышырлар, күчерергә мөмкинлек булыр дип, өметләнеп кайта алар! Хәзер кемдер гаҗәпләнгәндер бу сүзләргә яки ышанып та бетмәгәндер. Мин исә, үз чиратымда, килешмәдем һәм әлеге фикернең дөресме–түгелме икәнен ачыкларга булдым.

Моның өчен Татарстанда һәм Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче берничә дистә кешене сораштырырга туры килде. Нәтиҗәдә, чыннан да, берничә кешенең шәһәрдән авылга кайтуы беленде. Тик сәбәпләр төрле...

*Ләйлә, Татарстан:* «Бу уку елында сыйныфыбызга яңа укучы кайтты – Раилә. 8 ел буе Казан мәктәбендә укыган кешенең кисәк кенә авыл мәктәбенә кайтуы бөтен кешедә зур кызыксыну уятты. Башка иң беренче килгән уй: йә мәктәптән куганнар, йә имтиханын бирә алмам дип курыккан. Бөтен авыл халкы шул рәвешле имеш–мимеш сөйләде. Ләкин Ләйләнең авылга кайтуына гаиләсендә килеп туган проблемалар сәбәпче булып чыкты».

*Рәмис, Татарстан:* «Бер сыйныфташыбыз шәһәрдән авыл мәктәбенә күченде. 9 ел буе бер гаилә кебек яшәгәч, аны җибәрү читен булды. Җитмәсә, сәбәбе дә сәер: авылда сөйгәне көтә икән.. Сәер инде..».

Сорауларга җавап бирергә ризалашса да, исемен күрсәтмәвемне үтенде бер танышым. Ярый соң, әйдәгез, яңа танышыбызны Миләүшә дип атыйк. Миләүшә – Казан кызы. Һәм ул авылга, чыннан да, имтихан бирү өчен кайта. Гаепләргә ашыкмагыз! 11 нче сыйныфта имтихан бирү өчен физика фәнен сайлый

Миләүшә. Тик шәһәр мәктәбендәге укытучысы үз фәнен тиешле дәрәҗәдә белеп бетерми икән (һәрхәлдә, Миләүшә шулай дип саный). Шуңа күрә, авылда көчле мөгаллим барлыгын белгәч, алар гаиләләре белән вакытлыча (!) авылга күченергә булалар.

*Дамир, Татарстан:* «Узган 2017–2018 нче уку елында Казанда укучы бер егет авылга кайтты. Белемнәре чамалы гына, имтиханны бирә алмавы көн кебек ачык иде. Ләкин, ни гаҗәп, уку елы азагында имтиханнарны уңышлы гына биреп чыкты. Шаккаткыч: ярты ел эчендә шундый күп «өйрәткәннәр» укытучыларыбыз – әле дә булса аптырыйбыз!»

Тагын бер кыз Мәскәүдә (!) укыган. Тик мәктәпләре иске булу сәбәпле, шәһәрләреннән 800 километр чамасы ераклыкта урнашкан авылга кайткан. Шунда яшәүче туганнары әлеге мәктәпне тәкъдим иткән икән. Ләкин бер сорау туа: Мәскәүдә шундый көчле укытучылар, гимназий–лицейлар була торып, нишләп нәкъ менә авыл мәктәбен сайлаган соң ул?! Мин аның белән элемтәгә кереп карадым, ләкин ул кыз җавап бирүдән баш тартты. Шулай итеп, имеш–мимешләрнең өлешчә дөреслеккә туры килүен аңладым.

Авыл мәктәбе директорлары бу хакта ни уйлый икән соң – алардан да сораштырырга булдым.

ДӘВАМЫ БАР

## Тынычлык, бары тик тынычлык...

*– Ә алар мине кабул итмәсәләр? Үзләре турында югары фикердә булсалар?.. Җавапны белеп тә, әйтергә курыксам? Нишләргә соң миңа?!...*

*Тирән итеп сулыш ал. Бер... ике... өч... Тынычлан. Хәзер барын да ачыклыйбыз.*

Кайбер укучыларга төрле сәбәпләр аркасында мәктәпне алыштырырга туры килә. Бу – һәр бала өчен зур стресс, проблема. Яңа мәктәпкә баручыларны «Мине үз компанияләренә алырлармы?», «Алар янында ала карга булмаммы?» кебек сораулар борчый. Әлеге шикләр расланмасын өчен нишләргә, шуны карыйк әле.

1) Уку башланганчы, сыйныфта дуслар тап.

Сыйныф исемлеген карап, андагы укучыларны социаль челтәрләрдән таба һәм алар белән аралаша аласың. Димәк, 1нче сентябрьгә синең дусларың була диган сүз.

2) Тышкы кыяфәт бик мөһим.

Беренче пунктны үтәмәгәнсең икән, зянлы түгел: барыбер кайчан да булса танышасыз. Исемеңне белгәнче үк, сыйныфташларың синең турында: «Теге яшел носкилы кыз инде», – диебрәк сөйләшергә мөмкин. Шуңа күрә нинди дер исемнәр, кушаматлар такмасыннар өчен, артык игътибар җәлеп итәрлек киенмә.

Әгәр дә башкалардан аерылып торган ягың бар икән, аны икенче «кимчелек» белән яшерә аласың. Мәсәлән, сезнең класстагы малайлар кара галстуктан гына йөри, ди. Ә син – бик озын буйлы малай, дип уйлыйк. Сине «колга», «багана» дип йөрткәнче, «кызыл күбәләкле» малай дисәләр, күңеллерәктер, мөгаен.

3) Үзеңне тыныч һәм ышанычлы тот.

Әгәр дә берәрсе сиңа бәйләнә икән, тыныч кына, елмаеп җавап бирергә була. Конфликт ярат учыларга синең реакцияң мөһим.

Башыңны иеп, җилкәләреңне салындырып йөрмә. Күбрәк аралаш, елмай, үзең булудан курыкма. Шул вакытта тирә–юньдәгеләр сиңа тартылыр.

4) Беренче чиратта, партадашың белән дуслаш.

Бу – оялчаннар өчен иң яхшысы. Башта мәктәпне күрсәтүен, ә аннары белмәгән теманы аңлатуын яки ручка биреп торуын сорый аласың. Кешеләргә башкалар өчен файдалы, кирәкле булуларын тою ошый. Димәк, нинди дер дәрәҗәдә аларны аптырату дуслашырга бер сәбәп булып чыга.

5) Ят өендә ятык (уңай) бул, яки Кунак булсаң, тыйнак бул!

Баштарак барын да яхшылап күзәт, нинди дер нәтиҗәләр ясарга ашыкма. Әгәр дә бөтен әйберне тәнкыйтьләп: «Бу нинди таш гасыры инде? Безнең мәктәптә яхшырак иде!», «Бу нинди чеби ризыгы тагын?! Мондый ашатуны беренче күрәм!» – диеп йөрсәң, тиз арада үзеңә дошманнар табачаксың. Иң яхшы очракта алар сиңа: «Бар, үзеңнең идеаль мәктәбеңә кайт», – диеп әйтәчәкләр. Шуңа күрә сыйныфта/мәктәптә яшәп килгән кагыйдәләргә игътибар ит, аларны үзгәртергә тырышма.

ДӘВАМЫ БАР

# 16 да окоп казырга

*1941 елның сентябре. Татарстанга куркыныч яный. 25нче октябрьдә, Казанны әйләндереп алу өчен, бөтен көчне бер «нокта»га туплау башлана. Бу план тарихка «Казан каймасы» дип кереп кала. Анда безнең әнкәй (әбиебез) – Әтнә районы Түбән Көек авылы кызы Абдрахманова Әминә Әхмәтгали кызы да катнаша. Окоп казырга җибәрелгәндә, аңа нибары 16 яшь була.*

*«Борындык дигән авыл буламыни..».*

1941 елның 6 нчы ноябрендә үзенең бертуганы Мәүлиха апа белән бергә әнкәй, арбалы атка утырып, юлга кузгалалар. Тик юллары озын булмый, Идел аркылы чыга алмыйлар: боз катмаган. 11нче ноябрьдә кабаттан юлга чыгалар. 13е көнне Кайбыч районы Борындык авылына килеп җитәләр. Төн кунарга да шушы авылда тукталалар. Борындык дигән авыл буламыни, дип көлгән идем шул кичтә. Кем уйлаган берничә елдан шунда килен булып төшәсемне?» – дип искә ала әнкәй ул көннәрне.

*«Йомычка булса да җыярсың..».*

«Казан каймасы»на килүчеләрне Буа районының Суыксу авылына урнаштыралар. Әнкәйнең окоп казырга яше тулмаган икән, шуңа кире кайтарып җибәрергә булалар. «Кайта белмим», – дип утырып елагач: «Ярый, йомычка булса да җыярсың», – дип калдыралар үзен.

Хатын–кызларны зур гына буш йортка урнаштыралар. Өйне салам ягып җылыталар. Йокы урыны – идән, аякта оек–чабата, баш астында салам тутырылган капчык, юрган урынына сырма. «12 кеше бергә йоклагач, ул кадәр туңдырмый иде. Өйдә мичтән кала бернәрсә дә юк. Кичен, окоп казып кайткач, ашарга пеширәбез. Һәр көнне 500 грамм ипи бирәләр. Башта ашарга туган авыллардан алып килеп йөрдек, аннары һәр ай саен колхоздан китереп тордылар. Ач тормадык, Аллаһка шөкер», – дип сөйли әнкәй.

«Иртән торгач, төнлә ятып йоклаган саламны мичкә яга идек. Берсендә, бик салкын көнне, окоп казудан иртәрәк бушадык та, мичкә салам ягып, йокларга яттык. Солы саламы яга идек, ул озак яна бит. Без йоклап киткәнбез, ә мичнең аскы өлешенә солы төшеп утырган да ис чыккан, без исергәнбез. Күршедә торучы бер кыз, кибеткә барасызмы, дип кермәгән булса, шәт үлеп тә беткән булыр идек», – дип искә ала ул.

Бераздан окоп казучыларны Чувашиянең Козловка авылына күчерәләр. Аннары Тәтеш районының Тыншерма авылы янында окоп казыйлар алар. Февральнең 15ләренә кадәр, ягъни кайтырга приказ булганчы, шунда эшлиләр. «Башта яр буен шартлаталар. Без шул шартлаган урынны әйбәтләп казыйбыз. Окопның зурлыгы мунча бурасы хәтле. Ирләр (60тан узган картлар яки сугышка китәргә яше җитмәгән егетләр) бура бурыйлар да шул чокырга урнаштыралар. Без, буралар күренмәсен дип, балчык белән күмеп чыгабыз. Окопның бер башы сөзәк, икенчесе текә була», – дип сөйли әнкәй.

ДӘВАМЫ БАР

## Гадилектә – галилек!

*Президент, Дәүләт Советы рәисе һәм башка җитәкчеләребез ничек яши, кайда эшли? Бу турыда уйлап карамаган, кызыксынмаган кеше бармы икән?! Алар хакында күбрәк белүдән, кулларын кысудан, күзгә–күз карап сөйләшеп утырудан кем генә баш тартсын икән?!Мин дә бухыял белән янып яши идем. Һәм, ниһять, хыялым чынга ашты!*

19 нчы апрельдә «Ялкын» журналы редакциясе, үзе белән хезмәттәшлек итүче иң актив яшь дусларын җыеп, Дәүләт Советына Фәрит Мөхәммәтшин (!) белән очрашуга алып барды. Иң куанычлысы: анда мин дә бар идем!

Башта без, Татарстанның төрле төбәкләреннән килгән балалар, Татмедиа бинасына җыелдык. Аннары Дәүләт Советына киттек. Анда, иң беренче эш итеп, безгә бина буенча экскурсия оештырдылар. Депутатларның ничек эшләве, нинди бүлмәләрдә утырулары турында сөйләделәр һәм күрсәттеләр. ДәүләтСоветының үз китапханәсе һәм музее да бар икән, шундада булдык. Анда нәрсәләр генә юк: портретлар, Николай I заманыннан калган документлар, тәңкәләр, тарихи экспонатлар, статуэткалар... Дәүләт Советы рәисе җыелышларүткәрә торган конференцзалларга да кергәч, үзебезне депутатлар урынында хис иттек. Иң кызыгы: аларга , очрашу вакытында язып бару өчен, блокнот һәм карандаш бирелә икән. «Ә нигә ручка түгел?» дигән сорауга экскурсовод: « Карандаш язуөчен дә уңайлы һәм арзангарак та төшә», – дип җавап бирде.

Экскурсиядән соң безне махсус әзерләнгән залга алып керделәр. АндаП хәрефе рәвешендәге өстәлләрдә һәр кешенең кая утырырга тиешлеген күрсәтүче язулар тора иде.Һәркатнашучының алдына «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы» диеп язылган блокнот һәм ручка, чынаяк белән чәй, хөрмә-җимешләр, печенье-конфетлар куелган. Тиешле урыннаргаутырдык. Күп тә үтмәде, Дәүләт Советы җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин килепкерде. Без аныбасып каршы алдык. Очрашканчы, башыманинди генәуйлар килмәгән иде: шундый дәрәҗәле кеше безнең белән сөйләшеп тә тормас инде, диеп борчылган идем , ә ул гап-гади кеше икән! Һәрберебезнеңсоравын игътибар белән тыңлап, тулы җаваплар бирде Фәрит Хәйруллович. Без ике сәгать эчендә аның бөтен тормышы турында белеп калырга тырыштык: Фәрит Мөхәммәтшинның балачагы, мәктәп еллары, дуслары турында, ничек ял итүе, нәрсә белән кызыксынуы, гаиләсе белән тәүлекнең ничек сәгатен үткәрүе, ашарга пешерә беләме икәнлеге турында сораулар яудырдык. Минем дә күптән күңелемне кытыклап торган соравым бар иде:

**– Фәрит Хәйруллович, Сезнеңкебек уңышка ирешү өчен, эшне нәрсәдән башларга кирәк?** – дидем мин.

Ул исә:

– Моңа бер генә җөмлә белән җавап биреп булмый. Беренче чиратта, син, укучы буларак, мәктәптә бик яхшы укырга тиешсең. Әти–әниеңнең тәрбиясендә үсәргә, начар компанияләргә иярмәскә, дөрес даирә сайлый белергә кирәк. Үзеңнең кызыксынуларың, алга таба китәргә җыенган юнәлешең булырга тиеш... – диде.

Мин бу очрашудан Ф.Мөхәммәтшин турында башкалардан ишетмәгән өч факт белеп кайттым һәм үзем өчен кайбер нәтиҗәләр дә ясадым:

*1нче факт:* Безнең Дәүләт Советы җитәкчесенең, мәктәптә укыганда, начар билге дә алганы булган икән. Ләкин бу аңа зур кеше булырга һич кенә дә комачауламаган!

Димәк, начар билге алдым дип, беркайчан да төшенкелеккә бирелергә ярамый икән!

*2нче факт:* Фәрит Хәйруллович рус авылында туып үскән, русча укыган, дуслары белән дә русча гына сөйләшкән. Алар авылда бердәнбер (!) татар гаиләсе булган. Ләкин шуңа карамастан, хәзер ул менә дигән итеп татарча сөйләшә!

Димәк, теләгең булса, бөтен нәрсәгә дә өйрәнергә мөмкин икән!

*Знче факт:* Очрашуга барыр алдыннан куркуларыбыз юкка гына булган, чөнки Фәрит абый – үзебезнең әтиләребез, дәү әтиләребез кебек гап–гади һәм бик ягымлы, әйбәт кеше икән!

Димәк, бөеклек гадилектә икән!

*2-нче урын*
***Илүзә Нәгыймова***

## Язны мин ни өчен яратам?

*Белмим, нәрсәдәндер, әмма «яз» сүзен ишетүгә, минем күзләрем ялтырап китә. Әйтерсең, аларда язгы кояш чагыла.*

Бу чыннан да шулай, чөнки язгы кояшның никадәр якты булганын минем күзләрем яхшы сизә. Җәйнең иң ямьле һәм эссе көннәрендә дә кояш шулкадәр якты булмыйдыр. «Менә–менә эреп бетәм»–дип торган, энҗе кебек ялтыраган карны кочакларга ашыгып төшкән кояш нурлары күзне хәтта яшьләндереп тә ала.

Яз ул чын музыкант та бит әле. Яз оркестрының дирижеры – нәкъ шул ук кояштыр. Дирижерның елмаюы күрендеме, гөрләвекләр үз җырларын башкара башлыйлар. Кояш җылы карашын түбәләргә эленеп куелган боз сөңгеләренә таба юнәлттеме, тамчылар тып-тып килеп биешә, сикерешәләр. Чын әйтәм, җырлый белгән булсам, шул яз ансамбленә кушылыр идем. Әмма табигатьнең үз җырчылары бар бит инде. Бар дөньяга үзләренең матур җырларын сузып, җылы яклардан кошлар кайта. Озак көтәсе түгел, шул көй белән хисләнеп, җылы җил астында иркәләнгән агачтагы яшь бөреләр дә уяныр, алар бар тирә-юньгә хуш ис таратып, яфрак ярыр. Әле бит җырчылардан кошлар гына түгел, әнә, үзләренең тырышлыгы белән дә, дәртле җырлары белән дә танылган бал кортлары «быз–быз» килеп эшкә тотына. Язның скрипачлары-чикерткәләр үз көйләрен суза. Башка бөҗәкләр дә алардан калышмый, бөтен тирә-юньне тутырып шаулаша башлыйлар. Өр-яңа күлмәкләре белән мактанырга ашыккан яз биючеләре – күбәләкләр дә көннән–көн ешрак күренә башлыйлар. Бар урамны яңгыратып балалар көлүе ишетелә. Алар суларга сикереп шаяралар, ә аларның әниләре әллә аларны орыша, әллә бала чакларын искә төшереп көлешәләр. Басуларда да тиздән тракторлар гөрелтесе ишетелә башлар, кешеләр язгы эшләргә керешерләр. Гомумән, һәр мизгел бик күп матур тавышлар белән тулы, алар, барысы бергә кушылып, матур яз музыкасына әйләнәләр.Тыңлап торсаң, Шопен яки Моцарт концертына эләккәнсең кебек. Искиткеч!

Минем фикеремчә, яз – Җирдә яшәүче барлык җан ияләренең әнисе. Аннан башка кешеләр яңа тормышның нәрсә икәнен һәм аның ни дәрәҗәдә матур күренеш булуын аңлый алмас иде. Нәкъ менә ул кыш буе татлы йокыда булган табигатьне уята, тып-тын торган дөньяны шау-гөр китерә. Тормыш өр-яңадан, чип-чиста бер биттән башланган кебек була.

Мин язны яратам! Яратмаска мөмкинме инде шул матур, дәртле, тылсымлы ел фасылын?! Яз көне мине романтик рух җанландыра. Мин иҗатка игътибар бирәм, шигырьләр һәм зур булмаган хикәяләр язам. Бу вакытта кешеләр, мөгаен, үз музаларын таба алалар, илһамланалар.

Әйдә, озак көттермә, түрдән уз, яз!

## Минем гаиләм һәм сугыш

*Безнең илдә миллионлаган совет кешеләренең гомерен өзгән Бөек Ватан сугышы геройларын искә алмаган бер генә гаилә дә юк. Бу сугыш һәр гаилә тарихында төзәлмәс эз калдырды һәм күп кенә гади кешеләрне соклануга лаек булган чын каһарманнар итте. Безнең милләт сугышчыларның үлемсез батырлыгын хәтерли һәм шул авыр вакытта яшәгән әби-бабайларын, әти-әниләрен һәм туганнарын аерым бер дулкынлану һәм мәхәббәт белән искә ала.*

Фронт һәм тыл геройларының батырлыклары онытылмаслык, аларның даны мәңгелек! Кешеләр 4 елдан артык, үз гомерләрен көн саен куркыныч астына куеп, Җиңүне якынайту өчен, үлемгә фидакарьләрчә барганнар. Туган җиргә, Ватанга мәхәббәт, батырлык, тугрылык – минем карашка, сугыш геройларына хас төп сыйфатлар. Һәм мин горурланып әйтә алам: безнең илебезнең, авылыбызның, гаиләбезнең һәр кешесенә дә бу сыйфатлар хас булган. Алар көрәшнең гомуми мәгънәсен дә, ил язмышы өчен шәхси җаваплылыкларын да тирән аңлаганнар.

Сугышның беренче көннәреннән үк бер безнең Исәнбай авылыннан гына да 350гә якын кеше «Бер кайтмасак, бер кайтырбыз»,–дип фронтка киткән, калганнар тылда хезмәт иткән. Алар барысы да безнең илебезнең горурланып сөйләрлек, курку белмәс, җиңелмәс батыр уллары һәм кызлары, шундый батыр йөрәкле балалар үстергән бөек аналар, аталар.

Сугышта югалтулар кичермәгән һәм өметләрен өзмәгән гаилә юктыр дип уйлыйм. Безнең гаиләдән Ягъфаров Газиз Латыйп

улы, Ягъфаров Нурмөхәммәт Латыйп улы, Ризванов Хәбибрахман Шәрәфетдин улы, Ризванова Фәүзия Хәбибрахман кызы, Корбагалина Фәридә Хәфиз кызы һ.б., башкалар бәхетен үзләренекеннән өстен куеп, Туган илләрен саклар өчен, фронтка киткәннәр.

Ә без үзебез сугыш турында нәрсә беләбез? Пуля сызгыруларын ишетмәгән, бомбалар өзелүен күрмәгән, ачлык, ятимлектә үсмәгән кешеләр буларак, без сугышның нәрсә икәнен аңлыйбызмы? Бу сорауга аның аша үткән кеше генә җавап бирә ала.

Мин тыныч вакытта тудым һәм сугыш дәһшәтен күрмәдем, әмма аның нинди коточкыч нәрсәикәненкитаплардан укып, кинолардан күреп, укытучы апалар сөйләгәненннән беләм. Ләкин миңа иң тәэсир иткәне – әбием Фәүзия сөйләгәннәре. Мин әбиемне бик ярата идем һәм аның белән дөньяда булган барлык әйбер турында да сөйләшергә риза идем. Әмма аннан нәкъ менә сугыш турында сораштыру минем өчен авыр булды, чөнки ул күңеле белән шул куркыныч көннәргә кайта иде. Хәзер мин бу хакта сорашып тормавыма бик үкенәм. Миңа бер аклау бар: мин әбиемнең хәтерендә ул коточкыч елларны торгызырга теләми идем. Әмма аның бу хакта сөйләгән һәрбер сүзен хәтерлим, әйтерсең, ул миңа барысын да бүген генә сөйләп бирде.

Сугыш башланыр алдыннан ук әбиемнең әнисе үлә, шул сәбәпле алар үги ана белән үсәләр. Әтисенең фронтка китүен ул хәтта аңламый да кала: «Әткәй белән печәнгә барган идек, кайтканда, артык арыганлыктан, йокыга талганмын. Иртән торуыма әти инде өйдә юк иде», – дип сүзен башлап җибәрә иде ул. «Ул вакытта өйдә әле үги әни бар иде. Озакламый «Бу балалар, үскәч, мине карамаслар», – дип үги әни дә китте». Шулай итеп, кечкенә сеңлесе, ике абыйсы белән әбием өйдә ятим калалар. Шуны әйтәсем килә, сугыш чорында иң зур абыйсына 14, үзенә 8 яшь, иң кечкенә сеңлесе нибары бер яшьлек кенә булган! Сугыш китереп чыгарган хәсрәт– михнәтләрне, ачлык–ялангачлыкны, ятимлекне үз җилкәләрендә татыганнар алар. «Салкын, киярдәй киемебез юк, хәтта аш пешерергә казаныбыз да булмады, аны да мичтән кубарып алып киттеләр. Ике абыем, безне ач булмасын дип, ат җигеп колхозда эшләделәр. Өй эшләре минем өстә иде. Ярый әле, якында гына, туган кешеләр яшәде, булдырган кадәр ярдәм иттеләр». Әбием аларга гомере буе бик рәхмәтле булды, догасыннан калдырмады.

ДӘВАМЫ БАР

## Авылым атамалары

*Саф һава, сокланып туймаслык тугайлар, шаулап торган урманнар, хуш исле, аллы-гөлле чәчәкләр, челтерәп ага торган, салкынча сулы чишмә, кошлар җырлавы, ягымлы, ярдәмчел,киң күңелле кешеләр – болар барысы да минем авылым! Исәнбаем, күңелемә шул чаклы якынсың, кадерлесең һәм изгесең син!*

Безнең илебез искиткеч зур. Анда беренчесе икенчесеннән зуррак шәһәрләр, берсе икенчесеннән гүзәлрәк авыллар бихисап. Әмма шуларның берсе дә минем туган авылыма тиң түгел. Әйе, ул кечкенә генә, карталарда да аның исеме сирәк очрый, әмма аның иксез-чиксез басулары, куе урманнары, еракка сузылып аккан елгалары, кешеләре – шул кечкенә генә җиргә сыймый торган зур бер байлык. Исәнбай бу дөньда берәү генә, аның бернинди дубликаты да юк, кайда гына эзләсәң дә, минем туган авылымның матурлыгын берни дә алыштыра алмый.

Әлбәттә, һәр авылның үз тарихы булган кебек, безнең авылының да үзенчәлекле тарихы бар. Исәнбай авылына нигезнең 17 гасырның беренче яртысында, патша Михаил Федорович Романовның җирләрендә салынуы билгеле. Географик урынына килгәндә, ул Әгерҗедән 90 чакрым ераклыкта урнашкан. Исәнбай авылын бер ягыннан Биме, икенче ягыннан Кадыбаш авылы уратып алган. Риваятьләргә куз салсак, авылның беренче исеме Яланоч булган. Бу исем «Ялан очы» дигән сүзләрдән барлыкка килгән. Ә менә авылымның хәзерге исеменең килеп чыгышы тагын да кызыклырак. Авылга исемне үзенең туганнары белән беренче булып килеп урнашкан Исәнбай исемле кеше хөрмәтенә кушканнар.

Һәр авылның үзенә генә хас, кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Атамалар, минемчә, аеруча игътибарга лаек, чөнки алар тамырлары белән үткәннәргә барып тоташа. Димәк, алар авыл тарихы белән тыгыз бәйле. Мәсәлән, үзенең эре, кып-кызыл җиләкләре белән дан тотучы Яман чокыр. Габдулла Тукай язган бит әле: «Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк»– дип, менә безнең Яман чокырда да җиләк искиткеч күп! Җәен бар авыл халкы шунда инде. Кечкенә чагымда шакката идем, исеме шундый куркыныч, ә чынлыкта исә, бик күңелле урын. Башыма дөрес уй килде, әбиемнән бу урынның тарихын сорарга булдым. «Нигә хуш исле чәчәкләр тулы чокырга «Яман» исемен биргәннәр?» – дип сорагач, ул бераз көлеп тә алды. «Мин кечкенә

булганда, әти белән шунда печәнгә бара идек. Ул вакытта анда озын бер елга хөкемлек итә иде. Яман сүзе шул елгадан чыкты. Һей, боргалана–боргалана, көчле агым белән ага иде,әйтерсең, ташны да ватып чыгар. Бер дә якын килгәнем булмады, аны гел читләтеп йөрдем, чөнки су астыннан йә Су анасы, йә Дию чыгар да, мине алып китәр дип курка идем. Ул елга күптән кипте инде, хәзер яманлыгыннан шул чокыр гына калды». Менә бит, тарихы никадәр кызыклы булып чыкты!

Җәебезне шул чокырда үткәрсәк, кышын безне, киресенчә, тау көтә иде. Гади генә дә түгел, ә Вилен тавы. Авылыбызның кайсы гына баласыннан сорасаң да, алар фикеренчә, шәһәрдә махсус ясалган таулырның барысын да уздыра ала ул. Шуңа күрә, каникулга кайткан бөтен иптәшләрне җыеп, шау–гөр китерәбез без аны. Сиңа сигезме, сиксән сигезме–мөһим түгел. Олысы да, кечесе дә үз чиратын көтеп, тауны гизә. Вилен тавы тагын бер ягы белән кызыктыра. Аның итәгеннән безнең Бимe елгасы үтә. Чанаңа утырып, шул елагага кадәр шуып төшәлсәң, мәңгелек дан һәм хөрмәт сиңа! Тау исеменең килеп чыгышы Яман чокыр тарихы кебек үк серле түгел. Кайчандыр ул Вилен исемле кешенең бакчасы булган. Шуннан чыгып, бу урынга Вилен тавы дигәннәр.

ДӘВАМЫ БАР

*2-нче урын*
***Рүзәл Шәрипов***

## Кулга автомат кына тоттырсыннар!

«Ватанга тугры калырга, яшь армиячеләр антына тап төшермәскә, намуслы һәм гадел булырга, ярдәмгә мохтаҗларны якларга, укуда һәм спортта уңышларга ирешергә!» – бу Юнармия хәрәкәте активисты Гөлфинәнең тормыш шигаре. «Бу кем икән?» – дип уйлап куйдыңмы? Хәзер барысын да аңларсың!

**– Гөлфинә, Юнармия хәрәкәтенә син ничек килеп эләктең?**

– Мин кечкенәдәнтуган илен данлаган кешеләр белән кызыксындым. Аларның башкарган эшләрен, кылган гамәлләрен күзәтергә яраттым. Үз тормышымны да хәрби хезмәт белән бәйлисем килде. Хыялымны чынга ашырыр көн дә җитте. 2016 елның көзендә мин яшь армиячеләр рәтенә кердем. Бик тиздән юнармиячеләрнең иң алдынгылары рәтенә бастым дисәм дә, ялгыш булмас. Әлеге иҗтимагый хәрәкәттәге эшчәнлегем өчен орден белән бүләкләндем.

**– Әлеге орденны алырга теләүчеләргә киңәшләрең?**

– Минемчә, эшчән, акыллы, ярдәмчел, тырыш булган һәр яшь армияче бу бүләккә лаек була ала. Әлбәттә, укудагы уңышлар, физик яктан нык булу да зур йогынты ясый. Актив булырга кирәк, шул чакта гына сине күреп алачаклар.Әле орден алгач, ТНВ каналының«Башваткыч» тапшыруында катнашу бәхете дә елмайды. Бер–ике ел элек күрәзәчеләр киләчәкне юраган булсалар, мин аларның әйткәннәренә ышанмаган да булыр идем. Бу җиңүләрем соңгысы булмасын!

**– Орден алганнан соң, уңышлардан баш әйләнү булмадымы?**

– Юк бугай (көлә). Өйгә кайтып сөйләгәч,бермәлгә сүзсез калдылар да: «Булдыргансың, кызым, тик борыныңны бик күтәрмә яме, дусларың яратмас!» – дип «җиргә төшерделәр».Менә шулай итәктән тартып торгач, баш әйләнми икән. Йөрәк җылымны биреп эшләгәнемне күреп торган укытучыларым, дусларым чын күңелдән котлады. Сыйныфташлар белән бер зур гаилә кебек без, шуңа да җиңүемә иң күп куанганы алар булды кебек.

**– Хәрби әзерлек буенча дәресләрдә сине нәрсәгә өйрәттеләр?**

– Бу сорауга мин сәгатьләр буе сөйли алам. Иң мөһиме: туган илне яратырга, өлкәннәргә, нәни дусларыбызга карата дустанә мөнәсәбәттә булырга, иң авыр физик күнегүләрне дөрес итеп ясарга өйрәндем. Хәзер командабыз белән беренче медицина ярдәме күрсәтә, автоматны сүтеп җыя, бердәм команда булып стройда йөри беләбез. Күптәннән автоматтан атарга өйрәнәсе килә иде. Яшь армиячеләр хәрәкәте миңа шушы хыялымны чынга ашырырга ярдәм итте. Башта гына куллар да калтырады, мишеньга эләгә алмыйча җәфа чигеп, җиргә дә аткалаган чаклар булды. Ә хәзер исә... кулга автомат кына тоттырсыннар! Баш өстендәге алмага да эләктерә алам! Боларның барысына да без хәрби әзерлек буенча дәресләр үткәрүче укытучыбыз Илдус Әскәров ярдәме белән ирештек.

**– Автоматтан ату – кызлар эше түгел бит?!**

– Минем дә шулай уйлаганым булды. Сугышырга өйрәнгән чакта, бу кызлар эше түгел бит, дигән уй баштан чыкмады. Ләкин төркемебездә бердәнбер кыз булганга, үз–үзеңә ышану, тәвәкәллек арта. Бу миңа ярты юлда туктап калмаска, алга таба атларга этәргеч биреп тора.

**– Әллә армиягә дә барыр идеңме?**

– Әйе! Кечкенә чакта «Солдат булам, армиягә барам», – дип йөри идем. Тик үсә төшкәч, бу фикерем үзгәрде, бер дә пеләш каласы килми икән...

**– Яшь армияче булыр өчен, нинди сыйфатларга ия булырга кирәк?**

– Әлбәттә, туган илен яратырга, чын ватанпәрвәр булырга тиеш.Кешелеклелек сыйфатлары да зур әһәмияткә иядер, миңа калса. Туган җиреңне саклау дигәндә, аңа турыдан-туры илне саклау гына түгел, ә анда яшәүче халыкны яклау да керә.

**– Аннан башка тагын нинди иҗимагый файдалы эшләр белән шөгыльләнәсең?**

– Мин – «XXI гасыр волонтерлары»оешмасы вәкиле. Оешмадагылар белән бергә, балалар бакчаларына, картлар йортына, тернәкләндерү үзәкләренә барып, концертлар куябыз, төрле кызыклы акцияләрдә актив катнашып, кулыбыздан килгән кадәр ярдәм итәбез.

**– Үзең өчен буш вакытың каламы соң синең, Гөлфинә?**

– Буш вакытым күп түгел, юк дисәм дә була. Төрле фән олимпиадалары, БДИга әзерлек – барысы да мине көтә. Ә менә җәй көне футбол уйнарга яратам. Әйе, әйе, футбол! Яратып җан аткан командам да бар – Реал Мадрид. Кечкенә чакта шаяра-шаяра туп тибеп уйнаган уеным хәзер көндәлек шөгылемә әйләнде. Өемдә китаплар коллекциясе бар, бәйлим, чигәм. Тарих белән кызыксынам, китаплар укыйм, шигырьләр язам, җырларга-биергә дә яратам. Кеше үзендәге мөмкинлекләрне файдаланырга тиеш дип саныйм. Шуңа күрә үземне төрле яктан сынарга тырышам.

**– Барысына да ничек өлгерәсең? Уңышка ирешү серең беләнуртаклаш әле.**

– Көн тәртибеңне тиешенчә оештыра белсәң, уңыш синең кулда дигән сүз. Ә уңышны тоткансың икән, берүк, ычкындыра күрмә! Инстаграм, ВКонтактеда утырып, вакытыңны әрәм итмә. Интернет челтәрендә «эленеп» калырсың тагын! Көндәлек ясап, шунда һәрбер эшлисе эшеңне теркәп барырга тәкъдим итәм. Әмма эш белән артык мавыгырга да ярамый. Укыганда физик күнегүләр ясаштыргаларга кирәк. Ялыңны файдалы итеп уздырырга кирәген дә исеңнән чыгара күрмә.

**– Гөлфинә, иң зур хыялың нинди?**

– Имтиханнарымны уңышлы тапшырып, югары белем алып, киләчәктә Эчке эшләр министрлыгында эшлисем килә. Аның өчен мин бик күп тырышам, көч түгәм. Шуңа күрә дә әлеге хыялымның, һичшиксез, чынга ашуына ышанам.

Илебезнең киләчәге Гөлфинә кебек кыю яшьләр кулында! Аның үз антына тугры калачагына, барлык авырлыкларны җиңәргә үзендә көч табачагына сез дә инангансыздыр!

## Өстә – кофта, ә аякта – итек! Нишләргә?

*Күз алдыңа китер, син – сәхнә артында. Алып баручы көтмәгәндә синең исемеңне әйтә. Син каушысың. Беренчедән, чыгышың шулай тиз килеп җитәр дип көтмәгән идең, икенчедән, әлеге чыгыш синең киләчәгеңне хәл итә. Куркуыңны җиңеп сәхнәгә таба атлыйсың... Тукта-а-а! Синең бит өстеңдә – кофта, ә аягыңда – итек! Нишләргә?*

Ә Зәринә Никитина бу кыен хәлдән чыгу юлын тиз тапкан! Ничек икәнен беләсең киләме? Алайса әлеге мәкалә синең өчен!

Зәринә – Арчаның гаҗәеп матур, көчле тавышлы сандугачларының берседер, мөгаен. Аның район, республика, халыкара бәйгеләрдә яулаган җиңүләрен санап бетергесез. Шулай да берничәсен генә әйтеп китәм әле: Халыкара «Җырлы–моңлы балачак» телевизион конкурсы лауреаты, Республиканың Рөстәм Яхин исемендәге «Күңелемдә яз» һәм халыкара «Тере чишмә» конкурс–фестивальләрендә II дәрәҗәдәге лауреат булган Зәринә!

**– Зәринә, җыр сәнгате белән кызыксынуың кайчан башланды? Әлеге юлга сине кем этәрде?**

– Мин инде балачактан ук җыр–моңга гышыйк кеше. Әни, минем гел җырлап йөргәнемне күреп, җыр мәктәбенә йөртә башлады. Баштарак бик ярата идем, тик соңыннан фортепианода уйнау дәресләре туйдыра башлады. Көннәрдән бер көнне ноталар дәфтәремне мәктәптә яшердем дә, өйгә кайтып: «Әни, урлаганнар! Җыр дәресе буенча барлык китапларымны урлаганнар! Хәзер вокалга йөри дә алмам инде», – дидем. Әни барысын да аңлаган, күрәсең: җитди рәвештә генә ризалашты да, кычкырып көлеп җибәрде...

**– Ләкин музыкаль белем алмыйчада булмый бит?**

– Әйе, килешәм. 2012 нче елда Арчага күченеп килдек. Монда минянәдән җыр белән дуслашып карарга булдым һәм вокал түгәрәгенә язылдым. Түгәрәк җитәкчесе Алсу Мәҗит кызы, чыннан да, үз эшенең остасы булып чыкты. Аның янәшәсендә мин үземне уңайлы хис иттем, төпле фикерләрен ярты сүздән үк аңларга ияләштем. Шуңа күрә бик аз вакыт эчендә минем тавышыма туры килерлек шактый күп җырлар өйрәнергә өлгердек. Ә соңыннан мин ачык, сөйкемле, көләч йөзле Гөлнара Бариевна белән шөгыльләнә башладым. Аның белән без, әкренләп авыррак җырларга күчеп, төрле бәйгеләрдә катнаша башладык. Җиңүләр дә озак көттермәде, соңыннан илһамны да мин ирешелгән уңышлардан ала башладым.

**– Барысын да ярты юлда ташлап калдырасың килгән чаклар булгалыймы?**

– Әлбәттә, күз яшьләре дә, үпкәләүләр дә, рәнҗешләр дә – барысы да була. Әмма тешләреңне кысып түзәргә, алга таба атларга кирәк. Мине кечкенә чактан ук җырчы Гүзәл Уразовага охшаталар. Бер концертында аның белән бергә җырларга теләгәнемне белдергән идем, ул шундук минем өчен микрофон алып чыгып бирде һәм, җырлап бетергәч, колагыма: «Зәринәм, фәрештәм минем, җырлавыңнан туктама! Барысы да әйбәт булыр!» – дип,

бүләк тапшырды. Авыр чакларда әлеге сүзләрне исемә төшерәм. Алар миңа иҗат итәргә көч, дәрт, ә иң мөһиме – рухи байлык биреп тора.

**– Синең кебек зур уңышка ирешер өчен нишләргә кирәк?**

– Беренчедән, үзең өстендә, хаталарың өстендә һәрдаим эшләргә кирәк. Һәр чыгышымны видеога төшерергә кушам. Бары тик үзеңне – үзеңкүреп кенә, хаталарыңны төзәтергә мөмкин, миңа калса. Икенчедән, син һәрвакыт остазың белән бер дулкында булырга тиеш. Аны бер караштан аңлап, ул куйган таләпләргә яраша белергә кирәк. Өченчедән, үзеңә ышан, сәхнәдән курыкма! Бик тиздән бу курку үзеннән үзе юкка чыгачак. Әлеге гади кагыйдәләрне гел исеңдә тотсаң, уңыш синең кулыңан төшәргә дә теләмәс!

Зәринә бүгенге көн белән генә яшәми, гел алга омтыла. Киләчәккә планнары да зурдан – җырчы булу! Хыялларың тормышка ашсын, Зәринә!

**P.S.** Теге кызык хәлнең ахыры турында сөйләргә онытып торам бит әле! Зәринә ул вакытта югалып калмаган. Янәшәсендә торган чит кызның туфлилиләрен сорап торган да матур күлмәк өстеннән кигән калынкофтасын салып ташлап, сәхнәгә чыккан. «Калтырап торганымны жюри әгъзаләре сизмәгән ахрысы! Беренче урын биреп кайтардылар бит!» – дип шаяртa үзе.

## Тирән сулыш алдык та… киттек!

*Адреналин, тизлек, релаксация һәм җиңелчә генә курку хисе сизелә, ә чәчләрең җилдәй оча… Юк ла инде, фен белән чәч киптерү турында сөйли, дип уйлый күрмәгез! Сүзем яшьләр арасында шактый популяр булган экстрималь спорт төрләре хакында. Араларында син моңарчы ишетмәгәннәре дә бардыр әле. Шуңа күрә курыкынычсызлык каешыңны тизрәк эләктер дә… китәбез!*

*Паркур*

«Чикләр юк – каршылыклар гына бар» девизы астында шөгыльләнүче спортсменнар паркурны аерым бер сәнгать төренә кертеп, яшәү рәвешенә әйләндерәләр. Бүгенге көндә ул күпчелек илләрдә киң таралган спорт төре булып санала, хәтта аны популярлаштыру максатыннан махсус парклар, уен зоналары да төзелә. Чөнки паркурның асылы – баскыч, дивар һәм шулай

ук башка махсус ясалган конструкцияләр кебек каршылыкларны җиңеп чыгу.

Паркур белән шөгыльләнүчеләрне трейсерлар дип атыйлар. Күп еллар дәверендә алар һәр хәрәкәтне төгәл башкарырга ияләнгән инде, тик яңа гына эшкә керешергә телисең икән, яра, җәрәхәтләргә дә әзер булырга кирәк. Авырлыкларга карамыйча, куйган максатларыңа ирешү теләге дә әлеге эштә бик зур роль уйный, шуңа күрә дә үзеңә һәм үз көчләреңә һәрвакыт ышану мөһим.

Паркур белән шөгыльләнү өчен, бернинди махсус җайланмаларның кирәге юк. Моннан тыш, трейсерлар тәннәрен саклый торган җайланмалар да кулланмый. Бу үз-үзләрен тагын да текә хис итү максатыннан түгел, ә иркен хәрәкәтләнер һәм имгәнмәс өчен шулай. Шлем тирә–якны күзәтүеңне чикләп, тән балансыңны үзгәртсә, тезләрне саклау җайланмалары берәр җиргә эләгеп тә кала ала. Шулай итеп, паркур – куркынычсызлык максатларында саклану чараларын куллану киңәш ителми торган экстрималь спорт төрләренең берсе.

Паркур ярышларны яратмаучылар өчен каралган, дисәм дә ялгыш булмас. Ул – һәр адымнан ләззәт һәм адреналин алу чыганагы. Нәкъ шушы максаттан чыгып башлаган да инде үзенең эшен иң танылган трейсерларның берсе Дэвид Белль. Әлеге француз егете беренчеләрдән булып гади сикерүләргә уникаль алымнар керткән. Үзе уйлап чыгарган махсус хәрәкәт ярдәмендә 10 метр биеклектән җиргә җиңел төшүе аны бөтен җир шарына таныта.

*Джиббинг*

Скейтборд һәм роликлар туйдыра башлаган икән, әлеге спорт нәкъ синең кебекләргә кызыклы булыр. Джиббинг култыксалар (перилалар) буенча шууны күздә тота, аның белән шөгыльләнер өчен асты махсус тирәнлек белән ясалган аяк киеме генә кирәк. Игътибар иткән булсаң, Соник һәм Тайдус кебек видео–уеннар геройлары да мондый сәләткә ия. Тик бернинди әзерлексез перилага менеп баса күрмә тагын, сәламәтлегеңне син үзен кайгыртырга тиеш!

ДӘВАМЫ БАР

19-25 яшьлекләр

*1-нче урын*
***Чулпан Гарифуллина***

# Кеше кия, мин – салам: мөселман кызларын яулыктан баш тартырга нәрсә этәрә?

Соңгы вакытта озак еллар яулык бөркәнеп йөргән мөселман кызларының бер–бер артлы башларыннан яулыклары төшә башлады. Үзләре бу гамәлләрен төрлечә аңлата. Кызларның яулык киеп–салу тарихлары белән танышып, бу вазгыятькә карата белгечләр фикерен тупладым.

*«Яулыкны салсам да, диннән баш тартмадым»*

*Наилә Шиһапова* яулыкны 19 яшендә яба. «Яулыкка бөркәнү үз теләгем иде. Аны кияргә тирә–юнемдәге башка мөселман кызлары да этәрде. Алар миңа яулык бәйләүнең фарыз гамәл икәнен искәртеп торды. Бу вакытта мин намазга да яңа гына баскан идем әле. Сөйләүләре тәэсирендә, мин дә яулык ябындым», – ди ул. Хәзер Наиләгә – 21 яшь. Ул инде яулыктан йөрми. Сәбәбен исә болай аңлата:

– Яулык япканнан соң, миңа тора-бара авыр була башлады. Эчке дөньям белән гармония юкка чыкты, үземә карата ышанычны югалттым, дип әйтимме соң… Озак кына уйлаганнан соң, яулыкны салырга булдым.

Кызның бу карарына әти-әнисе каршы килмәгән. Җиткән кыз бит инде, үз башың белән уйлап эш итәсеңдер, дип кенә әйткәннәр. Туган-тумача да кырын карамаган. Киләчәктә, әзер булгач, яңадан бәйләп йөрергә дә исәбе юк түгел. «Яулыкны салсам да, мин ислам диненнән баш тартмадым бит, намазларны да укыйм, дини яктан да үсәргә тырышам. Кешеләрнең миңа карата мөнәсәбәте үзгәрмәде», – ди үзе.

Яулыкларын салган тагын өч кыз белән элемтәгә кергән идек. Шуларның икесе моның турында нидер сөйләүдән баш тартты. Берсе: «Дин һәм сәясәт – артык җитди һәм шәхси әйбер», – дисә, икенчесе: «Һәркемнең – үз юлы, үз сәбәпләре. Бу хакта бер кешегә дә сөйләп булмый», – диде. Кызларны аңларга була, билгеле. Аларга бу адым җиңелдән бирелмәгәндер.

Зөлфия исемле әңгәмәдәшебез (исемен үзгәртүне сорады) исә яулыкны салыр алдыннан депрессиягә бирелүе турында әйтте.

– Мин тормышка карашымны үзгәрттем. Фикерем һәрдаим үзгәреп тора, шуңа күрә киләчәктә тагын ничегрәк булыр, әйтә алмыйм. Үземне диннән киттем дип тә санамыйм, башкача карый башладым һәм кешегә үз фикеремне дә такмыйм, – ди ул. – Яулыкны салгач, якыннарымның миңа карата фикере үзгәрмәде. Диндәге кайбер кешеләр миңа начар карый башлар дип уйлаган идем, әмма алай булмады.

*Сынау яулык яптыра*

Мөселман кызларының яулыктан баш тартуын Сабада укытучы булып эшләүче Алинә исемле әңгәмәдәшебез дә еш күрә башлаган. Танышлары арасында да андыйлар юк түгел икән. Кайчандыр балаларны яшьтән үк мәдрәсәгә, мәчеткә өндәп, ислам дине нигезләренә төшендереп йөргән, ә хәзер яулыктан баш тарткан бер ханымны да белә ул. «Мондый хәлгә начар карыйм, аңлый алмыйм», – ди Алинә. Ул исә яулык бөркәнүгә шактый зур сынау аша килә һәм моны Аллаһы Тәгаләнең туры юлга чыгаруы дип кабул итә.

– Яулыкны биш елдан артык бәйлим инде. 11нче сыйныфны бетергәч үк, шулай эшләрмен дип ният иткән идем. Аннан, 9нчы сыйныфтан укуын мәдрәсәдә дәвам иттергән игезәк сыңарым миннән иртәрәк яулык япты, шул да тәэсир иткәндер. Яулык ябарга тагын бер сәбәп булды, – дип үз тарихы белән таныштырды Алинә. – 2011 елда без гаиләбез белән юл-транспорт һәлакәтенә очрадык. Барыбыз да исән–сау калдык, әмма бу авария безне үзгәртте. Шушы вакыйгадан соң күбебез урын өстендә ятты. Гаиләдәгеләрнең төрле тән җәрәхәтләре булды: кайсының кулы, аягы сынган, кайсының башы бәрелде, эчәгеләре өзелде. «Бу Аллаһы Тәгаләдән бер хәбәрдер», – дип кабул иттек. Шуннан соң барыбыз да диярлек биш вакыт намазга бастык. Аллаһка шөкер, моны йөк дип кабул итмибез.

Мөселман кызларының яулыкларын салуын бар кеше дә җиңел генә уздырып җибәрми. Мәсәлән, блогер, стилист, үзе дә яулыктан йөргән мөселман хатын–кызы Ләйсән Гарифуллина бу вазгыятьне күреп, шактый борчылуы турында «Инстаграм» социаль челтәрендә яза.

– Соңгы елда гына мин белгән алты-җиде мөселман кызы яулыгын салды. Мин аларны хөкем итмим, анысы. Бу адымга алар бер генә көн әзерләнми. Кеше моңа тора–бара килә.

Диннән ерагаймас өчен, кайбер нәрсәләрне истә тотарга кирәк. Беренчедән, шайтаннан саклану өчен, Аллаһы Тәгаләгә дога кылырга. Икенчедән, тирә–юньдәгеләргә, нинди мохиттә булуыңа игътибар итәргә. Алар йогынтысы бик көчле булырга мөмкин. Тирә–яктагылар һәрвакыт Аллаһ турында искә төшереп, ислам дине турында сөйләп торса, мондый адымга бару турында уй башка керә алмый. Әмма бу очракта да сак булырга кирәк. Бар шундый кешеләр, алар өчен Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткән нәрсәләр дә тыелган санала. Кешеләр еш кына ялган тыюлар аркасында да диненнән баш тарта, мондый хәлләрне үзем дә беләм. Өченчедән, сөннәт саналган гамәлләргә әллә ни игътибар бирмәү дә кешедәге иманны какшата. Мәсәлән, кеше баштарак дүшәмбе көннәрендә ураза тотудан баш тарта, аннан намазын оныта, шулай итеп, бүтән гамәлләрдән дә ераклаша.

*«Шәрә йөрү белән бер»*

Яулык япканнан соң аны кире салу дөресме? Дин белгечләре бу хакта нәрсә уйлый? Шушы сорауларны «Гаилә» мәчете имамхатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллинга юлладык.

**– Яулыкны бер ябып, бер салу дин ягыннан ничек бәяләнә?**

– Кызганыч, әлеге хәл күзәтелә. Бәлигълыкка җиткән кызлар яулык япмыйча, озын күлмәк кимичә урамга чыга икән, бу – гөнаһ. Ата-анасына да, үзенә дә. Моны шәрә йөргән кебек бәяләп була. Яулыкны япкан, савабын алган; салган икән, гөнаһын алган. Бу уңайдан безгә – ир-атларга – җиңелрәк, без түбәтәйдән дә йөри алабыз, кимәскә дә була. Шуңа күрә кызлар яулыктан йөрсеннәр, ә Аллаһы Тәгалә аларга шушы зур эштә җиңеллеген бирсен иде.

**– Кызык өчен генә дип, яулыкны бер ябып, бер салмыйдыр бит инде алар. Нинди сәбәпләр аркасында яулыкны салырга мөмкин?**

– Әйткәнемчә, яулыкны салу – гөнаһ. Табиблардан: «Нинди сәбәп белән аракы эчәргә ярый?» – дип сорыйлар бит әле. Янәсе, йөрәк авыртканнан, борчылганнан һәм башкасыннан шифасы бар. Теләсә нинди психологик һәм физик халәттә булсагыз да, аракы эчү гөнаһ санала. Шулай булгач, нинди хәл булса да, яулыктан баш тарту – гөнаһ. Әлбәттә, якын туганнар арасында яулыксыз, әмма матур һәм тыйнак итеп киенергә ярый. Яулык япкач, кызларга савабы языла.

**– Яулыгын салган кызларга нишләргә соң?**

– Беренчедән, кызларның мондый адымга барулары, безнең – имамнар, хатын–кызлар янәшәсендә булган ир–атлар тарафыннан нәрсәнедер эшләп бетермәү, күздән ычкындыру нәтиҗәседер. Ягъни кызларның, бәлки, үз атасына, иренә сөйли алмаслык бер борчуы бардыр. Шушы вакытта аларга ярдәм, терәк кирәк. Мондый адымга барырга теләгән кызларга нәсыйхәтем шул: борчылмасыннар. Нинди генә авырлык килсә дә, аннан чыгу юлы юк дип уйласагыз да, Коръәндә Аллаһы Тәгалә: «Хәтта көтмәгән җирдән дә ярдәм итәрмен», – ди. Бу дөнья – сынау дөньясы, Аллаһы Тәгалә адәм баласын сыный, тикшерә. Яулык япкан кызларны аеруча. Кызлар безгә – хәзрәтләргә килсеннәр. Ата–аналарына сөйли алмыйлар икән, без нәсыйхәтләребезне бирербез, ярдәм күрсәтергә тырышырбыз. Бу дөньяда үзем генә калдым дип уйламасыннар, күңелләре төшмәсен һәм Аллаһыбыз аларны бу зур гөнаһтан сакласын иде.

ДӘВАМЫ БАР

## ВИЧ: беркемне аямый һич

*«ВИЧ–инфекция» дигән замана афәте җәмгыятьтә тоткан урыныңа да, гаилә хәлеңә, дәрәҗәңә, белемеңә дә карамый теләсә кемгә, теләсә кайсы яшьтә иярә ала. Россиядә ВИЧ инфекциясен йөртүчеләр саны 1,06 миллион кешегә җиткән. Бу – рәсми саннар гына әле.*

*Кызыксыну артты*

Блогер, журналист Юрий Дудь төшергән «ВИЧ в России» дип аталган фильм берничә көндә дистә миллион караучылар җыйды. Алай гына да түгел: ВИЧ ачыклый торган махсус тест сатып алучылар, тикшерү узарга теләүчеләр, чир турында интернетта мәгълүмат эзләүчеләр бермә–бер арткан.

Күп кенә зур шәһәрләрдә, мәсәлән, Санкт–Петербург, Түбән Новгород, Красноярскида СПИД–үзәкләргә мөрәҗәгать итүчеләр санының ике мәртәбә артуы күзәтелгән. Уфада исә экспресс–тест узарга килүчеләр өчләтә арткан.

Юрий Дудь ничектер читтәрәк кала башлаган җитди проблемага кабат күзләрне ачарга ярдәм итте. Хәтта хакимияткә якын кешеләр дә аның ни дәрәҗәдә мөһим булуын искә төшерде. Фильм чыкканнан соң, Татарстан түрәләреннән иң беренчеләрдән булып әлеге афәткә яшьләр эшләре министры Дамир Фәттахов игъти-

бар итте. Министр үз үрнәгендә ВИЧ–инфекцияне ачыклый торган тестны ничек узарга, балаларга бу хакта сөйләргә һәм аңлату эшләреннән оялмаска кирәклеген аңлатты.

*Оят чир түгел*

Россиядә үзенең ВИЧ статусы турында җәмәгатьчелеккә ачыктан–ачык әйткән беренче хатын–кыз Светлана Изамбаева диагнозы турында 22 яшендә белә. Чир йоктыруның сәбәбе – саклану чараларын кулланмаган җенси мөнәсәбәт.

– Мин кияүгә чыгарга дип йөргән яраткан кешемнән ВИЧ йоктырдым. Кешегә ышанасың һәм аны яратасың икән, күп нәрсә турында уйламыйсың бит ул. Менә без дә саклану чаралары хакында уйламадык, – дип сөйләде ул. – Йөргән кешем дә ВИЧ-инфекцияле икәнен белмәгән. Гадәти медицина тикшерүенә килгән җирдән ВИЧ-тест узарга тәкъдим иттеләр. «Миңа бу нәрсәгә, мин сәламәт», – дигән булдым әле. ВИЧның бөтен үзенчәлеге дә шунда бит: бернәрсәң дә авыртмый, симптомнары күзгә күренми.

Светлана ВИЧ–инфекцияле килеш тә гаилә коруга ирешкән. Ике баласы бар, алар сау-сәламәт. «Ирем дә – ВИЧ-инфекцияле кеше. Мине ул «Мисс позитив» дигән бәйгедә очратты. Нәкъ шул бәйгедә мин ачыктан–ачык үземнең диагнозым турында бөтен җәмәгатьчелеккә әйттем дә инде», – ди ул. Бу адымыннан соң аңа мөнәсәбәтен үзгәрткән кешеләр дә була. Кайбер дус кызлары аралашуны туктата, аны фахишә һәм наркоман дип гаеплиләр. «Мин ВИЧ белән авырмыйм, ВИЧ белән яшим. Бу оят чир түгел. Дарулар кулланганда, син бүтәннәр өчен куркыныч тудырмыйсың», – дип искәртә Светлана.

Әңгәмәдәшебез үз хәйрия фондын булдырып, инде дистә елдан артык шушы афәт белән күзгә–күз очрашкан кешеләргә ярдәм итә.

– Безнең әти эчә, әнине кыйный иде. Соңрак әни дә эчкечелеккә сабышты. 15 ел элек – әтине, 10 ел элек әнине күмдек. Шуларны исәпкә алып, үземнең хәлне дә аңлап, бернигә дә карамастан, мин башкаларны да тормышны яратырга, яшәргә өйрәтәм, – ди ул.

Фонд башта ВИЧ-инфекцияле кешеләрнең бер–берсенә ярдәмләшү төркеме буларак кына оеша. Хәзер инде юридик, социаль, психологик ярдәм күрсәтәләр, ВИЧ турында мәгълүмат тараталар, тренинглар үткәрәләр.

«Үз мисалыбызда күрсәткәч, чиргә карата фикер үзгәрә», – ди Светлана.

*«Үләм дип түгел, өйләнә алмам дип борчылдым»*

«Өйләнү түгел икән сөйләнү. Элеккеге хатынымнан ВИЧ йоктырдым», – дип сөйләп китте безгә үз тарихын Әлмәттән, исемен күрсәтмәүне сораган бер ир–ат. Бу вакытта аңа 30 яшь булган. Үзе әйтүенчә, хатыны аңа бик озак СПИД дигән авыруның ялган булуын, Россиядә аның таралу очраклары күзәтелмәвен аңлатып, ышандырырга тырышкан. Тикшерүләр дә киресен исбатлап торганга күрә, ул үзен сау–сәламәт дип уйлаган.

– Хатыным чирне теш табибына йөргәндә энәдән йоктырдым дип акланып маташты. Соңрак кына белдем: аның миңа кадәр йөргән егете наркоман булган. Хатыным исә шуның белән җенси мөнәсәбәткә кергән. Теш табибы дип аклануларын чынга алып, мин, хатыным белән якынлык кылганда, саклык чараларын куллану турында уйламадым да бит, – дип сөйләде ул безгә.

Аерылышканнан соң, әңгәмәдәшебез Россия ислам университетына укырга керә, сессия вакытында яңадан тикшеренеп карарга уйлый.

– Бу юлы мине, чир булмауны раслый торган белешмә бирер урынга, психологка җибәрделәр. Шул вакытта ук эшнең нидә икәнен аңлап алдым инде. Психолог башта диагнозым турында әйтә алмый азапланды. Мин исә: «Элек ВИЧ–инфекцияле кешегә өйләнгән идем, дөреслекне яшермәгез», – дип, турысын әйттем. Күңелем төште, билгеле. Психолог та юатырга тырышты: имеш, терапия алсагыз, яшәргә була. Әмма мине ул чакта үлем куркытмады. ВИЧлы килеш кемгә өйләнермен – менә нәрсә күңелемә тиде, – дип сөйләде ул.

Хәзерге вакытта аның диагнозы турында ике якын кешесе генә белә икән. Башкаларга ачылуның мәгънәсен күрми – аңламаслар дип борчыла.

– Гаилә кора, хатын таба алмыйм. Күп кенә танышу сайтларында да эзләп карадым, файдасы юк. Кайвакыт күңелне бушатасы килә, дәва алганнан соң да хәлләр авыррак була, әмма бөтен кеше белән дә сөйләшә торган сүз түгел шул, – ди ул.

Бу афәт миңа беркайчан да кагылмаячак, дип уйларга ярамый. Әңгәмәдәшебез дә шуны искәртә. Үзе әйтүенчә, күпләр ВИЧ–инфекцияне наркоман һәм фахишәләр чире дип уйлый. «Мин дә наркоман, фахишәләр янында чуалган кеше түгел лә, тик барыбер чир йоктырдым бит. Халыкның ВИЧ турында белемнәре бик

сай. Дәүләт күләмендә ВИЧ тикшерүе узуны мәҗбүри итеп куярга кирәк дип уйлыйм. Минемчә, халык кына түгел, түрәләр үзләре дә аның турында тиешенчә мәгълүматлы түгел әле», – дип саный ул.

Россиядәге СПИД үзәкләрендә дә барысы да ал да гөл түгел. Әңгәмәдәшебез әйтүенчә, дәва алу өчен шактый урау юллар узарга туры килә. Моны үз мисалында да аңлатты, әмма зарлану буларак кабул итәрләр дип, боларын язмауны үтенде.

Билгеләнә торган дарулар да сыйфатлы түгел. Еш кына кыйммәтле һәм тәэсире булган даруларны алу өчен, акчаны үз кесәңнән тотарга туры килә. «Терапия ул – гомерлек. Аннан агулану очраклары да еш була», – ди ул.

ДӘВАМЫ БАР

## Һөнәрнең җенесе юк

*Һөнәрләргә бәйле чикләр юкка чыкты диярлек. Хәзер гүзәл затлар, тели икән, автобус та йөртә, кранда да эшли. Чабып барган атны туктатыр, дөрләп янган өйгә керердәй хатын-кызлар тимер-томыр белән генә дуслаша алмас димени? Ә менә ир-атларның хатын-кызлар эшли торган шөгыльгә алынуы бераз гаҗәбрәк тоелырга мөмкин. Бигрәк тә безнең илдә мондый күренешкә озаграк ияләшергә туры килә. Һөнәри рольләрне алмашкан ир-ат һәм хатын-кызларны без дә барладык.*

*«Хатын-кызлар миңа элеккеге егетләре турында сөйләр өчен дә килә»*

23 яшьлек Казан егете Нияз Нәбиуллин – үзенчәлекле һөнәр иясе. Ул – лашмейкер, ягъни хатын-кызларга керфек ясаучы. «Башта нинди өлкәгә килеп эләгүемне аңламаган да идем. Хәзер исә шөгылем миңа бик ошый», – ди егет. Процедурага килгән кызларның кайсы көлеп, кайсы ышанмыйча, качып китүчеләре дә булган.

Нияз керфек ясаучы һөнәренә тик торганнан гына керешми. Армиядә дә хезмәт итә, аннан кайткач, институтка укырга керә.

– Институтта укуым барып чыкмады. Шуннан соң Мәскәүгә күченеп китәргә уйладым. Анда үз эшемне булдырып, балалар өчен уенчыклар сату белән шөгыльләндем. Командама гади сатучы булып эшләүче бер иптәш алдым. Берникадәр вакыт үткәч, аның керемнең бер өлешен үзләштерүен сиздем. Бу кеше белән

килешүләрсез генә эш алып барган идем. Бар булган акчама тараканлы бер бүлмәле фатирга күчендем. Шулай итеп эшкә дәртем сүнде, бизнес янды, – дип сөйләде Нияз. – Яңадан Казанга кайттым. Очраклы рәвештә дус кызымны очраттым. Ул маникюр ясау белән шөгыльләнә икән. Аның белән сөйләшкәннән соң, матурлык өлкәсендә эшләүче ир–атларны барлый башладым. Мин көндәшлек азрак булган өлкәләрне эзләдем. Карый торгач, керфекләр ясауда беренче булыйм әле, дидем. Тиз арада курслар узып, эшкә керештем.

Нияз өчен хәзер төп илһам чыганагы – керфекләрен матурлатырга килүче хатын-кызлар. «Алар минем эшемнән канәгать икән, бик сөенәм», – ди ул.

– Иң беренче керфек ясавым җиде сәгатькә сузылды. Керфекләрен миңа ышанып тапшырган кыз алдында шулкадәр уңайсыз булган иде миңа ул чакта. Хәзер инде остардым. Иң кимендә – 1 сәгать тә 30 минут эшлим, – дип сөйли Нияз.

Әңгәмәдәшебез – оста куллы белгеч булуыннан бигрәк, хатын–кызларның бетмәс–төкәнмәс сер–зарларын тыңлаучы да.

– Килгән кызларга минем белән сөйләшеп утыру, серләре белән уртаклашу да ошый. Мин – яхшы тыңлаучы, ахры, юкса, сөйләмәсләр иде. Кызларның элек йөргән егетләре турында сөйләүләрен еш ишетергә туры килә. Бер мәртәбә килгәннәр тагын язылa. Белмим, әллә үземне ошаталар, әллә эшләрем бик шәп килеп чыга инде, – ди Нияз.

«WorldSkills» чемпионатының «Яшь профессионаллар» төбәк бәйгесе катнашучысы Рәмзил Камалиевны онытып өлгермәгәнсездер. Егет киемнәр тегә. Сеңелләренә дә, үзенә дә киемнәрне кибеттән аласы түгел. Башкаларның да аңа мөрәҗәгать иткәне бар икән.

Кукмара районының Починок-Кучук авылы китапханәсен 2011 елдан башлап ир–ат җитәкли. 32 яшьлек Сергей Прокофьев бу һөнәргә ничек килүе турында менә нәрсә дип сөйләде:

– Китапханәче булып тугыз ел эшлим. Бу һөнәр белән танышуым балачакта булды: әнием китапханәче иде. Гаилә традицияләрен дәвам иттерәм, дисәм дә була. Китапханәдә эшләвемә күпләр аптырый инде. Ир–атка бер урында тик утырып эшли торган һөнәр килешми, янәсе. Әмма һөнәр ул ирнеке яки хатынныкы дип бүленәме?! Күңел кушкан хезмәтне башкарасы килә бит. Китаплар арасында эшләүне күңелсез диючеләр ялгыша. Бу әле – үзеңне көндәлек камилләштерү дә. Китапханәче

– психолог та: китап сорап килүчеләргә күңеленә хуш килердәен бирергә кирәк бит. Без күп функцияләр үтибез.

ДӘВАМЫ БАР

*2-нче урын*
***Зәринә Хуҗина***

## Телгә хөрмәт – татарның канында

*«Татар кешесе! Бел! Син сөйләшкән тел дистәләгән гасырлар буенча чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән. Синең телеңдә катлаулы фәнни хезмәтләр дә, илаһи төшенчәләр дә, гүзәл әдәби әсәрләр дә язылган. Аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер!» (Т.Миңнуллин. Татарның әхлакый кодексы.).*

Үткәннәргә хатлар бармый, диләр,
Ышанмадым, булдым язарга.
Үзебезчә, саф татарча итеп,
Туфан абый дип Сезгә дәшәргә.
Уй–хисләремне уртага салып,
Сезнең белән киңәшергә.

Сезнең күп санлы исемнәрегез, дәрәҗәләрегез арасыннан татар баласына иң кадерлесе – Туфан абый. Сез бит, барыннан да элек, татар җанлы олуг шәхес, язучы. Сезне ничек ятратканнарын белсәгез…(хәер бу Сезгә яңалык түгел инде). Сез – халкыбызның күңел түрендә. Габдулла Тукай кебек. Ә бит монда да охшашлык юк түгел: Габдулла улы бит Сез.

Туфан абый, оят булса да әйтим инде, мин бит Сезнең хакта чын–чынлап, яхшылап Сез бакыйлыкка күчкәч кенә белдем. Бик яхшы хәтерлим мин ул көнне. Әниемә дусты, хезмәттәше Әлфия апа шалтыратты: Туфан Миңнуллин вафат. Телефонның теге башында Әлфия апа елый, бу башында –әни. Үзләре елыйлар, үзләре нәрсәдер такмаклыйлар: «Без тагын ятим калдык. Татар халкы ятим калды».

Мин исә бу галәмәткә шаккатып карап торам. «Андый язучы бар. Нәрсә язган соң әле ул? Ә-ә, «Авыл эте Акбай». Соң, язучылар да үләләр инде, шуннан нәрсә булган?» – менә шундыйрак уйлар йөгереп узды минем баштан. Шулай да кызыксынуым көчле иде. «Кем ул Туфан Миңнуллин?–» дигән соравыма әнием гаҗәпләнеп миңа карап алды да, компьютер янына килеп, нидер эзли башлады. «Кара», –диде ул, әкрен генә. «Әниләр һәм бәбиләр» драмасын тын да алмыйча бер–бер артлы өч тапкыр карадым мин ул чакта. Менә шулай килдем мин сезгә, Туфан ага. Күңелемә иң

уелып калганы – бала тирбәтүче ике ананың бишек җыры. Озак вакытлар көйләп йөрдем мин ул бишек җырын. Ә бит мин ул чакта, Туфан абый, үзем дә сизмичә, белмичә Сезнең фикерләрне күңелемә сеңдергәнмен. Әйе, бишек җыры яшәгәндә, алар онытылмаган очракта гына туган тел, милләт яшәячәк. Беләсезме, Туфан ага, мин бит бик бәхетле, замана баласы булсам да, бишектә, әйе–әйе, сиртмәле бишектә үскәнмен мин. Малайлар дөньясында бер кыз булгач, кадерләгәннәр мине, бишек тә тапканнар. Бишегем өстенә иелеп әнкәм, әбкәм, хәтта бабам да бишек җыры көйләгәннәр, мин иң кадерле тәүге сүзләремне әйткәнмен, әтием әкиятләр сөйләгән, мин балачак җырларын җырлаганмын. Болар барысы да, барысы да күңелемә туган телем –татар теле аша кергән.

Үсә төшкән саен, мин туган телем, халкым турында күбрәк белдем, белгән саен туган телемә булган мәхәббәт һәм горурлык хисләре арта гына барды.

«Бел! Син сөйләшкән тел дистәләгән гасырлар буенча чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән». Бел! Гади генә шушы бер сүз күңелнең иң тирән почмакларына үтеп керә дә, Туфан абый, үткәнебезгә, ата–бабаларыбыз рухына башкача карарга мәҗбүр итә. Әйе, туган телем – тарихлар ялкыны. Гасырлар да синең аша ага. Татар теле үзенең үсеш дәверендә төрле кыенлыкларны, киртәләрне үтте. Халык күпме изелсә дә, ана телен саклап калды. Ә милләтнең саклануы турыдан–туры телгә бәйле. Чөнки гыйлем алу, аңны үстерү, дөньяны танып белү һәм аралашу туган тел аша тормышка ашырыла. Күз алдына китерик: үзенең туган татар телен белмәгән кеше әдәбиятыбызның чишмә башы Кол Гали, бөек Тукай, герой–шагыйрь Муса Җәлил, Хәсән Туфан һәм, әлбәттә, Туфан Миңнуллин әсәрләрен уку бәхетеннән мәхрүм. Иң аянычы: алар хәтта үзләренең нинди зур бәхеттән коры калганнарын да аңламыйлар. Татар теле дөньясының үзе бер тылсымлы дөнья, телебезнең иң бай, иң мул сүзлек хәзинәсенә ия икәнлеген ничек аңлатырга соң? Ә бит мин бу сорауга җавапны таптым, Туфан абый. Ничек дисезме? Әлеге дә баягы Сезнең аша. Бу хакта соңрак. Үземнең уйларымны җиткереп бетерим әле сезгә.

Тел – сөяксез, ди халык. Туган телнең матурлыгы, байлыгы, аның шагыйрьләр теле булуы хакында күп язарга мөмкин. Иң әһәмиятлесе бит – «аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер!» Менә монысы инде четерекле мәсьәлә. Ул бит бер безгә –татарларга гына кагылмый. Милләтне аерып торган мөһим нәрсә –аның туган теле.

Күп гасырлар дәвамында буыннан –буынга тапшырылып килгән, бәяләп бетергесез хәзинәгә тиң булган туган телне саклау – һәр милләтнең бурычы.

Иң беренче чиратта без халкыбызның тарихын белергә тиеш, дип уйлыйм мин, Туфан абый. Бер вакыйга күңелемә уелып калды минем. 18нче йөз әдәбиятын өйрәнәбез. Пугачев хәрәкәте турында сүз бара. Бәхтияр Канкаев исеме яңгырады. Укытучының: «Кем ул Бәхтияр Канкаев? Аның турында нәрсә беләсез?» дигән сораулары җавапсыз калды. «Салават Юлаев исемен ишеткәнегез бармы?» – дигәч, безнең телләр чишелде. Аның исемендә хоккей командасы, Башкортстанда шәһәр, аңа куелган һәйкәл дип, бер–бер артлы тезеп киттек без.

«Молодцы, башкортлар! Үз геройларын кадерли беләләр, ә без… Ярый әле милләт сагында торучы Туфан абый бар, аңа рәхмәт. «Канкай углы Бәхтияр» драмасын алыгыз, укыгыз. Алдагы дәресләрнең берсендә шул хакта сөйләшербез. Укып чыккач, Туфан абыйга рәхмәт әйтергә онытмагыз!» – диде укытучыбыз.

Укытучыбызның «Молодцы, башкортлар» дигән сүзе үтерде дә инде мине. Чыннан да бит, Туфан абый, үз батырларыбызны барламасак, исемнәрен мәңгеләштерү, киләчәк буыннарга җиткерү турында үзебез кайгыртмасак, безне кем кайгыртыр! Барысы да үзебездән тора бит. Дәүләте булган халык бит без!

Туфан абый, ә бит төптәнрәк уйлап карасаң, Жириновскийның сүзләрендә хаклык юк түгел. Сезнең истәлекләрдә язылган «Татарларның бит дәүләте булган…. Булса ни. Булган чакта сакларга кирәк иде, хәзер тыпырчынудан ни мәгънә. («В свое время надо было защищаться, сейчас нечего рыпаться») дигән сүзләр турында әйтәм, әлбәттә. Әйе, йөрәккә кадалырдай сүзләр шул. Дәүләте, теле булган халык бүгенге көндә үзен Россия составындагы суверен республика дип яшәсен инде. Хәзер ул да юк. Әкәмәт шул, әкәмәт.

Менә шул Россия составында телебезне саклап калу һәм үстерү өчен нәрсә эшлисез соң дисезме, Туфан абый? «Суның кадере чишмә корыгач», ди бит халык, «теленең кадере тел беткәч» булмасын иде шул. «Ана сөте белән кермәгәнне тана сөте белән кертә алмассың»,дип тә өсти әле халкым. Шулай шул, ана телен саклау гаиләдән башланырга тиеш. Ә бүгенге көнгә күз салсак, татарча өйрәнергә теләп, татар авылына кайткан Ириналар тизрәк авылдан качарлык хәлдә шул без, Туфан абый. Тагын йөрәккә кадалырдай хәлләр. Шагыйрь әйтмешли, «Совсем сүзен «чәпчим»

чәпчетеп кенә калмадык, туган телебездә бер-беребезне аңламаслык булып үсеп җиттек бит. Өлкән буын телне белеп, яшь буынга ул өйрәтелмәсә, чылбыр өзелә. Катнаш никахларның да роле бик зур бу очракта. Үз җирендә телсез, йолаларсыз калу була инде ул. Әниемнең энесе марҗага өйләнгән, алар ерак Себердә яшиләр. Кунакка кайткач, кызлары Лилия апаны әнием мәҗбүриләп диярлек татарчага өйрәтте. Иң башлап «тетя Гульназ» Гөлназ апага әйләнде. Татарча сорамаса, әнием Лилия апага җавап бирми, яки татарчасын кабатлатып аңлата, миңа да татарча гына аралашырга куша иде. Аның белән бергә мин дә русчамны чарладым. Лилия апа тел өйрәнүгә бик һәвәс булып чыкты. Бер ай эчендә ярыйсы гына татарча сукалый иде инде ул. Әтисен татарча сәламләп, татарча сөйләшеп каршылады ул. Әтисенең күзләре дүрт булды, Туфан абый. Әмма әниемнең кызың белән татарча аралаш дигән сүзләрен абый тыңламады, күрәсең. Лилия апа телефоннан безнең белән татарча аралашырга тырышса да, тирәлек үзенеке итте, алдагы каникулда Лилия апа безгә кайта алмады, рус мохите Лилия апаны яңадан үз эченә тартып алды. Ләкин татар җаны канында калды. Халкыбызның милли, дини бәйрәмнәре белән котларга беркайчан да онытмады.

ДӘВАМЫ БАР

## «Бар яклап та сынады безне тормыш»

*Тормыш бик кызыклы, матур, авыр нәрсә ул. Тормышның каты җилләренә түзә белгәннәр генә алга таба яши ала. Язмыш сынауларын үтә алган Тәгъзимә әбинең язмышы яшьләргә үрнәк булыр дип уйлыйм. Тәгъзимә әби белән сөйләшеп, аның тормышы турында белгәч, күземнән сөенү, шул ук вакытта кызгану яшьләре акты. Ничаклы ел безнең күршедә яшәгән әбине мин яңадан ачтым, яңадан өйрәндем.*

Тәгъзимә әбинең оныгы – Алисә минем иң якын дустым. Без кечкенәдән үк бергә үстек, балачагыбыз бергә үтте. Алисәләрнең капка төбендә атынгыч һәм эскәмия тора иде. Без, бала–чагалар, шунда җыелып, я көнбагыш, я алма ашап утыра идек. Тәгъзимә әби безнең тавышны ишетеп чыга да: «Чүбегезне монысында үзегезгә җыйдыртам, сезнең артыгыздан җыеп йөрмим»,– дип ачулана. Көнбагыш чүбен кая куясың инде, ташлый идек шунда. Берәр савытка җыйсак, нәрсә булгандыр? Тәгъзимә әби

пөхтәлекне ярата иде, шуңа да безгә аннан каты гына эләккән чаклар булды.

Гомер уза, без дә үстек. Тәгъзимә әбигә июнь аенда 89 яшь тулды. Шушы 89 ел эчендә ул кайгысын да, шатлыгын да, күрергә, хәсрәтләрен дә татырга өлгергән. Ләкин барыбер Тәгъзимә әби начар вакытларны бик искә төшерергә тырышмый, бик сабыр, көчле рухлы кеше бит ул. Бу язманы укып чыксагыз, көлеп тә, елап та алырсыз. Шәхсән минем күңелгә Тәгъзимә әбинең язмышы бик каты кагылды.

«1930 елны Актаныш районы Татар Әҗбие авылында туганмын. Әнием Җинан биш кыз бала тапкан булган, шуларның дүртесе кайсы тугач, кайсы туганда ук үлгән. Мин генә исән калганмын», – дип башлады сүзен Тәгъзимә әби. Тәгъзимә әбигә әнисенең назын тоеп үсәргә насыйп булмый. Җинан аңа биш яшь булганда дөнья куйган. Кечкенә Тәгъзимәне әтисе Каһир һәм үги әнисе Габделбану тәрбияләп үстергән. «Үги инәй белән тордым, ул бер дә начар кеше булмады, яхшы булды. Минем хәтта үги инәй белән торганымны белмәделәр дә. Аның бер кызы бар иде. Икебез бергә үстек. Үзем тормышка чыккач, әни йортка бер бабайны кертте, ул да үземнең әти сыман булды.

Әти сугышка киткәндә үги инәй белән калдым. Әтине озата барганда, ул мине зират коймасы янында бастырып калдырып китте, үги инәй белән булгач, үләр дигәндер инде. Тормыш авыр булса да, бар яклап та безне сынаса да, үлмәдек, тырыштык, тырмаштык, ач–ялангач булдык, без генә түгел, ил белән бит. Әти үзе сугышта үлде. Сугышка киткәч, аның бер генә хаты килде. Аннары – «Безвестно пропал» дигән кара кәгазь».

Тәгъзимә әби 12 яшьтән алып 50 яшькә кадәр колхозда эшләгән. «Колхозда авыр булса да, күңелле иде. Мин кызык сүз сөйләргә яратам, синең белән рәхәт диләр иде авылдашлар. Башта мине нигәдер, усал дип уйлый торган булганнар, кайберәүләр бергә эшләргә эләкмәсәк иде бу апа белән дип уйлаган, эшләп карагач кына белделәр минем белән ничек күңелле икәнен. Колхозда үземне бик яраттылар. Балаларым күп булу сәбәпле, 50 яшьтә пенсиягә чыгырдылар.

Печән вакытында печәнне чабар идек, җыяр идек, кибән итеп кояр идек. Ашлыкны заготзерного тапшырыр идек, берничә ел грузчик булып йөрдем, хатын–кызга капчык күтәреп йөрү бер дә рәхәт булмады. Шәл, джемперлар бәйләдем, балаларга башлыклар бәйләп кигездем; чигүгә оста идем, төрле чигүне дә чиктем,

канва, тамбур, энә белән дә. Әллә ничә кешегә мамык шәл бәйләп бирдем. Яшь вакытта, аллага шөкер, чиста йөрдем, хәзер дә шулай пөхтә, матур киенеп йөрергә яратам. Авыл советында депутат идем. Анда мал учеты да ала торган идек, кеше учетларын алдык, балаларны больницага йөрттем, мин ияртеп алып бармасам, бармый торган иделәр».

Мәхәббәт. Бу турыда күпне күргән әбидән сорамыйча мөмкин түгел иде. Дөнья тоткасы мәхәбәттә бит! Мәхәббәтегез турында сөйләгез дигәч, Тәгъзимә әби елмая башлады, аның күлүендә үк ягымлы хатирәләр сизелеп тора иде. Мин түземсезлек белән аның сөйли башлаганын көттем. «Мәхәббәт турында сөйли башласаң, бер тарих китабы язарлык бит ул. Булачак ирем белән клубта таныштык. Кичке уенга чыккан идек, шулай уйнаган мәлдә күтәреп алып китте мине. Өч көн артымнан килеп йөрде. Дүртенче көнне ЗАГСка барабыз, язылышабыз дип килгән. Кияүгә 28 яшемдә 1958 елны чыктым. Насих күрше авыл егете иде, безнең авылдан 8 км ераклыкта. Минем армиядән кайтасы егет тә бар, үпкәләшкән идек, аны көтмәдем шул. Армиягә озаткан егетем 1 нче класстан йөргән егетем иде. Ул армиягә киткәч, минем артымнан икенче егет килде, авыл яшьләре шул армиядәге егетемә башка егет белән йөри дип язганнар. Йөрми идем дә инде мин аның белән, гел куа идем. Шуннан бу ачуланып, үпкәләп хат язган. Бәлки тормыш махсус шулай эшләгәндер, мине Насих белән кавыштырыр өчен. Кем белгән инде анысын», – дип сөйләде Тәгъзимә әби.

ДӘВАМЫ БАР

## Ике гасыр арасы

*Көннәр. Айлар. Еллар һәм дә гасырлар. Тарих тәгәрмәче шулай берсен–берсе алыштырып әйләнә дә әйләнә. Кеше гомере өчен кайчак көннәр гасырга тиң булса, тарих өчен гасырлар да бер мизгел булырга мөмкин. Ничек кенә булмасын, безнең яшәешебез көннәр, еллар, гасырлар аралыгындагы вакыйгалар, хәлләргә барып тоташа.*

Хәтта сәгате, минуты, секунды да санаулы. Үткән заман, хәзерге вакыт, киләчәк бар. Кайсы гына заманны алсаң да, яшәү–үлем, мәхәббәт–нәфрәт кебек мәңгелек фәлсәфәләр белән беррәттән, минемчә, милләт һәм тел мәсьәләсе һәрвакыт аерым бер урын алып тора. Тарих битләрен актарсаң, тел, милләт язмы-

шы, телне саклау, үстерү халык язмышы белән янәшә икәнлекне күрәсең дә уйга каласың. Бу проблема нилектән килеп чыга? Нәрсә җитми кешеләргә? Бүгенге көндә бу мәсьәлә ни сәбәпле кискенләште? Аны ничек хәл итәргә? Бик күпләрне уйга салган бу мәсьәлә мине дә борчылырга, җавап эзләргә мәҗбүр итә. Өстәвенә мин үземнең киләчәгемне анам теле – татар теле фәне белән бәйләргә җыенам.

Уйлар, уйлар… Җитез аргамактай очалар да очалар. Алар өчен гасырлар, еллар аралыгы берни түгел. Уйлар өермәсендә Кол Гали, Тукай, Исхакыйлар, Җәлил, Туфаннар бөтерелә. Күңел бәргәләнә, кемне эзли ул?

Ә мин хыял канатларында гасырларны иңлим. Әнә Мөхәммәдьярлар дәвере, әнә Тукай, Ф. Әмирханнар чоры; Һ.Такташ заманы… Хыялым дөньясы ике гасыр арасы – Бубилар тукталышында. Әйе, эзләгәнемне тапканмын икән бит. Бертуган Бубилар. Горур, нык ихтыярлы, ачык йөрәкле, сүзләре эштән аерылмый торган көчле рухлылар.

Мөхлисә Бубый – ислам дөньясында феномен булган алдынгы карашлы педагог–мәгърифәтче, хатын–кыз мәсьәләләре буенча ислам тарихында бердәнбер казыя. Ачы, гыйбрәтле язмышлы Мөхлисә Нигъмәтуллина, нинди генә шартларга куелса да, иманының нык булуын, башкарган эшләренең киләчәк буыннар өчен кадерле, кирәкле һәм дәвамлы булачагын, бөтен эшчәнлеген Аллаһ ризалыгы өчен алып баруын үлеп яратуы белән раслаган шәхес. Менә кемнәр җитми бүген безгә! Менә кемнәр кирәк милләткә!

Үткәннәргә «җан өрәм» һәм хыялымда аны терелтәм: мөлаем йөзле, ак шәлле, тыйнак карашыннан ниндидер бер якты нур сибелгән ханым. Мин, күптәнге танышымны очраткандай, үзенә тартып торучы бу ханымга таба атлыйм: «Исәнмесез, Мөхлисә апа». Ә ул исә, игътибар белән мине күзәткәннән соң, сак кына сәламемне ала: «Әссәләмегаләйкем. Сезне кем дип белик?» (димәк, замана җилләре сак булырга өйрәткән)

– Мин киләчәктән, XXI гасыр кызы, Әгерҗе төбәгеннән, – дип әйтеп бетерергә өлгермим, укытучыларга хас таләпчән һәм ышандыра торган тавыш ишетәм: «Безнең хатын–кызларыбызга төшкән бурычларның берсе – үзебезнең гореф–гадәтләребезне саклау булса, икенчесе –телне саклау».

– Гореф-гадәтләр, телне сакларга кирәклекне беләбез дә бит, Мөхлисә апа, әмма нишләргә?

Ул, ягымлы елмаеп, кулымдагы планшетыма карап алды да: «Ә син игътибарлы бул, төптән уйла, законнар кабул итеп кенә телне саклап булса иде ул, – диде. – Милләт баласы милләтнең атасы кулында түгел, бәлки анасы кулында тәрбия күрә, үсә, кеше була. Гаиләнең иң олы бурычы– тәртипле, әхлаклы, милли рухлы бала тәрбияләү. Шуңа күрә кызларыбызны укыту зарур».

Мин, җавап бирергә теләп, авызымны ачкан җирдән, планшетымнан килгән «Әлли–бәлли–бәү..». бишек җыры ишетеп гаҗәпләнеп туктап калдым.

– Белем алу, гыйлем бишек җырыннан башлана инде ул, балам. Шуны онытма! Телне, динне саклауга һәркем үзеннән өлеш кертергә тиеш. Минем вакыт чыгып бара. Милләтебез язмышы сезнең кулда, балам.

– Хушыгыз, Мөхлисә апа. Рәхмәт сезгә. Зинданнарны ярып чыккан, ассалар да, киссәләр дә исән калган бөек татар теленең бетүенә Сезнең үрнәктә канына теленә, милләтенә карата мәхәббәт сеңгән халык юл куймас.

Ике гасыр арасы һәм чынбарлык. Мөхлисә Бубыйның сүзләре мине тирән уйга салды. Милләтем дип, халкым, туган телем дип яшәгән Бубиларның варислары була алырбызмы без? Хәтергә язучы, Г.Тукай бүләге иясе Ркаил Зәйдулланың «Үлеп яратты» спектакле килә. (классыбыз белән Казанга барып карадык без аны) Мөхлисә Бубый, төрмә камерасында утырганда, балаларын күз алдына китереп, ана буларак аларга соңгы сүзен җиткерә. «Мин сезгә дини һәм дөньяви белем, тәрбия бирдем. Белемле кеше үз кадерен белә. Үз кадерен белгән кеше беркайчан да кол булмый. ...Хатын–кызлар татар җанлы булсалар, милләтебез беркайчан да югалмас!» Бәгырьләребезне телгәләгән туган телне саклап, татар булып калу сынавы алдында калган шартларда бу сүзләр бүген дә актуаль, минемчә.

ДӘВАМЫ БАР

*3-нче урын*
***Индира Гайнетдинова***

## Үткәннәргә сәяхәт

*Колакларны чыңгылдатып яңгыраган каты тавышка сискәнеп уянып киттем. Купе ишекләре шыр ачык булу сәбәпле, күрше вагоннардан аермачык ишетелгән тавышлар төшемне бүлделәр. Татлы йокымнан аерылып, башымны йомшак мендәрдән күтәрә алмыйча азапланган килеш, яртылаш ачык күзләрем белән тирә-юньне күзәттем.*

Карачкы кебек караеп күренгән агач-әрәмәлекләргә, кыйшайган түбәле йортларга, буш басуларга, төтен, тузан белән ысланган каралты-кураларга карап бару тәмам туйдырды. Күзне ял иттерердәй, күңелгә куаныч бирердәй берәр манзара, тормыш, кайнап торган кала-сала очрасын иде, ичмасам. Ачык тәрәзәләрдән биткә салкын җил өрә – быел җәй салкын килде. Тән буйлап бәбкә йоны йөгерә, ә күз алдыннан калейдоскоп кебек сурәтләр алмашына: үткәне, бүгенгесе, киләчәк. Алар арасында балачак кына – якты һәм җылы. Шулай тирән уйлар диңгезендә йөзеп утырган арада, янәшәдә утырган, саргаеп арыган гәҗитне тырыша-тырмаша укып азапланган Дилфат бабайга күзем төште. Янында берничә калын китап һәм фотосурәт ята. Фотода исә милли китапханәдән күренеш. Борынгы биналардагы үзгә ис һәм китаплар дымы бер аңкышка агып чыга да, әсәрләнеп каласың. Бер карасаң, үзе бик җидти профессорга охшаган, бер карасаң, чи авыл бабайларыннан бер дә ерак китмәгән. Пошына-пошына нииндидер хезмәтләр актара, күп тә узмый, шаркылдап көлеп җибәрә, тагын укый, тукталып тирән уйга бата, киредән авызы колакта, ә колак еракта. Укыганын йомшак кына тавыш белән тагын берничә тапкыр кабатлап ала. Әйе, шундый киң күңелле карт инде ул, Дилфат бабай; тарих белән кызыксына, гомере буе бик күп илләр буенча сәяхәт кылган, йөзләгән шәһәрләрләрдә эзен калдырган.

Әле кичә генә танышкан булсак та, бабай турында бик күп мәгълүмат тупларга өлгердем. Эчкерсез ич, киң күңелле, гел сабый бала кебек инде үзе. Янында кечкенә генә буйлы, ак яулыгын чөеп бәйләгән Зифа әби иртәнге чәй әзерләп азаплана. «Сөймим

шушы поезд ризыкларын. Гомерем буе картым белән дөнья гизеп йөреп, тәмам бизеп беттем инде шушы ««ярымфабрикат» ризыкларыннан. Менә ичмасам, авыз итегез, үз йортымда пешкән җылы ризык..» – дип сөйләнә-сөйләнә, кабарып пешкән, борыннарны кытыклап, вагон буенча таралган хуш исле ризыкларын өстәлгә китереп куйды. Уянганымны күрсәтмәскә тырышып, шыпырт кына ятсам да, Зифа әби минем торганны сизеп алып, үзенең сый-нигъмәтләрен миңа да кыстый-кыстый ашатты. Чыннан да, өй ризыгы телләрне йотарлык тәмле инде ул, авызда эреп китә. Ә Дилфат бабай исә,тарихка башы-аягы белән чумып элекеге еллар буенча сәяхәт кыла иде. Әбинең сөйләнгәннәрен колагына да элмәде. «Килеп җитәбез ич, уян!» – дип, дәшкәч кенә кинәт сискәнеп көрән төстәге, маркалар белән ябештерелеп беткән чемоданын утыргыч асытыннан тартып чыгарып тиз-тиз тутырырга кереште.

Зифа әби белән Дилфат бабай шәһәрдән биш-алты чакырымлык авылга юл тоталар иде. Шәһәр ыгы-зыгысыннан туеп, гомерләренең көзентыныч тормышта үткәрәселәре килә, шуңа күрә кечкенә урыс авылыннан йорт сатып алганнар. Дилфат бабай туган йортын калдырып чыгып киткәндә аңа нибары сигез-тугыз яшь чамасы булган, шуңа күрәаларга мондый күченеп йөрү эшләре бернинди авырлык тудырмый, киресенчә, яшьлек елларына алып кайта. Тик язмышлары гел шулай язгы чәчәктәй атып утырмаган шул. Икесе тиңрәхимсез һәм дәһшәтле Бөек Ватан сугышы елларын узган бөек кешеләр.Әле ул вакытта сигез-тугыз яшьлек сабыйлар булсалар да, ачы һәм ач, авыр еллар мәңге хәтердән чыкмаслык булып йөрәкләрендә уелып калган. Тик сугыш елларына әйләнеп кайтып сөйли китсәң, алар сүзне икенче якка борырга керешәләр иде. Дилфат карт аеруча сугышның барлык авырлыгын үз җилкәсендә күтәреп йөрткән кеше: рәхимсез сугыш әти-әнисен дә, алты бертуган сеңлесен дә алып киткән. Вагондагы халыкның гөр килүе йокымнан арындырмаса, әле дә фашистлар белән сугышып йөргән булыр идем. Янәсе, сугыш башланган яки мин үткәннәргә кайтканмы, билгесез, ләкин бомбалар гөрелдәве ишетелә. Ә башымда бердәнбер уй: ник качмадым мин бу илдән ?!... Һәм шул вакыт бабай сүземне бүлдерде: «Сугыш бит ул, улым, гасырлар дәвамында синдәйләрне генә түгел, алпавыт ирләрне, көчле хатыннарны изеп үзенә буйсындырган тулы бер организм. Ә син, ә без – лаеклы нәселебезне дәвам итүче нәзберек кенә кешеләр, ләкин без көчлерәк, чөнки без шул тулы

бер көчле организмга күзгә-күз карашып каршы торганбыз». Зифа апа сүзебезгә кушылып: «Язмыш булгач, төрле хәлләр була инде: үксетеп елата да, канга батырып кыйный да, эчләр шомарып катканчы көлдертә дә дигәндәй... Әйдә, кайгылы хәлләргә караганда, рәхәт вакытлар күбрәк булды түгелме соң, Дилфаткаем, шуларны сөйләп узыйк», – дип, кыенсынып кына елмаеп, күңелне ярып үтеп керерлек җылы караш ташлады. Күрәм, әле дә йөрәкләреннән кан саркый, тик шулай да әлеге ике яшь йөрәкле кешедә бәхет дигән нәрсә бар яклап ташып тора иде. Алар яшәү ямен бөтен җаны-тәне белән тоеп, гөрләп яшәргә ашкынып торучы изге йөрәкле кешеләр.

Поезд, шак-шок килеп, станциягa килеп туктады. «Яшь йөрәкләрдән» башка перронга төшүчеләр күренмәде. Тиз генә саубуллашып, бер-беребезгә матур теләкләр теләдек тә, үз урыныма барып утырдым. Башка сөйләшер кеше юк дип, уйларыма кереп чумдым. Хе, кызык бит ә! Ничә яшь ара, ә үзебез озын юл буе ничек җиңел вә рәхәт итеп сөйләшеп кайттык. Әйтерсең лә, яшьтәшләр, юк–юк, алай гына да түгел, күптәнге якын дуслар. Ничек әле, «алтыдагы–алтмышта» диләр бит?! Дөрес икән.

Поезд вагоннарында хәрәкәт суына: халык та йокымсырый, проводниклар да иренеп кенә атлый, тәрәзәләрдән ялт-йолт күренеп алган билгесез шәһәр дә, авызын ача–ача, якшәмбе кичен озата. «Ярый, тиздән минем тукталыш, күп калмады инде», – дип, тынычландырдым үземне.

Мин исә Казаннан Волгоград шәһәренә юл тота идем. Укуда яхшы өлгереш күрсәткән өчен берничә студентка күз явын алырлык мәһабәт биналар арасыннан яралары әле дә сыкрап торган Севастополь, Керчь, Санкт–Петербург кебек бай тарихлы шәһәрләргә сәяхәт оештырганнар иде. Шунда өч ай яшәп, тарих белән бәйле фәнни эш алып барырга дигән җидти бирем бирделәр.

Каникулларга сусап, тилмереп көтеп алган җәй айларына алдан ук башка планнар корып куелган булса да, тарих белән тыгыз бәйләнгән эштән баш тартырга кыймадым: бер ел эшкә җикмәгән чемоданымны тутырып, дус–туганнар белән саубллашып, маҗаралар эзләп поездка утырдым. Бүген инде мин җәйге кояш нурларында коенып, районыбыз базарының каты чәен чүмереп, хыяллар диңгезен кичә–кичә тарихи шәһәргә юл тотам. Шулай җылы кояш нурларына әлсерәп китеп, әзрәк черем итеп

алганмын. Проводникның миңа төртүеннән кисәк уяндым, килеп җиткәнемне сизмичәдә калганмын икән.

«Яңа шәһәр – яңа тормыш», – дип эчемнән кат-кат кабатлап, алга атладым. Бу юл – үз-үземне эзләүнең чираттагы адымы, алга үрмәләргә ныклы нигез булачагына ышанычым һәр адымым белән арта гына бара иде. Барлык мәшәкатьләремне үткәннәрдә калдырып, тирән сулыш алдым. Яңа шәһәр–яңа тормыш, ә шәһәр – ул тере организм, сәяхәтләр исә шул организмның ничек эшләвен эчтән күзәтеп, үзеңнең эчке дөньяңны тәртипкә салырга ярдәм итә. Сәяхәт итү кешене бөтенләй яхшы якка үзгәртә диләр бит, ярый, дөреслеген үземдә тикшереп карармын.

ДӘВАМЫ БАР

# Драматургия



*3-нче урын*
***Фирүзә Мостафина***

# «Язмыш шулай теләде»

Драма

Катнашалар:
Җәүдәт – 60 яшь.
Зөлфирә (хатыны) – 51 яшь.
Ләйлә (кызлары) – 22 яшь.
Ислам (Ләйләнең егете) – 24 яшь.
Әлфия (күршеләре) – 66 яшь.
Рөстәм (Җәүдәтнең дусты) –58яшь.
Зөлфирә – Җәүдәтнең бертуганнары (2–3пар).

*Беренче пәрдә*
*Беренче күренеш*

(Өй эче күренеше. Зөлфирә белән Ләйлә өстәл әзерлиләр: Җәүдәтнең 60 яшьлек юбилеена әзерләнәләр. Жәүдәт креслода утыра, ул костюм–чалбардан)

Зөлфирә (тәлинкәләрне сөртә–сөртә): Менә бит, бу көн дә килеп җитте, тиздән кунакларыбыз да җыела башлар.Үзеңне ничек хис итәсең, картым? (көлеп) 60ны тутырган кебекме соң?

**Җәүдәт**: Әәәәй, без картаймый кем картайсын?! (Зөлфирәне иңеннән кочып) Тик, күңелем һаман 18 дә.

**Ләйлә**: Әтием, син әле яшь егетләр кебек. (Әтисен кочаклый). Тиздән кунаклар да килеп җитәр. Әти, син аларны каршы алырга чыгырсың. Әни, син бит әле матур күлмәгеңне дә кимәгәнсең. Барысын да үзем әзерләп бетерәм, бар, киенеп чык. (Әнисенең иңеннән тотып кертеп җибәрә).

(Урамда гармун тавышы ишетелә)

**Җәүдәт**: Килеп җиттеләр, ахры. Әнә, гармун тавышлары да ишетелә башлады (тәрәзәдән карый). Килделәр. Зөлфирә, син әзерме?

(Бүлмәдән матур күлмәген киеп, балкып Зөлфирә чыга.

Җәүдәт аннан күзләрен ала алмый).

**Җәүдәт**: Һай, әнисе бигрәк матур инде син. Кабат гашыйк булдым, ахры.

(Ул арада шаулашып өйгә Җәүдәтнең якын дусты Рөстәм, Җәүдәт һәм Зөлфирәнең туганнары керәләр. Рөстәм гармунда уйнап җырлый):

Бәхетле бул, кайгы күрмә,
Сагышларга уралма.
Туган көнең якты булсын,
Караңгыда югалма.
Туган көнең белән, дустым!

**Җәүдәт**: И, дустым, рәхмәт инде сиңа!

**Зөлфирә**: Исән–сау гына килеп җиттегезме? Әйдәгез, түрдән узыгыз!

(Барысы да кунаклар белән кочакланышып күрешәләр, исәнләшәләр. Кунаклар бүләкләрен, күчтәнәчләрен биреп, әкренләп утыра башлыйлар)

**Ләйлә**: Әлфия апа гына күренми әле.

**Зөлфирә**: Озакламас инде, кереп җитәр.

(Ишектән күршеләре Әлфия күренә)

**Әлфия**: Нихәлләрегез бар? Исән–сау гына торасызмы? Күрше, юбилееӊ белән сине. Һәрвакыт шулай яшь егетләр сыман булып кал!

**Җәүдәт**: Рәхмәт, рәхмәт Әлфия апа. Әйдә, рәхим ит. (Әлфия дә утыра)

**Зөлфирә**: Әйдәгез, оялып утырмагыз, ашап–эчеп утырыгыз, барыгыз да үзебезнекеләр бит.

**Рөстәм** (торып баса): Сүзне үзем башлыйм әле. Дустым, сине чын күңелдән шушы 60 яшьлек юбилееӊ белән тәбриклим. Хатыныӊ Зөлфирә белән бәхеттә, куанычта,тагын да шулай озак еллар яшәргә язсын. (Гармунын ала). Әйдә, үзебезнеӊ яраткан җырны җырлап китик әле. (Рөстәм җырлый башлый, калганнар кушыла. Җыр: «Китмим әле яшьлегемнән» Фирая Зыятдинова сүзләре, Луиза Батыр-Болгари көе)

Бер–бер артлы еллар үтә
Көмеш өстәп чәчләремә.
Ә шулай да мин ышанам
Яшен булып яшьнәремә.
Без бит җирдә якты, җылы
Ямь өстәргә яратылган.

Китмим әле яшьлегемнән
Яз гөлләре арасыннан,
Яз гөлләре арасыннан.

(Җыр акрын гына бетә, ут сүнә.)

2 нче күренеш

(Зөлфирә белән Ләйлә туган көннән соң кашык–тәлинкәләр сөртеп урнаштыралар, Җәүдәт алар янында утырып тора)

**Ләйлә**: Сизелми дә үтте бу туган көн. Сиңа ошадымы соң, әти?

**Җәүдәт**: Әлбәттә, кызым. Минем иң якын, иң кадерле кешеләрем янымда иде. (Бераз вакыт узгач). Нигәдер хәлем юк. Үземне начаррак хис итәм әле. Бераз ятып торыйм, булмаса.

**Зөлфирә**: Бар, бар, картым, арыгансыңдыр. Ял итеп ал.

(Җәүдәт кереп китә)

**Ләйлә**: Әни, минем синнән бер әйбер сорыйсым килә.

**Зөлфирә**: Сора, кызым, сора.

**Ләйлә**: Әнием, ә син үзеңнең беренче мәхәббәтеңне хәтерлисеңме? (елмая)

**Зөлфирә**: Әйе, кызым, ничек инде хәтерләмәскә?!

**Ләйлә**: Сөйлә әле, әнием.

**Зөлфирә**: Кызым, мәхәббәт турында уйларга башың яшь түгелме соң әле? (елмая)

**Ләйлә**: Әнием, миңа бит инде 22.

**Зөлфирә**: (кызын кочып ) Шаяртам, кызым. (Диванга утыралар, салмак көй уйный башлый). Яшьлегемдә булган иң кайнар мизгелләрнең берсе... Гашыйк булу... Беренче мәхәббәт... Җәйге матур кич иде. Иптәш кызларым белән һәрвакыттагыча күл буенда очрашырга дип сөйләштек. Җәйләрен күл буе икеләтә матур бит. Авылыбыз зур, караңгы төшә башлагач, күл буена кеше хәйран җыела иде: яше, карты – һәммәсе шунда. Бергәләшеп җырлар җырлый, уеннар уйный идек. Бервакыт, минем белән бергә килгән иптәш кызларым уенга кереп киттеләр, мин үзем генә утырып калдым. Шулчак яныма берәү килде дә: «Нигә үзең генә моңаеп утырасың?» дип, сүз башлады. Бик кызык егет булып чыкты тагын үзе, сөйләшүебез озакка сузылды. Шәһәр егете булып чыкты, авылыбызга кунакка кайткан. Миңа 18, аңа 27... Яшь арабыз 9 ел булса да, сөйләшүебез, аралашуыбыз һаман дәвам итте. Сүз кем турында барганын аңлагансыңдыр, кызым? (Елмая)

**Ләйлә**: Беренче мәхәббәтең...әти идемени? (Гаҗәпләнеп елмая)

**Зөлфирә**: Әйе. (Бераз туктап торгач). Соңрак ул үзенең шәһәргә китәсе булуы турында әйтте, ләкин бик тиздән кайтырга вәгъдә бирде. Мин дә аны көтәчәгем турында әйттем. Еллар узды, башымда һаман: «Ул мине оныткандыр, шәһәр егетенә авыл кызы нигә кирәк булсын?» дигән уйлар иде. Бервакыт, иптәш кызым керде дә: «Ишеттеңме соң әле, Җәүдәт кайткан»,– диде. Үземне кинәт ниндидер хисләр биләп алды. Кич җитүгә, күл буена йөгердем. Бәлкем, ул андадыр… Ләкин күл буенда мине берәү дә көтми иде.

**Ләйлә**: Кайтып киттеңме?

**Зөлфирә**: Юк, аның киләсенә күңелем ышана иде. Кинәт, иңнәремнән берәү тотты да: «Нигә моңаеп утырасың үзең генә?»– дип сорады. Аның тавышын ишетүгә, йөземдә елмаю барлыкка килде. Ул мине онытмаган!… Озак кына сөйләшеп утырдык. Ул миңа үзенең мәхәббәт хисләрен аңлатты. (Бераз туктап торгач) Язмыш шулай теләгәндер, бүгенге көнгә кадәр бәхетле яшибез, Аллага шөкер. (Музыка әкрен генә сүнә)

**Ләйлә**: Эх, әнием, мин Сезне шундый яратам. (Әнисен каты итеп кочаклый )

**Зөлфирә**: Чү, әтиең чакыра түгелме, янына кереп чыгыйм әле. Ул үзен начар хис итәм дигән иде. (бүлмәгә кереп китә)

**Ләйлә**: Менә бу мәхәббәәәәәәәәт…

(ут сүнә)

*Икенче пәрдә.*

*3нче күренеш*

(Күл буе. Ләйлә белән Ислам урындыкта утыралар).

**Ислам**: Я, сөйләп җибәр, Җәүдәт абыйның туган көннәре ничек үтте? Кунаклар күп килдеме?

**Ләйлә**: Барысы да күңелле үтте, иң якын туганнарны гына чакырдык. Күрше Әлфия апаны чакырдык, әтинең якын дусты Рөстәм абый килде, һәм дә инде әтинең, әнинең бертуганнары.

**Ислам** (елмаеп): Әйе, күп булмаган икән.

**Ләйлә**: Беләсеңме нәрсә… (сүзен әйтеп бетерми туктап кала)

**Ислам**: Нәрсә булды, Ләйлә?

**Ләйлә**: Әти бездән нидер яшерә кебек. Ахыргы көннәрдә ул үзен бик начар хис итә. Менә бүген дә гел ятып кына торды. Ә бәлкем… (курку хисе белән)

**Ислам**: Нәрсә, Ләйлә?

**Ләйлә**: Әллә нинди уйлар килә башка…

**Ислам**: Юкка борчылып утырма әле, Ләйлә (кызны кочаклый). Күрдеңме, йолдыз атылды?

**Ләйлә**: Ислам, ә син безнең сөюебез мәңгелек булачагына ышанасыңмы? (күктәге йолдызларга карап)

**Ислам**: Әйе, Ләйлә (катырак кочаклый)

Кемдер йөгереп сәхнәгә керә: Җәүдәт абыйны ашыгыч ярдәм машинасы белән район хастаханәсенә алып киттеләр!

(Ләйлә белән Ислам йөгереп чыгып йөгерәләр, ут сүнә)

*4нче күренеш*

(Өй эче. Зөлфирә, күз яшьләрен сөртә–сөртә өстәл янында утыра.

Аның янына күрше Әлфия керә)

**Әлфия**: Өйдә кеше бармы? (Зөлфирәне күргәч) Нихәлләрең бар, күршекәем?

**Зөлфирә**: Авыр, Әлфия апа, бик авыр. Җәүдәтемнең киткәненә тиздән 2 ай була, күңелем әле дә ышанмый (күз яшьләрен сөртә).

**Әлфия**: Кем уйлаган бит, әле генә 60 яшен тутырган егет, җир җимертеп яшәп яткан җиреннән дөнья белән хушлашыр дип…

**Зөлфирә**: Хастаханәдә аны яман чир белән авырган булган, диделәр. Юк, ышанмыйм Әлфия апа. Бу бит башка сыймый! (елый).

**Әлфия**: Тынычлан, Зөлфирә,тынычлан. Күз яшьләреңне кызың күрсә…әле үзе кайда соң?

**Зөлфирә**: Иптәш кызы чакырды, шуның янына китте. Ул бала да бик борчыла, кайгыра, күрсәтми генә.

**Әлфия**: Зөлфирә, әйтергә дә онытып торам икән…Сиңа керүемнең сәбәбе шул: ирең исән чакта безгә кергән иде һәм шул вакытта: «Әлфия апа, сиңа бер үтенечем бар: шушы кулъяулыкны, мин киткәч, Зөлфирәгә бирерсез әле, эчендә язуы да бар»,– диде. Мин тиз аңлап җиткерә алмадым. «Кая китәсең? Берәр хәл булдымы әллә?»–дип сорадым. «Барысы да соңрак ачылыр, Әлфия апа. Мин сине иртәгә үзебездә туган көн кичәсендә көтеп калам. Тик, мин биргән кулъяулык турында, зинһар, Әлфия апа, Зөлфирәмә берни әйтмә», – диде. Мин инде олы яшьтә, үзең беләсең, хәтерем дә какшаган; бүген өйләрне җыештырып йөргәндә шул кулъяулыкка тап булдым. (Бераз туктап торгач) Зөлфирә, бу сиңа ирең Җәүдәттән (кулъяулыкны бирә). Тынычлап укы, мин чыгыйм.

(Әлфия чыгып китә. Зөлфирә диванга утыра, кулъяулык эченнән язуны ала һәм моңсу көй белән Җәүдәт исеменнән хат яңгырый)

Зөлфирәм! Гафу ит мине, Сезгә алдан белә торып, берни дә әйтмәгән өчен. Сезнең күңелегезне төшерәсем килмәде. Күптән түгел, син эштә вакытта район хастаханәсенә барып тикшеренеп кайттым. Йөрәгем сизгән ахыры, анда миңа куркыныч хәбәр әйттеләр: яман чир авыруы… «Моның булуы мөмкин түгел, мин үземне яхшы хис итәм бит», – дидем. Ә андагы дәвалаучылар миңа: «Без сезнең анализларыгызны кат–кат тикшердек, бернинди ялгышлыклар да булырга мөмкин түгел», – дип җавап бирделәр. Нишләтәсең, язмыш шулай теләгәндер. Зөлфирә, мин кызым Ләйлә белән сезне бик нык яратам, саклагыз бер–берегезне. Ә мин һәрвакыт сезнең янәшәгездә булырмын…

(Музыка көчлерәк уйный башлый, Зөлфирә елый, сәхнә артыннан Ләйлә йөгереп чыгып әнисен кочаклый)

**Ләйлә**: Әниеееем!

*(пәрдә ябыла)*
*Тәмам!*

## Ташландык

(1 пәрдәле драма)

Рольләрдә:
Ләлә –15 яшь
Әнисе Рауза –50 яшь
Иптәш кызы Алинә –15 яшь
Тапкан әнисе Энҗе –33 яшь
Күрше хатын Сәрия – 49 яшь

(Авылча җиһазланган йорт. Ләлә мәктәптән кайта)

**Ләлә**: Әнием, мин кайттым.

**Рауза**: Әйдә, кызым, син яраткан пирогны пешердем.Бүген бит яраткан кызымның туган көне. Кил әле,бәләкәчем.

**Ләлә**: Әни, мин бит бәләкәч түгел, миңа 15 тулды, 15 яшь.

**Рауза**: Үткән гомер, кызым, үткән гомер.

**Ләлә**: Әнием, әйт әле, 15 яшьтә син нинди идең?

**Рауза**: Иии, кызым, кем хәтерли инде аны хәзер?!

**Ләлә**: Сөйлә инде, әнием, миңа бик кызык.

**Рауза**: Без яшь чакта эш күп иде, кызым. Без эшләп үстек. Хәзер бит кер юмыйлар, су ташымыйлар, күп кеше хайван да асрамый бит. Авыл җирендә дә эш калмады…

**Ләлә**: Иии, әнием, рәхмәт сиңа, нинди табын әзерләгәнсең.

**Рауза**: Иптәшләрең киләдер бит, кызым?

**Ләлә**: Алинә килә дә, Рамильне чакырырмын дигән идем.

**Рауза**: Төпле егетме соң ул, кызым? Хәзер ышанычлы егетләр дә калмады бит.

**Ләлә**: Әни, ни сөйлисең, Рамиль андый егет түгел. Менә бүген таныштырырмын.

**Рауза**: Ярар, кызым, тәртипле генә булыгыз. Бар, дәресләреңне кара.

**Ләлә**: Рәхмәт,әнием. Син дөньядагы барлык әниләрдән дә яхшырак, матуррак, ягымлырак. (үз бүлмәсенә кереп китә)

(Күрше Сәрия керә)

**Сәрия**: Саулармысыз, өйдә кеше бармы?

**Рауза**: Әйдә, күрше, әйдә, мактап кына йөрисең, чәй эчеп утыра идем.

**Сәрия**: Ләлә кая соң?

**Рауза**: Дәрес әзерли. Әйдә, бүген туган көне бит кызымның, чәй эчеп алыйк, Ләләнең яраткан пирогын пешердем.

**Сәрия**: Ни арада үсеп җитте бу бала. Кайчан гына алып кайткан идегез. Рәхимҗан, мәрхүм, үсеп җиткәнен дә күрә алмады…

**Рауза** (пышылдап): Күршекәем, шыпырт, Ләлә ишетә күрмәсен. Кичермәс, дөреслекне яшергән өчен.

**Сәрия**: Шушы яшькә кадәр кадерләп үстердең үзен, кайбер ана үз баласын да ул кадәр кадерләми. Кадереңне генә белсен инде.

**Җәүдәт**:Картлык көнемдә таянычым инде ул минем. Рәхимҗаным мәрхүм, балаларыбыз булмады (яшьләрен сөртә). Я, ярар, элеккеләрне искә төшереп, яраларны яңартып утырмыйк әле. Әйдә чәеңне суытма. Күңелсезләнеп утыра торган көн түгел бит.

(Ләлә чыга)

**Ләлә**: У, кунак бар икән. Исәнме, Сәрия апа.

**Сәрия**: Исәнме, үскәнем.

**Рауза**: Кызым, син кая?

**Ләлә**: Алинә килә, кибеткә барып кайтырбыз дигән идем.

**Рауза**: Ярый, кызым, матур гына йөрегез.

**Ләлә**: Без озакламыйбыз, әнием.

**Сәрия**: Ярар, күрше, мин дә чыгыйм.

**Рауза**: Ярар, күрше, тагын кер. Хәзергә хуш.

(Урам күренеше. Алинә белән Ләлә)

**Алинә**: Ләлә, мин бер яман сүз ишеттем. Әйтсәм ачуланмыйсыңмы?

**Ләлә**: Рамиль белән минем турындамы?

**Алинә**: Юк, монда Рамильнең катнашы юк.

**Ләлә**: Әйт, тыңлыйм.

**Алинә**: Сине ташландык бала диләр, дөресме?

**Ләлә**: Ни сөйлисең син? Кечкенәдән бергә үстек бит. Бала ташландык була алмый, син үз акылыңдамы?

**Алинә**: Тынычлан, Ләлә, мин ишеткәнемне генә әйтәм.

**Ләлә**: Ярар әйдә бу гайбәтне онытыйк, син әйтмәдең, мин ишетмәдем. Кичкә безгә кил.

(Өй күренеше. Ләлә елап өйгә кайта)

**Ләлә**: Әнием шул дөресме?

**Рауза**: Кызым, ни булды? Нәрсә ул?

**Ләлә**: Мин ташландык баламы? Әнием, дөресен әйт.

**Рауза**: Кызым, балам, ни сөйлисең? Кем әйтте бу сүзләрне?

**Ләлә**: Бар да белә, ник мин белмим?

**Рауза**: Син минем үз кызым, кадерле кызым. Тынычлан, кызым. хәзер иптәшләрең килә, мәҗлеснең ямен җибәрмик.

**Ләлә**: Ярар, әнием, мин сина ышанам. Хәзер юынам да, өстәл әзерлим.

(10 минут үткәч, Ләлә кулына кызлыкка алынган шаһадәтнамә тотып чыга, үзе елый)

**Ләлә**: Әнием, ни бу? Ник мине алдадың?

**Рауза**: Кызым, тынычлан әле. Хәзер аңлатам. 15 ел элек булды ул хәл. Рәхимҗан мәрхүм белән балабыз булмады. Нинди генә врачларга бармадык, кая гына тикшеренмәдек. Безгә коточкыч хәбәр җиткерделәр: балагыз була алмый…Менә шунда инде Рәхимҗан әтиең белән киңәшләштек тә, сине алып кайттык. Бик җитез,бик шук идең. Өебезгә шатлык өстәдең. Мин дә, әтиең дә бик бәхетле булдык, балам.(Ләлә елый-елый тыңлый)

**Ләлә**: Ә минем чын әнием кем, ул кайда? Ник миннән баш тарткан?

**Рауза**: Исеме – Энҗе, шәһәр кызы, шәһәрдә яши, 18 яшьтә тапкан.

**Ләлә**: Тапкан да, ташлаган. Ышанасы да килми.. .Мин – ташландык!!!

**Рауза**: Балам, ни сөйлисең син? Мин сине бар җан җылымны биреп үстердем.

**Ләлә**: Рәхмәт сиңа, әнием.Синең алда бурычлымын. Ләкин мин Энҗене табып күзләренә карап сорау бирәсем килә. Ни өчен?

**Рауза**: Кызым, үткәннәрдә казынма.

**Ләлә**: Юк, әни. Син мине туктата алмассың. (Бүлмәсенә кереп китә)

**Рауза**: Ни өчен? И Ходаем, бердәнбер баламны тартып алма!… Тукта, кунаклар килеп вакыт җитәр. Кызымның бәйрәмен бозмыйк. (Өстәл әзерлиләр, Ләлә чыга)

**Ләлә**: Әнием, кунаклар килер вакыт та җитте. Мин бик дулкынланам.

(Ишектә звонок)

**Ләлә**: Әнием, ач әле.

(Рауза барып ишекне ача. Кулына чәчәк бәйләме тоткан Рамиль керә, артыннан Алинә һәм таныш түгел бер хатын. Барысы да аптырашып басып торалар. Исәнләшәләр, Рамиль туган көне белән котлап чәчәкләрен Ләләгә суза)

**Рауза**: Әйдәгез кунаклар, рәхим итегез, аптырашып тормагыз, утырыгыз.

**Энҗе**: Менә йортыгызны таба алмый йөргәндә, шушы яшьләр очрады. Мин ялгышмаганмынмы? Ләлә биредә торадыр бит? Мин Энҗе булам, әнисе.

**Ләлә**: Ялгышыгызны бик соңлап аңлагансыз, ханым.

**Рауза**: Кызым (кисәтүле тавыш белән), чит кеше белән алай сөйләшмиләр.

**Энҗе**: Мин бит чит кеше түгел, әнисе.

**Ләлә**: Мин сезне үзем эзләп табасы идем. Килеп яхшы иткәнсез. Юк, әни дип әйтер өчен түгел, күзләрегезгә карар өчен.

**Энҗе**: Без барыбыз да адәм балалары, барыбыз да хаталанабыз.

**Ләлә**: Хайваннар да хәтта балаларын ташламыйлар. Менә сез, нинди күңел, нинди вөҗдан белән яшәдегез. Оялмыйча әнисе дип торасыз. Кояш берәү булган кебек, әниләр дә бала өчен берәү генә. Минем әнием – Рауза, ишетәсезме, Рауза!

(кунаклар өстәл тирәли утыралар, Ләйлә ярсый-ярсый сөйли)

**Энҗе** (тезләнеп): Кичер, кызым, яшьлектә аңлап бетермибез. (Ләләне барып кочаклый, Ләлә этеп җибәрә)

**Ләлә**: Торыгыз, мескенләнмәгез. Бу сүзләр белән генә минем каткан бәгеремне эретә алмассыз. Ходайдан гафу сорагыз.

**Энҗе**: Яшь идем, уйлап бетерелмәгән. Яшьлек бар кешедә дә була бит…

**Ләлә**: Әйе, яшьлек бар кешедә дә була. Ләкин бар яшьләр дә сезнең кебек балаларын ташлый башласа ни була? Без – ташландыклар белән җир йөзе тула бит.

**Энҗе**: Кичер, кызым…(елый)

**Ләлә**: Мин ташландык булганга карап ата-ана назыннан мәхрүм булмадым. Ходай ялганларга ирек бирмәс. (Халыкка карап) Әй, кешеләр (югары тонда), яшьлектә хаталар кылмагыз. Без бит кешеләр, адәм балалары. Хайваннар булып хайваннар балаларын ташламыйлар. Кайберәүләр кебек түбән җанлы булмыйк. Кылган гамәлләребез өчен гомер буе үкенерлек булмасын…

*(Пәрдә ябыла)*

## КАЗЫЙЛАР ТАРАФЫННАН ИГЪТИБАРГА ЛАЕК ДИП ТАБЫЛГАН ЭШЛӘР

*Илназ Абдрахманов*
Шигърият (12-14 яшьлекләр)

### Кайтабыз да китәбез!

Укулар тәмамлангач,
Каникуллар башлана.
Кайтабыз без авылга
Чүпрәле якларына.

Бер дәү әнием – Чатказда
Икенчесе – Чынлыда.
Җәй буе ике авылда,
Кунак булабыз шунда.

Шундый рәхәт авылда
Йөгерәбез, чабабыз.
Велосипедлар белән
Болыннарга чыгабыз…

Җәйнең үткәнен шулай
Сизмичә дә калдык без.
Авылның матурлыгын
Күңелләргә салдык без.

Ул авыллар бигрәк матур,
Шунда әти-әнием үскән.
Хәтфә кебек яшел үлән,
Кабка төбенә җиткән.

Иртән торып каз бәбкәсе
Сакладык без чирәмдә.
Дәү әниләр шатлангач,
Рәхәт булды бигрәк тә.

Баян тартып кичләрен
Җырладык без, хисләнеп.
Каникуллар тиз уза шул,
Сизмәдек тә үткәнен…

Печәнен дә җыйдык без,
Эскертләргә куйдык без,
Балык тоттык инештә,
Кызындык без кояшта.

Казанны да сагындык,
Без анда туып үстек,
Авылдан көч җыеп килдек әле,
Инде укырга киттек.

Исән-сау булсын әбиләрем
Сызламасын аяк-куллары!
Алар таза-сау булсалар,
Тагын кайтырбез әле без –
оныклары!

### Алып кайтам машина!

Шау-гөр килә авыллар,
Җыела авылдашлар
Рәхәтләнеп ял итәргә
Кайталар бар туганнар!.

Сабантуй – көтеп алынган
Иң хөрмәтле бәйрәмдер.
Юкка гына әйтмиләрдер
«Сабан туе – хезмәт туе
Шатлык һәм бәхет туе!»

Язлар җиткәч, мин дә яратам
Ямьле сабан туйларын.
Үскәч батыр булып калу
Минем бөтен уйларым.

Хыялланып кына булмый
Күп көч куярга кирәк
Көрәшчеләр бик күп тә бит
Батырлары бик сирәк.

Егет булгач, басам әле
Көрәшчеләр сафына.
Батыр калып бүләккә
Алып кайтам машина!..

Тик бераз гына үсим инде
Мин бит әле кечкенә.
Ә әлегә бәйрәм итик шатланышып,
Туганнар, бергә-бергә!

## Апамның туй көне

Бүген бездә зур бәйрәм
Апамнын бит туй көне.
Әллә кайчаннан бирле
Көтәм инде бу көнне!

Илназ абый, килдеңме,
Өйләнәм бит дисенме?
Йөрәкләрне җилкендереп
Әллә бер биисеңме?..

Җитәкләшеп, матур итеп
Тигез гомер итегез.
Бер-берегез өчен җилкән булып
Йөзеп чыгыгыз тормыш диңгезен.

Һәрвакытта тормыш юлы
Сез дигәнчә бармас шул.
Тик шулай да тырышыгыз
Туры юлдан барыгыз!

Бүген – сезнең туй көнегез
Тормышыгызнын тик башы
Уртак юлыгызның бәхет,
Шатлык булсын юлдашы!

Без телибез сезгә бүген
Уңышның иң зурысын.
Киләчәкнең иң матурын.
Гомернең иң озынын!

*Диләрә Мансурова*
Шигърият (12-14 яшьлекләр)

## Дөнья тоткасы…

«Дөньяны өч кит тота», – дип,
Сөйли иде әбиләр.
Дөнья тоткасы ни икәнен
Әллә алар белмиләр?
Нишләп инде өлкән буын
Белмәсен ди шул хакта?
«Һөнәрле һич үлмәс», – дигән
Мәкаль яши халыкта.
Алтын куллы кешеләрдән
Тора дөнья тоткасы.
Һөнәрле кешеләр генә
Хәл итә бит барысын.
Көн дә иртә белән торып,
Күз салабыз өстәлгә.
Икмәк белән тамак туя,
Көч һәм дәрман өстәлә.
Рәхмәт сезгә, игенчеләр
Һәм пешекче апалар!
Тамагыбыз тук булганда,
Матурая дөньялар.
Төзүчеләргә мең рәхмәт,
Җылы йортта яшибез.
ЖЭКта эшчеләр – фидакарь
Һич туңуны белмибез.
Өс – башыбыз бөтен безнең,
Тегүчеләр тырышкан.
Көнкүреш хезмәтчәннәре,
Рәхмәт сезгә халыктан!
Тракторчы, нефтьче һәм шофер,
Артист, токарь, урманчы,
Сездән башка тормыш бармый -
Уйлап кына карачы…
Киләчәгем бәйле минем
Укытучыларым, сездән,
Олы тормыш юлларына
Аяк басарбыз тиздән.
Төрле һөнәр мәктәпләре
Безне күптән көтәләр.
Сайлыйк әле, без, дусларым,
Тик кирәкле һөнәрләр!
«Дөнья тоткасы» булырлык
Горур һәм тырыш булыйк,
Үз һәнәребез остасы
Һәм КЕШЕ булып калыйк!

## Чит илләрдәге татарларга

Явыз Иван сәясәте
Татарларны рәнҗетте.
Бик күбесе кимсетелде,
Күпләре читкә китте.
Тел белмичә, җәфа чигеп,
Тормыш корганнар алар.
Бик къп кыенлыклар күреп
Шунда яшәп калганнар.
Үз телләрен, җыр- моңнарын
Онытмаганнар алар.
Мәдәният һәм сәнгатьне
Тарихны саклаганнар.
Язмыш каты сынаса да,
Сыгылмыйча калганнар.
Горурланам алар белән
Нинди көчле рухлылыр!

## Татарстан ризыгы

Бик күп сыйфатлы товарлар
Җитештерелә бездә,
Әз генә шулар турында.
Сөйләп үтимче сезгә.
«Түбән Кама» сөт ризыгын
Бармы татыганыгыз?
Катык, кефир һәм сөтеннән
Телегезне йотарсыз.
Ә Чаллыда чыга торган
Туңдырманы күрегез,
Үзе тәмле һәм сыйфатлы
Файдалы ул, белегез!
Ә Раифта чыга торган
Минералка бер дигән!
Башка җирләрдән дә аны
Алып китәләр икән.
Үзебезнең Мамадышта
Җитештерә казылык,
Шәһәребезнең йөзенә
Китермәс ул кызыллык!
«Икмәк-табын күрке», – диләр,
Матур сүзләр, килешәм.
«Тәмле икмәк ашыйлар», –
дип,
Бездән бар да көнләшә.
Үзебезнең республика
Ризыкларын алыгыз!
Сыйфатлы ризык кулланып,
Сау-сәламәт булыгыз!

## Кеше булып калыйк!

Бу көннәрдә мин, дусларым,
Телевизор карамыйм.
Интернетта да утырмыйм,
Газета да укымыйм.
Барысы да бертавыштан:
«Ахырзаман җитә», – ди,
Дөнья бетәргә бары тик
Биш кенә көн калган, ди.
Имеш, түрә абзыкайлар
Бункер сатып алганнар.
Үзләренең мал-мөлкәтен
Шунда, ди, тутырганнар.
«Ахырзаман» дигән булып,
Кемдер һаман урлаша.
Барыбер дөнья бетә, дип
Бертуктаусыз алдаша.
Кемдер нәкъ шушы көннәрдә
Эшләп йөри игелек.
Кемнеңдер гомер буена
Күңелендә – изгелек.
Дөньялар үзгәреп торса да,
Әйдәгез, без сынатмыйк!
Нинди генә хәлләрдә дә
Чын кеше булып калыйк!

## Шүрәле теләкләре

Тукай абый Шүрәлесе
Кара урманда торган.
Кайчагында ялгышып,
Явызлыклар да кылган.

Үткән гасырда да түгел,
Менә шушы заманда.
Шүрәлене күрергә,
Юнәлдек без урманга.

Урман эче тынып калган,
Җәнлекләр дә күренми.
Эчкәрәк керергә булдык,
Кызыксынусүрелми.

Шүрәлебез елап утыра,
Бүрәнәсе янында.
Кытыклап кеше үтерү,
Һич кенә юк уенда.

«Заманалар үзгәрә», – ди,
Уйлары инде үзгә.
«Явызлык бүтән кылмам,
Кайтыймчы бүген сезгә!»

Шүрәлене авылга без
Алып кайтырга булдык,
Кайткачтын аның белән,
Рәхәтләнеп уйнадык.

Мәктәпкә алып бардык,
Ул аны да яратты.
Компьютерны күргәчтен,
Бигрәкләр дә шатланды.

Исәпләдек, яздык, чиштек,
Укып та без күрсәттек.
Тәрбияле бала нинди була,
Барсын аңа өйрәттек.

Наданлыктан туйган инде,
Исәбе бар аның да.
Урман мәктәбен ачу,
Уе килде башына.

Урмандагы бар җәнлекне,
Укырга ул өйрәтер.
Укый белә башлагач,
«Туган тел»не сөйләтер.

«Әлифба»ны , «Туган тел»не
Бүләк иттек без аңа.
Бүләкләр аңа ошады
Күзләре гел ут яна.

Киткән чакта теләде:
«Телегезне саклагыз!
Тукай абый әсәрләрен
Өйрәнегез, ятлагыз!»

## Әниемә бүләгем

Әниемә бүләк ясар өчен,
Утырдым мин өстәл артына.
Әллә ясап бирергәме икән
Матур гына бер картина?

Әллә күктән йолдызларны
чүпләп,
Ясап бирергәме муенса?
Бик тә күңелләре булыр иде
Минем йолдызларга коенса.

Әллә иртән йокысыннан
торгач,
Бер кочаклап үбеп алыйммы?
Эшкә чыгып киткән
вакытында
Кесәсенә кәнфит салыйммы?

Озак баш ваттым мин,
әниемне
Белмим ничек сөендерергә.
Һәм тотындым, үзе эшкә
киткәч,
Бөтен өйне киендерергә.

Обойлар бик тоныкланган иде,
Ясап куйдым анда күп чәчәк.
Әни өйгә кайтып керүгә үк,
Иң беренче аны күрәчәк.

Күрәчәк һәм мине кочып алып,
Күккә кадәр, менә, чөячәк!
Әниебез гел елмаеп торса,
Матур булыр безнең киләчәк.

## Гореф-гадәт

Гореф-гадәт нәрсә ул, дип
Мин уйланып торамын.
Үзем җавап таба алмагач,
Әбиемнән сорадым.

Әби, – димен, әйтеп бирче,
Нәрсә ул гореф-гадәт?
Андый гадәтләр булырга
Нәрсәләр булган сәбәп?

Каз өмәсе – йола бәйрәм
Йортларда каз суялар.
Казлар елда күп булсын диеп,
Каурый сибеп куялар.

Басуларда карлар эреп,
Җирләр бераз ачылгач,
Карга боткасы пешереп,
Кешеләр яз чакыра.

Сабантуйлар – сабаннан соң
Борыннан килгән йола.
Гореф-гадәте халкымның
Елда үтәлеп тора.

Язгы кыр эшләре беткәч,
Шаулатып бар дөньяны
Иркен мәйдан үзәгендә
Гөрли сабантуйлары.

Кешеләр яңгыр чакырып,
Су сибешеп уйныйлар.
Әгәр яңгыр явып куйса,
Сөенешеп туймыйлар.

Аңладыңмы инде улым,
Нәрсә ул гореф-гадәт.
Гореф-гадәтләр булырга
Нәрсәләр булган сәбәп.

## Тылсымлы куллар

Дәү әнием бар минем,
Чигә милли киемнәр.
Түбәтәй, калфак, кәвешләр,
Сокланмас икән кемнәр.

Аның чиккән түбәтәе
Күз яуларын алырлык.
Бар күңелен биреп эшли,
Күреп, таңнар калырлык.

«Халкым өчен» дип тырыша,
Даны еракка киткән.
Ул чиккән түбәтәй, калфак
Кытайга барып җиткән.

Тылсымлы куллар тудырган
Ак калфак, түбәтәйләр.
Халкымның данлы үткәнен
Гүя безгә сөйлиләр.

Чулпыларын талып куйсын,
Калфагын кисен кызлар.
Түбәтәй төшмәсен баштан –
Халкымның йөзе алар.

# ЭЧТӘЛЕК

**КЕРЕШ СҮЗ** .......... 3

**ШИГЪРИЯТ**

Эльвина Гәрәева .......... 5

Диләрә Зәкиева .......... 6

Искәндәр Зиннуров .......... 7

Диләрә Кашапова .......... 9

Алинә Хәбибуллина .......... 12

Энҗе Хөсәенова .......... 19

Адилә Әхмәтҗанова .......... 21

Илназ Закиров .......... 25

**ПРОЗА**

Айлия Хаҗиева .......... 30

Азалия Мирхәйдәрова .......... 37

Илназ Билалов .......... 40

Айзилә Абдрахманова .......... 42

Алинә Хәбибуллина .......... 48

Азалия Хәмәтшина .......... 52

Энҗе Халикова .......... 52

Гөлчәчәк Сабирова .......... 55

Айгизәр Ногманов .......... 57

**БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ**

Идел Ногъманов .......... 60

Нәзилә Гирфанова .......... 62

Назилә Закирова .......... 65

Ләйсән Абдрахманова .......... 68

Гөлия Яруллина .......... 72

Диләрә Галимуллина .......... 75

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Зилә Габдрахманова .......... 80

Ильвина Шайхуллова .......... 82
Нарим Сәлмәнов .......... 84
Ләйсән Абдрахманова .......... 86
Талия Төхфәтуллина .......... 92
Айзилә Абдрахманова .......... 99
Илүзә Нәгыймова .......... 106
Рүзәл Шәрипов .......... 111
Чулпан Гарифуллина .......... 117
Зәринә Хуҗина .......... 126
Индира Гайнетдинова .......... 134

**ДРАМАТУРГИЯ**

Фирүзә Мостафина .......... 139

**КАЗЫЙЛАР ТАРАФЫННАН ИГЪТИБАРГА ЛАЕК ДИП ТАБЫЛГАН ЭШЛӘР**

Илназ Абдрахманов .......... 149

